1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН  2015 МАРТ № 3

Сөембикә

СУРРОГАТ ӘНИ
савапмы, әллә...

БАЛАСЫЗ
БАЛ АЕ
*очрашу урыны –
Италия*

ИЛДУС
ГАБДРАХМАНОВ
СЫЙЛЫЙ
*бәйрәм табынына –
үрдәк*



Надежда
ИМАМЕТДИНОВА:

«ЙӨРӘГЕНДӘ
ӨМЕТ УТЫ СҮНМӘСЕН»



70
1945–2015

Сугыш язган хатлар

Безнең әтиебез Габдрахман Гаффар улы унбиш авылдашы белән авылдан сугыш башлануның икенче көнендә үк чыгып китκән. Әниебез белән сугышка кадәр һәм аннан соң тугыз бала алып кайтканнар. Ике ир балалары әти фронтта чакта вафат (һәлак дию хаклырактыр) булган: берсенә яшь ярым, икенчесенә ярты яшь чакларында.
Әтинең фронтта йөргәннәре бер кыйсса, госпитальдә ятулары бүтән бәян. Калганын аның әнигә язган ике хаты сөйләсен. Ул хатларны әниебез вафатыннан соң яшел сандыгыбыздагы изге Коръән-Кәрим китабыннан табып алган идем. Ул хатлар өлкәнәйгәч тә бөти урынына тагып йөртерлек. Хәтер бөтиләре... Алардагы сүзләрнең тәэсире көчле, догага тартым, борынгы язмалардагыча тыныч, мәңгелек. Әнә ич: «хатыным» димәгән, «якыным» дигән. Аралар чиксез ерак — хис, тою якын. Сагыну көчле, сагыш зур, наз чиксез.
Әхәт ГАФФАР

Сезгә сагынып.

Якыным Гайшә! Сиңа, матурым Әлфиягә вә иң-иң матурым Наиләгә, шулай ук миннән соң булган кечкенә бәбигә, кыскасы, барыгызга да сәлам. Ярый... Якыным Гайшә! Нихәл суң? Үзеңнең саулыгың бармы? Бәгырьләрем Әлфия, Наилә һәм кечкенә бәби саулармы? Мине, ягъни әтиләрен искә алалармы? Башка хәвеф-хәтәр юкмы? Суң, ризык мәсьәләсендә аптырамыйсызмы? Беләмен, бәгырьләрем, көн уздыруларыгыз ансат түгелдер. Ә инде ягу өчен утын мәсьәләгез, анысы, минемчә, юк инде. Нишлик суң, бер без генә түгел. Беләсең, хәтереңдәдер: безнең тормышның шөкер, бик рәхәт вакытлары бар иде. Беләсең, безнең бар нәрсә җитеш иде. Ул бергә-бергә балалар белән уйнашып, рәхәт гомер иткән вакытлар минем бер дә исләремнән чыкмый. Ярый, якыным Гайшә! Нигә суң миңа хат язмыйсыз икән? Менә мин 6 нчы аемны хәрби госпитальдә ятам. Сезгә ничә мәртәбәләр хат яздырып салдым. Ә сездән бер хат та алганым юк. Менә шул мәсьәлә минем өчен бик күңелсез. Әллә бертөрле хәл булдымы икән дип борчылам. Мин сугыш кырыннан ранный булып чыктым. 29 сентябрь көнне кич белән. Бу көн, 3 март көнне, минем ранный булганыма 156 көн, ягъни 5 ай да 6 көн.

Кайгылы хатым.

Якыным Гайшә! Сиңа, әгәр дә үлеп бетмәсәләр, матурым Әлфиягә, һәм – иң матурым иде – Наиләгә, бәлкем, бу көндә юктыр да, шулай да, нәни улым Аитка, барыгызга сәлам... Әй, якыным Гайшә! Синең 15 февральдә язган хатыңны алып укыдым, мәсьәләне төшендем. Эшләр шулаймыни? Ә укыгач нишләдем суң, – караватыма ятып аунап еладым, ризык ашамадым. Шулай итеп, синең кайгылы хатыңны алып укуы минем өчен җиңел булмады. Һәм минем дә сиңа кайгылы хат язуым җиңел булмады. Минем бу минутларым ничек суң, – яза торган кулым калтырый, ике күземнән канлы яшь ага. Үзебезне тәрбияли торган сестра, сиңа хат бар, Җаббаров, йә, тансавайт ит, юкса хатыңны бирмим, диеп, шул арада сөенечемнән сикерә-сикерә биегән булып, бөтен иптәшләр көлешеп карап торып, суңра сестра маладис, Җаббаров дип, синең кульязмаңны биреп, мин сөенә-сөенә укый башлаган идем, чишмә кебек, ике күземнән яшь ага башлады. Шуннан караватка ятып, одеал белән бөркәнеп бик озак еладым. Әй... Гайшә! Шулай ук ул безнең матурларыбыз әрәм булырлармени? Әлфиям һәм Наиләмне күргән идем, әнә шул минсез булган кечкенә йөрәк бәгърем – 2 нче Аитны күрми калам микәнни?

(Хатлар кыскартылып бирелә.)

Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2011 елның 23 мартында «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы ПИ № ФС 77-44363




2007, 2008, 2009 елларда журнал Россия матбугатының Алтын фондына кертелде.

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте
Казан, Академия урамы, 2.





Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Нурия Беломоина, Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова



Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламалар аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова
Pre-press:
Игорь Глушков
Тышлыкта:
Надежда Имаметдинова
Фото: Газинур Хафизов

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Роза Камалетдинова
Асия Юнысова
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Нәшер итүченең адресы: Казан, Академия урамы, 2, ААҖ «Татмедиа».

Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Күләме 8 басма табак.

Басарга кул куелды: 25.02.2015 ел.
Заказ О-457.
Тираж 7838

ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы булышлыгы белән гамәлгә куелды

Журналны тарату мәсьәләләре белән абунәчеләр – җирле элемтә бүлегенә; элемтә бүлекләре – нәшриятның газета-журнал экспедициясенә (420066, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. Тел.: 562-10-66) мөрәҗәгать итә ала.

Банк реквизитлары:
Филиал ОАО «Татмедиа»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Журналда полиграфия кимчелеге булган очракта нәшриятның техник контроль бүлегенә мөрәҗәгать итегез. Тел.: 519-44-61.

Сату бәясе – килешү буенча.







Анастасия Бузенеева эше

Илсөяр ИКСАНОВА

Мин – хатын-кыз

Каурый болыт булып күккә аштым,
Тамчы булып тамдым гөлләргә.
Йә, кемнәрнең җаны кипкән иде,
Җылы яңгыр кирәк кемнәргә?

Язгы үлән булып күтәрелдем,
Яфрак булып шыттым бөредән, –
Йә, кемнәрнең ачылмаган язын
Ак кыраулар сугып өлгергән?

Ал таң булып кундым офыкларга
Һәм көн булып төштем өзелеп.
Шагыйрь, диеп сокландылар бар да –
Мин хатын-кыз идем иң элек!

Ленар ШӘЕХ

Бу язларны сиңа бүләк итәм...

Бу язларны сиңа бүләк итәм,
Ул язларга сыйган барсы да –
Мәхәббәт тә, күңел сафлыгы да,
Җанны эретерлек ярсу да.

Бу язларны сиңа бүләк итәм,
Ул язларда яшәү моңы бар.
Күктән тамган тамчы чыңнарында
Сөенеч һәм бәхет тыны бар.







БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





16 ЯКТЫ ӨМЕТ
Л. Гәрәева

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8 СВЕТЛАНА ЗАХАРОВА: ТАБИБ. ДЕПУТАТ. ХАТЫН-КЫЗ...
Ч. Әхмәтова



20 «ҖИҢМӘСӘМ, ЙӨРМИМ ДӘ!»
М. Авзалова



12 БЕЗ БИТ ДӨНЬЯ ТОТКАСЫ!

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



24 ҖАН ӨЗДЕРГЕЧ МОҢ БУЛЫП...
Р. Камалетдинова



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 

26



ПАРТИЗАН КЫЗ ЧӘЧКӘ
Ч. Заһирова

ЯШӘЕШ 

40



ДИҢГЕЗ КИЧКӘН БӘХЕТ...
Г. Сафиуллина

46



КЫРАЛАК ӘНИ
Л. Гәрәева

ШУЛАЙ УК: 

СӘЙДӘ, СЫЕРЧЫК ҺӘМ ЯЗ
Г. Әдһәм
32

БАЛАСЫЗ БАЛ АЕ
С. Гаффарова
50

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

58



ӘНӘ ДӘ БҮЛӘК, ӘНӘ «МЕНДӘРЕ» ДӘ...

ҺӘР САНЫБЫЗДА: 

БЕЗНЕҢ ПОЧТА 6
ДӨНЬЯ ГАМЕ 23
ШИГЪРИЯТ 30
БЕР ҖЫР ТАРИХЫ 38
РӘССАМ СӘХИФӘСЕ 64







Бу хатымны Арчаның «Казан арты» тарихи-этнографик музеенда уздырылган кичәдән кайткач яздым. Журналист, язучы, шагыйрь Галимов Дамир Каюм улын искә алу кичәсе иде ул.

Үземнең Дамир абый турында берни дә белмәвемә шаклар катып кайттым. Югыйсә Арча педагогика көллиятенең III, IV курсларында укыганда ул безнең сыйныф җитәкчесе булды, балалар әдәбиятыннан укытты, музыка дәресләре алып барды. Без аны үзебезнеке итеп, шулай булырга тиеш кебек кабул иткәнбез. Ә искә алу кичәсендә Дамир абыйны (без аны бик якын итеп Дамир абый дип йөртә идек) бөтенләй яңа яктан ачтым. Ул район газетасында журналист булып та эшләгән, авыл мәктәпләрендә укыткан, китаплар да язган. Җәй саен, студентларны туплап, Азин эзләре буйлап сәяхәткә алып чыккан. Шушы сәяхәтләрнең нәтиҗәсе буларак, «Кызыл шарф» китабы дөнья күргән. Ә бит ул бөтенесенә дә үз көче белән ирешкән. Алты яшендә ятим кала ул. Әтисе Каюм абый сугыш кырларында һәлак була. Әнисе Асылбикә апа кулында биш бала өелешеп калалар. Сугыш ятимнәренең күргәннәрен кем санап бетергән... Арча педагогика училищесына укырга кергән, армиягә барып кайткан, укыткан. Училище коридорлары, Арча урамнары буйлап төз, мәһабәт гәүдәле, ташып торган болыт чәчле матур кеше булып йөри иде ул. Иде дим... Училище яңа бинага күчкәч, Дамир абый башлангыч хәрби хәзерлек дәресләрен укыта башлый. Ату дәресләре өчен тир ачтыра. Фаҗига шунда була да инде. 1987 елның 30 апрелендә, ату дәресендә, бер кызның пулясы Дамир абыйның умырткалыгына барып тия. Өрлектәй гәүдәле 42 яшьлек ир урынга кала. Шул хәлендә 6 ел да 6 ай ята. Тормыш иптәше Сания апа гел аның янында була. (Сания апа белән Дамир абый ике ул үстерде. Искәндәрләре – Арча хастаханәсендә, Таһирлары Йошкар-Олада – табиб. Дамир абый әле оныкларын да күреп өлгерде.) Ул гел өметләнеп ятты. Шигырьләр яза башлады. Көчле рухлы, корыч ихтыярлы булып яшәде. Мин аның янында соңгы тапкыр 1988 елда булдым. Училище хәлләрен сөйләштек. Авыруы турында бер сүз әйтмәде. Менә шундый кеше иде ул безнең Дамир абый. Фаҗигале язмышлы, әмма безнең күңелләрдә Арча урамнары буйлап горур кыяфәт белән алга бара торган булып калды. Үзенең язмышы турында болай дигән ул:

Җиңел юлдан кем дә уза ала,
Ә син упкыннардан узып бак!
Түзәрдәйгә кем дә түзә ала,
Түзәлмәстәенә түзеп бак!
Оныттылар, диеп җан әрнесә,
Чын дусларым бар дип тынычлан.
Дуслар булса, исәп бирешмәскә –
Алга үрмәләргә тырышам.

Мөслимә НИЗАМОВА.
Арча.

Узган елның салкын, моңсу көзендә 52 ел бергә гомер иткән иремнән мәңгелеккә аерылдым. Әйтеп аңлаталмастай авыр көннәр кичерәм. Күздән яшем кипми, авыздан ризык үтми. Күз алдымда гел ул – Рафаэлем. Ярты гасыр бергә яшәгән ирем белән узган гомернең һәр көне бер-бер артлы күз алдымнан үтә.

Беренче һәм гомерлек мәхәббәтем иде ул. Сугыштан соңгы авыр елларда Әгерҗе банкына эшкә урнашкач таныштык без. Өч ел дуслашып йөрдек. Ул мине бер күрү белән үзенә тәгаенләп куйган булган. 1962 елның июлендә эшемә керде дә: «Бүген күлмәгең дә матур икән. Әйдә, паспортыңны ал да ЗАГСка киттек», – ди. Ул заманнарда туйлар итеп торырлык түгел иде шул хәлебез. Бер дә икеләнмичә, риза булдым. 21 яшендә гарипләнеп калганын белсәм дә, курыкмадым. Бу чир аның холкын да бозган иде: тиз кызып китә, әмма тиз үк суына да. Танышбелеш: «Кызган тимер кебек бит ул, ташла, бәхетле булмассың», – диләр иде. Мин үзем бик сабыр, юккабарга тавыш куптаруны җенем сөйми. Шуңа күрә тату тордык.

25 квадрат метрлы бүлмәгә килен булып төштем. Монда кайнатам белән кайнанам да яши иде әле, кечкенә генә бүлмәдә бергә гомер иттек. Параличланып урынга калган кайнанамны биш ел карадым. Кайнатама да инсульт булды.

Өч бала, ике якта ике авыру. Төне буе кер уып, аларны бәкегә төшеп чайкап, иртәгәсе өчен ашарга пешереп, керфек кагарга өлгермәгән төннәрем еш була иде. Зарланмадым, авырсынмадым. Мәңгелеккә күзләрен йомар алдыннан кайнатам, телен чак әйләндереп: «Кайчак гаепләгән булсак, гафу ит, кызым. Әйбәт килен булдың, улыбыз белән озын гомер ит. Картлыгыгыз матур булсын!» – диде.

Рафаэлем озак еллар җитәкче урында эшләде. Җитәкче хатыны булуның җиңел түгеллеген үз башына төшкән кеше генә аңлый. Эштән соңарып, салгалап кайткан чаклары да булды. Нахак сүзләрен дә ишеттем, тешемне кызып түздем. Ышанасызмы, юкмы, беркайчан да каршы дәшмәдем мин аңа. «Кайда, нишләп йөрдең?» – дип сорамадым. Нинди хәлдә генә кайтып керсә дә, елмаеп каршы ала, ашатып урынга яткыра торган идем. Гаилә учагын сүндерми саклау өчен барысын да эшләдем. Беркайчан да, беркемгә дә тормышымнан зарланмадым. Кайберәүләр килешмәс. Шулкадәр ачу килгәндә, ничек инде эндәшми калып була, диярләр. Без бит сугыш чоры балалары. Авырлыклар сабырлыкны чарлый икән ул.

Бүгенге яшь ханымнарны да сабыр булырга чакырам. Ирләр алар сабый бала кебек. Аларга хатын гына түгел, үз әниләре кебек, кайгыртучан ана да була белергә кирәк. Балаларга да әтиләренең кирәкле, акыллы кеше булуларын, гаиләнең туендыручысы икәнен гел тукып торыгыз. Ирне ир итеп яшәсәгез генә гомерегез тату, матур узар. Мин бик бәхетле хатын булып яшәдем. Мактанып әйтмим, әмма бу – минем сабырлыгым әҗере. Иремне югалту бик авыр. Әмма минем шатлыгым, таянычым булырдай өч кызым, оныкларым бар. Картайган көндә шулар бәхет түгелмени? Дөньядагы һәр хатынкызга бәхетле хатын, кадерле әни булырга язсын.

Римма ЯППАРОВА.
Әгерҗе шәһәре.

Мин Мөслим районы Күбәк авылында гомер итәм. Шушы авылда без биш туган туып-үстек. Абыебыз гына ике ел элек вафат булды, калганыбыз – дүрт кыз – исәннәр.

Яшь чагымда мәктәпне тәмамлап, Казанга тегүчеләр әзерли торган училищега укырга кердем. Тормышта бик кирәкле һөнәр булды ул, балалар, туган-тумачалар мин теккәннәрне киеп куанды. Училищены тәмамлап, 1 нче тегү фабрикасына эшкә урнаштым. Шунда Халисә исемле кыз белән дуслашып киттек. Тырышып эшләдек. Берсендә «Ватаным Татарстан» газетасына мактап язып та чыктылар. Моның өчен иң нык куанган кеше әни булгандыр. Куанмыйча? Кызын газетага язсыннар да!

Эшемне яратсам да, авылымны өзелеп сагына идем. Мөслим белән Казан арасы ерак бит. Ул чорларда бүгенгедәй җилдереп кенә барыпкайтырмын димә. Мин кунакка кайткан саен, әнием күз яшьләре белән елый. Түзмәдем, авылга кайтып киттем. Бөгелмәдә лаборантлар әзерли торган училищеда укып, үзебездәге май заводына урнаштым. Кайтканыма бер дә үкенмәдем. Авылдашым Илшат белән гаилә корып җибәрдек, балалар туды. Алар үсте, үзләре әти-әни булды. Алла боерса, дүртенче оныгыбыз туарга тора.

Балалар таралышкач, бик ямансу була икән. Ирем белән уйлаштык та, тәрбиягә бер малай алдык – Русланны. Без аны сигез ел тәрбияләдек. Быел унберенчене тәмамлап, КФУның механика-математика факультетына укырга керде. Гел шалтыратып, хәл белешеп, рәхмәт әйтеп тора. «Сагынам», – ди. Үзебез дә сагынабыз. Бик матур җырлый иде (25 чакрымдагы Мөслимгә музыка мәктәбенә укырга йөрттек), университетның хорына йөри башлаган. Руслан киткәч, ямансу булыр дип, тагын бер малайны – Рамилне алдык. Аны алганыбызга февральдә ике ел булды. Әйбәт кенә укып йөри, гаилә тормышына ияләнә.

Язгач-язгач, үземнән ике яшькә олы апам Мәүлиева Рәмзилә турында да языйм әле. 1980 елда Мөслим районы Яңа Сәет авылына килен булып төште ул. Җизнәбез Таһир бик акыллы, булган егет иде. Апам, төп йорт килене буларак, кайткан-киткәнне кунак итеп, мунчасын ягып, ачык йөз күрсәтеп яшәде. Бераздан яңа йорт салып керделәр, өч балалары туды. 1999 елны колхоз басуында чөгендер алып, җир җимертеп эшләп йөргән җиреннән җизнәбез үлеп китте. «Йөрәк», – диделәр. Олы кызларының мәктәпне генә тәмамлаган елы, Айзилә белән Айдар мәктәп балалары. Апам хәр күңелле. Шулай булмаса, язмышның ялгыз хатын иңенә өйгән авырлыгына чыдамас иде. Авыл кешесенең тормышы тоташ мәшәкать бит аның. Мал-туары, кош-корты, бакчасы, тәзәтәсе-кагасы... санап бетерерлек түгел. Болар өстенә колхоз эше тагын. Фермада апам эшләмәгән бер генә эш тә калмагандыр. Быел аның килен булып төшкәненә – 35 ел. Шул еллар дәверендә кодагыебыз Гайникамал белән дус-тату яшәделәр. 2015 елның 15 гыйнварында кодагыйга 100 яшь тулды, ноябрьдә апама 55 тула. Кодагый гомер буе апага ярдәм итеп, тормыш йөген тартышып барды. Ул әле дә җитез, булган, күз тимәсен, зурлап юбилеен үткәрдек. Апам бик матур җырлый безнең. Җыр аның гомерлек юлдашы булды. Җыр һәм гөлләр... Гөлләр үстерергә дә бик ярата ул. Аларның йортын тәрәзә төбендәге гөлләреннән танырлык. Гөлле, ашлы, ачык ишекле, уңган хуҗалы йорт ул апамнар йорты. Гел-гел шулай булсын иде.

Ризилә ВӘЛИЕВА.
Мөслим районы, Күбәк авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: suyumbike@telebit.ru


Фото: Газинур Хафизов

СВЕТЛАНА ЗАХАРОВА: ТАБИБ. ДЕПУТАТ. ХАТЫН-КЫЗ...



Чулпан ӘХМӘТОВА

Светлана Михайловна Захарова – Татарстан парламентының Социаль сәясәт комитеты рәисе, Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшерү комиссиясе җитәкчесе. Депутатлыкка «Бердәм Россия» сәяси партиясе исемлеге буенча сайланган.
Һөнәре буенча – табиб, медицина фәннәре кандидаты. Ике бала анасы: Дмитрий Казан дәүләт техник университетының беренче курсында укый, кызы Динәгә – 9 яшь.
Сокландыра торган хатын-кызлар – Индира Ганди, Маргарет Тэтчер, Софья Ковалевская, Валентина Матвиенко.
Киенү стиле – классика, спорт киемнәре.
Укый торган китаплары – медицинага кагылышлы әдәбият.
Өстәл китабы – Лев Толстой, «Анна Каренина».

Светлана Михайловна, парламентка даими нигездә эшләүче депутат булып килердән элек, Сез Чаллы поликлиникасының баш табибы вазыйфасын башкаргансыз. Социаль сәясәт комитетын җитәкләргә тәкъдим булгач кичергән хис-тойгыларыгызны хәтерлисезме?

– Ничек кенә хәтерлим әле... Комитет алып барырга тиеш булган эшләр белән танышканнан соң утырып еладым. Минем урында кайсы хатын-кыз еламас иде икән? Күз яшьләремне агызып күңелемне бушатканнан соң, җиң сызганып эшкә тотындым. Комитетның эше закон проектлары әзерләү һәм Татарстан Республикасы законнарының, норматив хокукый актларының үтәлешен тикшереп тору гына түгел. Без сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт, туризм, хезмәт мөнәсәбәтләре, халыкны эш белән тәэмин итү, хезмәтне саклау, гражданнарның аерым категорияләрен социаль яклау һәм социаль тәэмин итү, гаиләне, аналарны, аталарны һәм балаларны саклау, демографик һәм яшьләр сәясәте һәм тагын бик күптөрле эшләр белән шөгыльләнәбез. Әлбәттә, бу темалар минем өчен ят түгел, чөнки Дәүләт Советына депутат булып сайланганчы Чаллы шәһәре советында ике чакырылышта депутат булдым, социаль юнәлештә эшләдем.

Сез сәясәткә шактый яшьтән кереп киткәнсез...

– 1999 елда беренче тапкыр депутат мандатын алганда миңа 27 яшь иде. Ул чакырылышта 40 яшькәчә булган бердәнбер депутат. Мин депутатлыкка, сәясәткә керәм дип түгел, үзем табиб булып эшләгән участоктагы башлап ташланган поликлиниканы төзетеп бетерүдә файдам тияр дигән уйдан чыгып, коллегаларым белән киңәш-табыш иткәннән соң килдем. Безнең 4 нче поликлиника шәһәрнең иске бер бистәсендә урнашкан иде. Күп катлы йортның ярымподвалында. Бер көнне безне су басты. Өске катта авария булган. Без – табиблар, авыруларны кабул итәргә тиеш вакытта су җыеп йөрдек. Шул вакытта тәмам йөрәгем сыкранды. Болай булырга тиеш түгел бит! Кешенең иң кыйммәтле байлыгы булган сәламәтлекне саклауга караш мондый булырга тиеш түгел! Коллегаларым белән киңәшләштек тә, мин депутатлыкка чыгарга булдым. Көндәшем зур бер предприятиенең генераль директоры иде. Сүзе үтә, акчасы җитәрлек, командасы зур. Һәм мин – участок табибы, акчаны күргән дә юк, хезмәт хакын да тоткарлап кына бирәләр, командам – бергә эшләгән табиблар. Мин үз пациентларыбызның теләктәшлегенә өметләндем һәм ялгышмадым. Ике турда узган сайлауларда көндәшемнән 5 тавыш артык җыйдым. Шуны аңладым, безнең эшебезне халык бәяли икән бит. Кайвакытта үз һөнәреңә карата начар сүзләр дә ишетәсең, эшең бәяләнми кебек тоела, күңел дә төшеп китә. Әмма әлеге тиңдәшсез көрәштә җиңеп чыкканнан соң, шуңа тагын бер кат инандым – халык табибларның эшен күрә!

Без туксанынчы елларда поликлиника каршында хатын-кызлар, ирләр, балалар сәламәтлегенә кагылышлы аерым мәктәпләр оештырган идек. Мәсәлән, климакс чоры җиткән хатын-кызларга үз сәламәтлекләрен ничек кайгыртырга? Хәзер инде интернет бар, күп сорауларга җавапны аннан табарга була. Әмма компьютер аша мәгълүмат алу да белгеч белән күзгә-күз карап сөйләшүне алыштыра алмый. Без хатын-кызларны аерым бер вакытка чакырабыз, табиб лекция укый, киңәшләрен бирә. Ирләрнең дә үз проблемалары. Яшь әниләр өчен мондый аралашулар кирәк тә кирәк инде. Шулай итеп, без үз тирәбездә яшәүчеләрне поликлиникага җәлеп итеп, аларны чирдән ничек дәваланырга гына түгел, ә авыруны булдырмас өчен нәрсәләр эшләргә кирәклеген өйрәтә идек. Хәзер мондый профилактика республика күләмендә алып барыла.

- 2014 елда Татарстанда демографик күрсәткеч шатландыра, 8200 кешегә артканбыз. Бу уңайдан шуны да әйтергә кирәк, республика күләмендә диспансерлаштыру уздыру да үзенең уңай нәтиҗәсен бирде.
- Авылларда сәламәтлек саклау өлкәсенә игътибар артты. Узган елда бу тармакка казна 2,3 млрд. сум акча бүлеп бирде. 2014 елда 78 фельдшер-акушерлык пункты төзелде, 252 ФАПка ремонт ясалды.
- Узган җәйдә башкалабызда Анжела Вавилова исемендәге иганә фонды инициативасы белән Балалар хосписы ачылды. Аны төзү өчен 121 млн. сум акча тотылды, шуның 70 млн. сумы – хәйрия акчасы.
- 2014 елның маенда Казанда Республика кан үзәге ачылды. Бу – Россиядә иң заманча үзәк, елына 30 000 литр тирәсе донор каны әзерләнә.
- Казанда калкансыман биздәге яман шешне радиоактив йод ярдәмендә дәвалый торган радионуклид терапияcе бүлеге ачылды.
- Кадрлар кытлыгын хәл итү максатыннан хөкүмәт шундый программа эшләде – дәүләтнеке булган медицина учреждениеләренә (хастаханәләргә, поликлиникаларга) эшкә урнашучы табибларга фатир мәсьәләсен хәл итү өчен 500 мең сум акча бирелә. Бу программа нигезендә ике йөзләп табиб эшкә керешә инде, шуларның 133 е Россиянең башка регионнарыннан килгән. Авыл җирләрендә эшли башлаган «земский врач»ларга 1 миллион сум акча бирелә.
- Кадрлар, нигездә, Казан дәүләт медицина университетында әзерләнә. Моннан тыш, Казан федераль университетының медицина факультетында 50 студент «дәвалау» белгечлеге буенча максатчан программа нигезендә белем ала. Әлеге белгечләр, укып бетергәннән соң, биш ел дәвамында республика сәламәтлек саклау оешмаларында эшләргә тиеш була.

Депутат булып сайлангач, поликлиниканы төзеп бетерә алдыгызмы?

– Без ул эшне башкарып чыктык. Әмма депутат булып эшли башлагач, социаль юнәлешнең медицина белән генә чикләнмәвен аңладым. Тормышта үзенә игътибар сорый торган өлкәләр шактый күп, алар кичектергесез икән бит. Депутат буларак миңа күптөрле сораулар белән киләләр. Кемнеңдер торыр җире юк, кемгәдер эш кирәк, сәламәтлек саклауга кагылышлы гозерләр дә бик күп... Тагын шунысы да бар, кайбер мәсьәләләр киң катлам кешеләргә кагылышлы булып чыга, бер кешенең мөрәҗәгатеннән чыгып башланган эшне хәл итеп, без күпләр проблемасын чишәбез. Аерым мәсьәләләр дә шактый һәм аларга барлык очракларда да булыша алам дию алдашу булыр иде. Әмма беркайчан да сиңа гозер белән килгән кешене үз проблемалары белән урамга чыгарып җибәрергә ярамый. Кайвакытта, мәсьәләне уртага салып сөйләшкәндә, аның дөрес куелмавын да аңлатып була. Кайчакларда бер утырып сөйләшү дә кешенең күңелен күтәреп җибәрә, аңа көч бирә.

Татарстан парламентына депутатлыкка кандидат булып чыкканда Сез сәяси тормышта кайнаган, шактый чыныккан шәхес булгансыз...

– Мин ул вакытта поликлиниканың баш табибы идем. Эшем җайга салынган, гаиләм түгәрәк, ике балам үсеп килә... Бәлки, минем бу адымымны аңламаучылар да булгандыр. Әмма кешенең геннарыннан килә торган лидерлыкка омтылу сыйфаты аңа ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнеп калырга ирек бирми, һаман да күңелен җилкетеп тора. Мин Арыслан йолдызлыгында туганмын. Мөгаен, бу фактор да тормышыма үз йогынтысын ясамый калмыйдыр. Кечкенәдән оештыручы идем. Гаделлеккә омтылу, дөреслекне табарга тырышу кебек сыйфатлар миңа мул бирелгән. Мин кеше ярдәменә өмет итә торган затлардан түгел, мин ярдәмне үзем күрсәтергә тиеш! Мөгаен, болар барысы бергә миңа табиб һөнәрен сайларга этәргеч биргәндер. Хәер, әнием Линуза Нестеревна – табиб, ул мине һәрвакыт үзенең дәвамчысы итәргә теләде. Ләкин мин хыялымда үземне укытучы, тикшерүче итеп тә күрә идем. Әнием минем бу теләкләремә каршы килмәде, әмма, табиб булу өчен аеруча тырышып укырга кирәк шул, анда укулар бик авыр, дия торган иде. Бу исә минем минминлегемә тия, үземнең булдыра алганымны исбатлыйсым килә иде. Аннан соң тормышымдагы бер очракны хәтерлим, миңа 12-13 яшь булгандыр, әни командировкада иде, төнлә әбиебез авырып китте. Кан басымы уйный, берничек тә ярдәм итә алмыйбыз. Ашыгыч ярдәм чакырдык. Шул вакытта үземнең бик тә көчсез булуымны тойдым.

Сез әниегез юлын дәвам иткәнсез. Сезнекен дәвам итүче булырмы?

– Улымның табиб булуын бик теләгән идем. Үзенең дә нияте бар иде кебек. Әмма һөнәр сайлау вакыты җиткәч, «минеке түгел» диде. Инде өметем Динәдә. Кечкенә булса да, күп кенә даруларны белә, авырулар белән кызыксына. Аннан соң кызымны кечкенәдән әбисе карады, аның йогынтысы көчле булды. Мин декрет ялларында озак утырмадым, ике атнадан эшкә чыктым. Бала табарга да эш урынымнан киттем дияргә була...

Светлана Михайловна, табиб нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

– Табиб гомере буе укырга, өйрәнергә тиеш. «Укырга! Укырга! Укырга!» дигән сүзләр табибларга атап әйтелгән кебек. Чөнки бүген технологияләр бик алга китте, алар тиз арада яңарып торалар, һәм бик күп яңа төр авырулар барлыкка килде. Табиб мәрхәмәтле, игелекле һәм таләпчән булырга тиеш. Авыру кеше үзен бик кызгана, бик ярата, әгәр таләпчән булмасаң, ул табиб кушканнарны үтәмәскә дә мөмкин. Табиб та кешеләрне яратырга тиеш. Аларның күңелләренә юл табарга, тереләчәгенә ышаныч тудыра белергә тиеш. Һәрбер отличник табиб була алмый!

«Мин кеше организмын өскә кигән кием белән тиңлим. Без киемне каралган саен юабыз, үтүклибез, сүтелеп китсә – тегәбез, тишелсә – ямыйбыз. Әгъзаларыбыз эчтә, әмма алар да пычрана, туза, тишелә. Аларны да киемне пөхтә тоткан кебек карап, саклап тотарга кирәк. Ярый ла, киемне алыштырып була. Әгъзалар исә безгә гомергә бер генә бирелә. Аларга аеруча игътибарлы булырга тиешбез. Кеше шуны аңламый, сәламәтлеген саклау өчен тырышмый икән, табиб үзе генә берни эшли алмый. Мин үз пациентларыма шул хакыйкатьне аңлатырга тырыша идем.»



Бүгенге көндә халыкка медицина ярдәме күрсәтүдә нинди кичектергесез проблемалар бар?

– Әлбәттә, сәламәтлек саклау тармагында хәл ителәсе мәсьәләләр шактый, безнең комитет аларны һәрдаим күз уңында тота. Мәсәлән, инвалидларга яшәү, сәламәтлекләрен кайгырту, уку, эшләү, күңел ачу өчен уңайлы мохит тудыру. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү өчен кабул ителгән «Уңайлы мохит» программасы үтәлешен тикшергәндә кайбер кимчелекләргә тап булдык – биналарны проектлаштырганда һәм аны тапшырганда инвалидлар өчен уңайлы мохит тудырырга дигән таләпләрне үтәүнең катгый системасы юк, проектлаштыручылар арасында бу аспектны исәпкә алып эшли белүчеләр дә бармак белән генә санарлык. Бу мәсьәләгә җәмгатьчелек тә битараф түгел, теләсә кем гарипләнергә мөмкин. Бу программаның ничек тормышка ашырылуын һәрдаим күзәтеп барачакбыз.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә яман шеш белән авыручыларның артуы бик борчый. Диспансерлаштыру вакытында бу төр авыруларның беренчел стадиядә билгеле булулары аларга тиз арада ярдәм күрсәтү мөмкинлеген тудыра, әлбәттә. Бу очракта аларның күбесен тулысынча савыктырырга мөмкин. Әмма бу авыру бик тиз арада тулысынча дәвалауны таләп итә. Авырткан аяк белән сызлана-сызлана булса да яшисең әле ул, ә бу чир белән озак тарткалашып булмый. Әлбәттә, бу өлкәдә дә медицина үсештән туктап тормый. Башкалабызда атом-төш (Центр ядерной медицины) дәвалау үзәге ачылды. Әмма шунысына да күз йома алмыйбыз, республика онкодиспансерында тикшеренү, химия терапиясе курсларын үтү өчен чиратлар барлыкка килде. Инде Чаллы, Әлмәт кебек шәһәрләрдә дә бу төр дәвалау үзәкләрен ачу, булганнарын киңәйтү сорала. Белгечләр бар, махсус биналар кирәк. Мәсьәләне якын арада комитет утырышына чыгарырга ниятлибез. Безне ишетерләр дип өметләнәм.

Светлана Михайловна, безнең җәмгыятьтә хатын-кызның төп проблемалары нинди? Аларны чишәргә нәрсә комачаулый?

– Без соңгы елларда аерым социаль яклауга мохтаҗ кешеләргә – ятим балаларга, күп балалы гаиләләргә, ялгыз аналарга, гомумән, тормышы китек булганнарга игътибарны арттырдык. Бу кирәкле гамәл. Әмма гап-гади тормыш алып баручы традицион гаиләләр, ничектер, бер читтә кала бирә. Алар күзгә-башка ташланмыйча үз көйләренә матур гына яшиләр, эшлиләр, балалар тәрбиялиләр... Шундый гаиләләр илнең терәге бит. Без аларны күрергә, җәмгыятьтә аларның мөһимлеген һәрдаим сөйләп торырга, үрнәк итеп күрсәтергә, яшь буынны алар мисалында тәрбияләргә тиешбез. Аларның да проблемалары бар, алар аны сөйләп йөрми, үзләре хәл итәргә тырыша.

Гаиләдә авыр хәлдә калган хатын-кызның иң зур проблемасы – китәр җире булмау. Алыйк исерек ир белән торган ике балалы хатынны. Ул бу ирдән бүген китәр иде, барыр җире юк. Аны кайда көтеп торалар? Ярый ла, барып сыенырга аны аңлаучы ата-анасы, туганнары булса... Бездә психологик ярдәм күрсәтү үзәкләре эшли, әмма анда барып кунып калып булмый. Бездә, хәтта, бомжларны кундыру үзәкләре бар, әмма төн уртасында исерек ире куып чыгарган хатынга кунып чыгар урын юк. Каядыр китеп эш табып, фатир табып яши башлаганчы барып баш куяр урын юк. Без бу хакта депутат хатын-кызлардан торган «Мәрхәмәт» берләшмәсендә сүз башладык, ниндидер бер чишелеш табылыр дип уйлыйм.

Югары дәрәҗәләргә ирешкән хатын-кызларга беркадәр саграк, хәтта, әйтер идем, шикләнебрәк тә карыйлар. Ир-егетләр дә дистанция сакларга тырыша...

– Шулайрак шул... Эшлекле костюм кигәч, сине хатын-кыз дип уйлаучылар кими. Югыйсә эшлекле хатын-кызлар башкалардан әллә ни аерылмый инде. Өйгә кайткач, халат кияләр, ашарга пешерәләр, савыт-саба юалар. Мин атнага алты көн эшлим, якшәмбене тулысынча балаларыма багышларга тырышам.

Еш кына Чаллыга әти-әни янына кайтып киләбез, туганнар белән аралашабыз. Безнең гаилә бик дус, тату. Һәм, әйтергә кирәк, катнаш гаилә. Минем әнием татар, әтием рус милләтеннән. Әнинең әнисе Хәят һәм карт әби гел безнең белән яшәделәр, безнең белән татарча гына аралаштылар. Карт әби биш вакыт намаз укый торган карчык иде, белгән кадәр догаларны ул өйрәтеп калдырды. Ислам диненә тартылуыма балачактан ишетеп үскән шул догалар сәбәпче булгандыр дип беләм. Хәер, әнием дә мөселманча йолаларны үтәп яшәргә тырыша. Ул әтинең әнисе – бабушкага карата да бик мәрхәмәтле, яхшы килен булды. Бабушка чиркәүгә йөри иде. Шуңа күрә мин милләтара, динара ыгы-зыгыларны аңлый алмыйм, бер-берең белән килешеп яшәү өчен мондый аерымлыклар киртә була алмый. Язмышым шулай булгандыр, мин дә рус егетен яр иттем. Балаларымда ике телгә карата да тигез мәхәббәт тәрбияләргә тырышам.

Ике телне дә белүем миңа табиб булып эшләгәндә дә бик ярдәм итте. Татар карчыклары яратып, Светлана кызым дип дәшәләр иде. Чынлыкта, сер итеп кенә әйткәндә, минем мулла кушкан исемем – Гөлчәчәк.

Хатын-кыз, ничек кенә көчле булмасын, янында үзеннән көчлерәк иңнәр тоярга тиеш. Без, нинди генә дәрәҗәләргә ирешсәк тә, барыбер ир-егетләр ярдәменә, аларның игътибарына мохтаҗ. Безгә Аллаһ тарафыннан бирелгән төп миссия – гаилә кору, сәламәт, инсафлы балалар табып үстерү. Лидерлыкка омтылган кызлар колагына шуны әйтәсем килә: кияүгә чыгуны соңга калдырмагыз! Эш бәхете – бер бәхет, гаилә бәхете – тулы бәхет! Без дөньяга бәхетле булыр өчен туган!























Фото: Марат Хәялетдинов, Газинур Хафизов

БЕЗ БИТ ДӨНЬЯ ТОТКАСЫ!

Тышта әле салкын кыш, февраль аеның үзәккә үткән ачы җилләре... Тик шулай да күңелдә инде әкрен генә уянып килгән яз җылысы. Хатын-кызның бәеклеген, гүзәллеген, күңел чисталыгын дөньяга ишеттерүче «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесендә алган тәэсирләребез, бәлкем, шулай итәдер. Әлеге чарага йомгак ясалып, хатын-кызлар бәйрәме алдыннан җиңүчеләрнең исемнәрен дөньяга яңгыратканчы, ул әле башта зона буенча бара. Бәйгене оештыручылар – «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы, Татарстан Республикасының Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил аппараты һәм Татарстан профсоюзлары. Бу юлы да Азнакай, Яшел Үзән, Лаеш, Алексеевск, Алабуга, Чаллы төбәкләрендә уздырылган бәйгедә барлыгы 41 район һәм Казан шәһәренең иң шәп вәкилләре катнашты. Кемнәр генә юк икән арабызда!

Яшел Үзән

Дистәләгән еллар дәвамында барган бу бәйге безне яңа исемнәр, яңа язмышлар, яңа тарихлар белән хәйран итә килә. Хәзер ул исемлеккә кемнәр өстәлер, гүзәл затларыбыз тагын кайсы яклары белән ачылыр?!

Яшел Үзән шәһәренең музыкаль театр бинасында башланып киткән тамашаны күзәтә-күзәтә, бәйгенең мәгълүмати спонсоры вәкиле буларак, жюриның башка әгъзалары белән янәшә утырып, сорауларыма җавап эзлим.

– Бу – безнең күңел бәйрәме һәм без аны шулай кабул итик тә, – диде зона ярышларын ачып җибәреп, Яшел Үзән муниципаль районының Башкарма комитеты урынбасары, районның халык мәгарифе бүлеге җитәкчесе Раиса Афанасьева.

Бирегә җыелган Апас, Буа, Югары Ослан, Чүпрәле, Яшел Үзән, Кама Тамагы, Кайбыч, Тәтеш, Теләче муниципаль районнары вәкилләре – хатын-кызларыбызның иң-иң шәпләре, уңган-булганнары, хәтта җитмеш төрле һөнәр үзләштерүне дә авырыксынмаганнары бәйгене, чыннан да, зур бәйрәмгә, олы тантанага әверелдерде.

Ул, елдагыча, «Хатын-кыз – ана» номинациясеннән башланып китте. Сәхнәгә күтәрелгән әниләребез Ирина Шубина-Мордовченко (Яшел Үзән) белән Резеда Сабирҗанова (Кама Тамагы) – ятимнәргә гаилә җылысы, ана назы, ана мәхәббәте бүләк иткән олы йөрәкле, тәвәккәл ханымнар... «Бәхет ни ул дисәләр? Бәхет – шушы балаларым, кеше булып җитсәләр», – дип бөтен теләген шигъри юлларга салып әйтеп биргән, үзенең дүрт баласы янына биш ятимне сыендырган Резеда ханым һөнәре буенча укытучы да икән әле. Бәхетне, чын бәхетне менә шулай бала тәрбияләүдә күргән олы җанлы әниләребез бик күп безнең. Әлеге номинациядә алар җиңүче дип танылды.

«Хатын-кыз – ел үрнәге» номинациясендә беренче булган Тәтеш кызы Лилия Вәлиеваның муенындагы дистәләгән медальләрен күргәч, зал аны көчле алкышларга күмде. Ул – республика спорты үсешенә зур өлеш керткән, казанышлары белән исемен илгә таныткан стендка ату буенча халыкара класслы спорт мастеры, үзе тренер, үзе спортсмен-инструктор... Европа, Дөнья чемпионатларында уңышлы чыгыш ясап, Кубок һәм медальләр, призлы урыннар яулаган искиткеч шәхес. Тикмәгә генә: «Мин беренче булырга яратам!» – дип әйтми шул ул!

Шигарьләре дә нинди бит әнә туташ-ханымнарыбызның: «Көрәшкән кеше генә җиңә!»

«Язмышым – һөнәрем», «Хатын-кыз – бизнес-леди», «Хатын-кыз – мәдәният һәм рухият», «Хатын-кыз – галим» номинацияләрендә җиңү яулаган 40 ел стажлы сыер савучы Елизавета Бартязова (Кайбыч), Яшел Үзән шәһәренең «Зәңгәр кошчык» мәктәпкәчә белем бирү хосусый учреждениесе җитәкчесе Альбина Динмөхәммәтова, шәхси үрнәге белән башкаларны да үзе артыннан ияртә алган Земфира Переведенцева (Югары Ослан), 65 ләп фәнни хезмәте булган педагогика фәннәре кандидаты Ирина Маршалова (Яшел Үзән) сынауларда сыналып, бу тормышта бары үзе генә ачкан юлны таба алган, үз язмышларын үзләре ясаган гаҗәеп ханымнар.



«Хатын-кыз – лидер» номинациясендә беренче урын алган Асия Ибраһимова (Тәтеш) – якташлары арасында гына түгел, республикада танылган педагог. Ул «Иң яхшы директор» грантына, Россия Федерациясенең мактаулы исемнәренә лаек булган дан казанган укытучы. Эшне башлап җибәргән чорларны исенә төшерсәме?! «Татар мәктәбе ачам дип, өйдән өйгә йөрүләр, ата-аналарны үгетләүләр... берсе дә күз алдыннан китми», – ди ул сораштыра башласаң.

Нефтьче-оператор, китапханәче, артист, укытучы, тәрбияче, җирле үзидарә башлыгы, журналист, спортчы, тегүче... Һәркайсы әдәби әсәр герое, якты образ булырлык үзенчәлекле язмышлы ханымнар.

Гомер көзләрендә дә үзләренә тынгы таба алмаган, аның һәр көнен истә калырдай итеп яшәгән ветераннарыбызга һәйкәл куярлык. Аларга карап сокланасың, аларга карап яшәргә, бирешмәскә өйрәнәсең! «Өлкән буын» номинанты Екатерина Елисееваның (Кайбыч) сәхнәдәге «кыланмышларына» карыйсың да, картлык аны әле озак вакытлар җиңеннән эләктереп ала алмас, артыннан куып тота алмас дип, аның өчен сөенеп тә куясың. 49 ел буе балалар укыткан тынгысыз укытучы әле Ветераннар советы рәисе, «Березка» ансамбле җитәкчесе дә. Каян килгән көч диген 80 гә якынлашып килүче бу кешедә?!

Моннан 20 еллар элек журналыбыз үткәргән «Киленбикә» бәйгесенең җиңүчесен, «Киленбикә» таҗына һәм тунына лаек булган Теләче килене, инде хәзер балаларының хөрмәтле әнисе, оныкларының яраткан дәү әнисе – Нурания Гыйльметдинованы (Теләче) янә сәхнәдә күргәч, бик куандык. Ул авылның бүгенгесен, киләчәген берничә җөмлә белән шундый төгәл һәм дөрес итеп әйтеп бирде, гаҗәеп моңлы тавышы белән тамашачыларны үзенә тәмам әсир итте ки, җырлавыннан туктагач та, зал бер мәл тын калып торды. Бу номинациядә ике җиңүче – Екатерина Елисеева һәм Нурания Гыйльметдинова билгеләнде.

«Ир-ат – лидер», «Алтын йөрәкле ир-ат» номинацияләрендә Сергей Сысоев (Буа) белән Расих Шагаев (Тәтеш) һәм Мөнир Салаватов (Кайбыч) җиңүче булдылар.

Һәм, ниһаять, дулкынландыргыч минутлар якынлаша. Жюри рәисе педагогика фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фәннәр эшлеклесе, атказанган мәдәният хезмәткәре Роза Баһаутдинова җиңүчеләрне сәхнәгә чакыра. Димпломнар, чәчәк бәйләмнәре, җылы котлау сүзләре... бары аларга – безнең кадерле әниләребезгә, уңган апа-сеңелләребезгә бүген.

Алабуга

Алабуга шәһәре сәхнәсендә – Минзәлә, Мөслим, Менделеевск, Мамадыш, Актаныш, Балык Бистәсе, Әгерже, Алабуга районнары ханымнары. Булдыклылар, тырышлар, тәвәккәлләр! Минзәлә районы Татар Мөшегесе авылыннан мәктәп директоры Римма Галимәрдановага («Хатын-кыз – галимә» номинациясе) җитәкче мәшәкатьләрен хәл итү белән бергә, фән белән дә шөгыльләнү, уңышларга ирешү өчен никадәр ихтыяр көче, түземлек кирәк булгандыр. Актаныш районының «Әнәк» агрофирмасы сыер савучысы Дилә Шәвәлиева («Язмышым – һөнәрем» номинациясе) дә сокландырды: авылның мәдәни тормышы эчендә кайнарга, «Карга боткасы» кебек борынгы йолаларны яңартырга, бәйрәмнәр оештырырга ничекләр итеп өлгерә икән ул?! «Өлкән буын» номинациясендә җиңү яулаган Наилә Низамовага җиде дистәне тутырган дип берәү дә әйтмәс: Алабуга мәдәният һәм сәнгать колледжы укытучысы бүген дә яраткан студентлары арасында – заман белән бергә атлый. «Хатын-кыз – ана» номинациясендә чыгыш ясаучылар «Ел хатын-кызы» бәйгесенең һәрвакыт игътибар үзәгендә: Илсөяр Хәбибуллина (Минзәлә) – Картлар йорты директоры. Шундый җаваплы вазыйфасы өстенә ул биш бала анасы да! Татьяна Семякованың (Менделеевск) да ул-кызлары бишәү: кечкенәсе әле тәпи дә китмәгән – сәхнәгә әнисе кулында чыкты. Барысы да матурлар, сәламәтлеләр, өч телдә сөйләшәләр!

Азнакай

Татарстанның көньяк-көнчыгышында яшәүче уңганбулган хатын-кызларны Азнакай үзенә җыйды бу юлы. Чатыр таулы әкияти Азнакай ул көнне калфаклы сылу кызлар булып, яз булып елмайды, бөтен тирә-юньгә бәйрәм сулышы өреп балкыды. Бәйгедә катнашучыларны сәламләргә чыккан район башлыгы Марсель Зөфәр улы Шәйдуллин да: «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең зона ярышы

Азнакаебызда узу белән горурланабыз, зур җаваплылык тоябыз», – дип, бәйрәмне тагын да зурлады. Әлеге мәртәбәле бәйгедә «Татарстан хатын-кызлары» республика иҗтимагый оешмасы рәисе Зилә Вәлиева, оешманың президиум әгъзасы Гүзәл Әхмәдиева, «Ак калфак» Бөтентатар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисоваларның конкурсантларны бәяләве үзе үк күп нәрсә сөйли. Бөгелмә, Баулы, Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Зәй, Сарман, Ютазы районнарыннан килгән гүзәл затлар арасында кемнәр генә юк! Әлмәт дәүләт драма театры актрисасы Мәдинә Гайнуллинаны аласыңмы, «Маяк» газетасы мөхәррире Гөлгенә Кәримованымы, Ютазыдан килгән алты бала әнисе Рәзимә Кашапованымы... Ә менә Оксана Данилова Лениногорскида гына түгел, бөтен нефть төбәгенә бер фән кешесе, галимә икән! Балачагында Ленинград блокадасы михнәтләрен татыган, эвакуацияләнеп килеп, Татарстанда икенче ватанын тапкан Вера Вуколова – корычтай нык ихтыярлы хатын. Тумыштан ук инвалид Лилия Заһретдинова – инглиз, немец, татар телләре буенча шәп тәрҗемәче... «Хатын-кыз – ана» номинациясен тәкъдим иткән Нажия апа Ильясовага 90 яшь! Бөек Ватан сугышы ветераны Зиннур ага белән 66 ел тату гомер кичереп, берсеннән-берсе уңган биш ул тәрбияләп үстергәннәр. Алар сәхнәгә дә парлап чыкты. Биш ул, биш килен, бер кочак оныклар, туруннар... Кызганыч, Нажия апага Казанга – финалга бару насыйп булмый. Бәйгедән соң, озак та үтми аның йөрәге тибүдән туктый...

Менә тагын бер якты образ: Актүбә бистәсе башлыгы Роза Галиева сәхнәгә чыгу белән үк зал алкышларга күмелде! Үз җирлекләрен үстерү буенча шаккатмалы эшләр башкарган чын лидер ул! Азнакайда гына түгел, бөтен республикада беләләр аны!

Лаеш

Кукмара районының Зур Сәрдек авылыннан, биш бала анасы булу белән бергә, озак еллар халык театрын да җитәкләгән Рәмзия Хөсәенова, Лаеш районыннан 20 ел эшләү дәверендә музейда 9 меңнән артык экспонат туплаган Фәридә Мортазина, Саба районыннан «Тулган ай» ансамбле җитәкчесе Рәсимә Сәүбәнова, Балтач районыннан 17 ир-ат арасында бер хатын-кыз – авыл җирлеге башлыгы булган Римма Исьмекова һәм исемнәре җиңүчеләр арасында аталган башка күп кенә ханымнарга карагач: «Хатын-кызда тик бер теләк: өлгерергә, өлгерергә, өлгерергә!» дигән юллар искә төшә.

«Өлкән яшьтәге хатын-кызлар» номинациясендә сәхнәгә чыккан 85 яшьлек Гөлҗиһан Айнуллина (Питрәч) барыбызны да аяктан екты. Башта ул: «Картаямыни соң йөрәк, / Маңгайлар сырланса да...» – дип сыздырды. Җырлап бетергәч: «Биимичә, сәхнәдән чыгып китү юк», – диде дә, әйләнә-бөтерелә биеп китте. Тамашачы «аһ» итте. Без – жюри әгъзалары исә: «Әбинең башы әйләнеп, егылып китмәсә генә ярый», – дип борчылдык. Биюеннән туктап, урындыгына килеп утыргач та, сер бирмәде әбиебез: «Чыгып китәсем килми бит әле», – дигән булды.

«КИҢӘШЕП, ЯРДӘМЛӘШЕП...»

Татарстан Республикасының Инвестицияне үстерү агентлыгы җитәкчесенең урынбасары буларак миңа шактый вакыт кече һәм урта бизнестагы эшмәкәрләр белән аралашырга туры килде. Ни гаҗәп, хәтта алар да дәүләт ярдәме турында бигүк белеп бетерми икән әле. Әйтик, бу – күптөрле бизнес-парклар, технопарклар, күргәзмәләр... Әмма хатын-кызга максат-омтылышларын гамәлгә ашыру өчен югары дәрәҗәдәге очрашулар җитми. Без моны аңладык һәм атна саен үткәрелә торган «эшлекле төшке аш» проектын башлап җибәрдек. Кемнәр белән генә сөйләшү алып бармадык без соңгы вакытларда: Эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Татарстан Президенты каршындагы вәкил, зур оешмаларның һәм агентлыкларның җитәкчеләре белән очрашулар, коррупция мәсьәләләре буенча Прокуратура һәм Президент Аппараты вәкилләре белән түгәрәк өстәлләр... Менә шундый эшлекле сөйләшүләрдә җавап табыла да инде кызыксындырган сорауларга.

Минемчә, мондый очрашуларның иң файдалысы Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы җитәкчелеге белән берлектәгесе булды. Анда чыгыш ясаган эшмәкәр ханымнар кече һәм урта бизнеска күрсәтелгән комплекслы ярдәм турында сөйләделәр, бик күп яңалыклар әйттеләр. Мәсәлән, чыгымнарны каплау, консультация ярдәме күрсәтү, Татарстанның Гарантия фонды, эшмәкәрлеккә һәм Татарстан экспортына ярдәм үзәкләре турында күпләрнең беренче генә ишетүләре иде.

Моннан тыш, Татарстанда бизнесны үстерүгә дәүләт ярдәменең башка төрләре турында да әйтеп үтик:

- Татарстан хөкүмәтенең халык һөнәрчелеге сәнгате өлкәсендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү гранты;
- Юридик вәкил, индивидуаль эшмәкәр сыйфатында теркәлгәннән соң, бер мәртәбә финанс ярдәме;
- Эш урыннары оештырганда (шул исәптән инвалидлар өчен дә) җиһаз сатып алу һәм кую чыгымнарын каплау;
- Крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүгә грантлар һәм эшләрен башлап җибәрүче фермерларга бер мәртәбә күрсәтелә торган ярдәм;
- Крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә ярдәм;
- Россия һәм чит илләрнең белем бирү һәм фәнни оешмаларында белем күтәрү өчен гражданнарга хөкүмәт бирә торган «Алгарыш» гранты;
- Инновацион продукцияне эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен кече һәм урта эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәме.

Планнарыбыз зур безнең. Әйтик, быел Түбән Новгородта, Чаллыда тәҗрибә уртаклашу һәм хезмәттәшлек буенча бизнес-миссия уздырачакбыз. Теләге булганнарга мастер-класслар, тренинглар оештырачакбыз. Бизнес белән шөгыльләнүче хатын-кызны һәрьяклап күрсәтү өчен «Заман хатын-кызының дөньясы» дип исемләнгән китап бастырып чыгарырга җыенабыз. Һәр хатын-кызның үз язмышы, үз холкы, тормышка карашы... Ләкин алар барысы да гаиләсенә, эшенә гашыйк, тормышка мөкиббән...

Лиана СӘЕТОВА,
«Татарстанның эшлекле хатын-кызлары»
иҗтимагый оешмасы президенты.

БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





Лилия
ГӘРӘЕВА

ЯКТЫ ӨМЕТ

Бүлмәдә дүрт шәм яна икән. Беренчесе – Тынычлык – телгә килеп, болай дигән: «Минем янар көчем калмады, кешеләр Тынычлыкны саклый белмиләр, мин сүнәм». Икенчесе – Ышаныч та сүнгән: «Кешеләр инде бернәрсәгә дә ышанмый, януымның мәгънәсе юк», – дигән ул. Өченчесе – Мәхәббәт тә: «Кешеләр Мәхәббәтнең кадерен белмиләр, үзләрен өзелеп яраткан иң кадерле кешеләрен рәнҗетәләр», – дип, янмаска карар иткән. Шул вакыт бүлмәгә бер нарасый йөгереп кергән дә, сүнгән шәмнәргә карап, елап җибәргән: «Сез бит янарга тиеш идегез, мин караңгыдан куркам!» Дүртенче – соңгы шәм, аны юатып, болай дигән: «Елама, минем янар көчем барында син ул шәмнәрнең барысын да кабыза аласың. Мин – Өмет булам!»

Сабыйлар иленә илтүче сукмак

Надежда – Надя – Надия. Надиясе турында бераз соңрак, әлегә ул – Надежда – әти-әнисенең якты өмете. Әтисе Равил абый кушкан исем бу. Нигә ул исемне сайлады икән? Гомерем буе янәшәмдә Өметем булсын, диюе булганмы?

Кыргызстанның Бурулдай авылында сигез балалы гаиләнең җиденче кызлары булып дөньяга килә Надежда-Надия. Әти-әнисе – Кытайда туып-үсеп, Кыргызстанга күченеп килгән кешеләр. «Үскәч кем буласың?» – балалардан гел сорала торган сорау бу. Надежда нинди һөнәр сайлыйсын беренче сыйныф бусагасын атлап кергән көннән үк белә. Беренче укытучысы кебек укытучы булачак ул. Шушы хыялы белән мәктәпне тәмамлый. Әмма... хыялына хыянәт итә – документларын фармацевтика училищесына илтә. Нигә фармацевтиканы сайлаганын һичкайчан аңлата алмас, мөгаен. Киләчәктә чемпионнар тренеры булып танылачак абыйсына үзенчә ярдәм итәргә теләве булгандыр инде. Яшь-яшь килеш урын өстенә калган абыйсы бигрәк кызганыч шул. Сынган аяклары ялганмый да ялганмый. Газапларын җиңеләйтердәй дарулар бар барын да, ләкин сатуда юк. Көндез шәм яндырып эзләсәң дә, кирәкле даруларны таба алмас көннәр дә бар иде бит. Сеңелнең нияте изгесен изге дә, тик хыялы гына хыянәтен кичерми менә. Укырга керә алмый Надежда. Өмете өзелгәндер дисәгез, ялгышасыз. Авырлыктан сынмый, чыныга гына ул. Моның шулай икәнен мең кат раслаячак әле. Ә әлегә... әлегә хыялына бер адым якыная тора – мәктәпкә пионервожатый булып урнаша. Соңрак озынайтылган көн группасына күчә. Тиктормас, шук, мең дә берне белергә теләгән «буратинолар» арасында эшләү шундый ошый аңа. Икенче елны, инде һич икеләнүсез, университетка юл тота. Аның юлы тәгаенләнгән. Ул юл балалар дөньясына илтә!

Саумы, тормыш!

Күрәк сакаллы акыл ияләренең даһи фикерләре язылган том-том китапларын «кимергән» арада кияүгә дә чыгып куя Надеждабыз. Дөрес эшли, билгеле. Хатын-кызның төп вазыйфасына хыянәт итсенме? Киләчәктә ире булачак, тик әлегә аңа таныш түгел Линар кибеттән чыгып килгән мизгелдә очрата кызны. Үзен күрми дә әле, бары тик күзләрен генә күрә дә, күбәләк канатын хәтерләткән керфекләрен генә күрә. Юк, хәтта күрми дә – ишетә! Шул керфекләр тибрәнеп, ачылып-йомылган мизгелне ишетә. Әле бүген дә – арада чирек гасыр бергә яшәлгән гомер яткан да шушы тавыш онытылмый. Күбәләкнең өрфия канатларыннан гына чыгадыр бу тавыш. Шушы көннән Надежда егет күңелендәге Күбәләккә әверелә. «Кайсы гөлгә кунар Күбәләк син? Кайдан эзлим сине, кайдан табыйм?» Кызны кабат очратудан чарасыз егетне беркөн кунакка чакыралар. Килсә – табын артында теге Күбәләк! Әллә кайда еракта да булмаган икән югыйсә. Шушында гына – егет яшәгән совхозның балалар бакчасына килеп урнашкан икән! Бу юлы кызны ычкындырмый инде Линар. 1989 елны Сөләйманова Надеждадан Имаметдинова Надиягә әверелә ул. Менә Надия дигәнебезнең серен ачар вакыт та җитте. Кайнанасы шулай дип атый аны. Татарстанда туып-үсеп, шушында буй җиткергән, язмышына буйсынып, әчә суларын Кыргызстан туфрагында тапкан татар хатынына Надия исеме якынрак булмый, нишләсен. Линарының да педагог булып чыгуын гына күр син! Ике педагогка аңлашып яшәп китүе бер дә кыен булмый. 1990 елны кызлары Наилә туа. Авыр, болгавыр еллар бу. «Сухой закон»ның йөзем бакчаларын кырган еллары. Аларның да йөземчелек совхозы тарала. Кешеләргә эш бетә. Надежда эшләгән балалар бакчасын ябалар. Әмма, алда торган ишекләр ябылса да, Өмет дигән теге ут бар бит әле. Надежданы мәктәпкә башлангыч сыйныфларны укытырга чакыралар. Өр-яңа мәктәпнең буп-буш сыйныф бүлмәсен ире белән баштанаяк җиһазлыйлар, бизиләр. Үз акчаларына! Кызы тугач, бер мәл тукталып калган укуын да дәвам итә. 2002 елны кулына башлангыч сыйныф укытучысы дипломын ала.

> *Начар педагог – хакыйкатьне үзе әйтеп бирә, яхшы педагог аны табарга өйрәтә.*

Тәрбиянең асылы – хөрмәт

Аның сыйныфында кайсы гына милләт баласы укымый. Кыргызлар, руслар, татарлар, дунганнар, алманнар... Кыргыз балаларының абый-апаларына, әти-әниләренә, әби-бабаларына булган мөнәсәбәте сокландыра аны. Аларда өлкән кеше – иң хөрмәтле кеше. Кыргыз гаиләләрендә әби-бабайның урыны түр-







дән, олыларның сүзе – закон. Өлкәннәргә карата мондый ихтирам белән Надежда-Надия Татарстанга кайткач та очрашачак әле. Ә укытучыларын ничек хөрмәт итә ул балалар! Кая ул укытучы белән кара-каршы әйткәләшеп утыру! Алар өчен укытучы – илаһи бер зат. (Кайчан гына әле бездә дә шулай иде.) Кыргыз баласы кечкенәдән аңлап-белеп үсә – әти-әнисенең йөзенә кызыллык китерергә, нәсел-нәсәбенә тап төшерергә ярамый. Элегрәк баланың кыңгыр эшләре хакында әти-әнисенең эш урынына хәбәр итү дә бар иде бит. Хәзер генә ул барысына да укытучы гаепле. Кайбер әти-әниләр баласы «өчле» алса да укытучы янына «разборкага» йөгерә. Гел-гел баланы гына тыңлап, аныңча гына яшәүче ата-аналардыр инде аның болары. Бераз соңрак, күпме еллар балалар белән эшләп тупланган тәҗрибә күзлеге аша карап әйтәчәк әле Надежда: «Балаларга мөстәкыйльлек бирергә кирәк. Кулыннан җитәкләп йөртеп, аларны тормышка өйрәтеп булмый».

Баланың тәрбиялелеге – табигатькә, тәрбиясезлеге тәрбиячегә сылтана.

Көрәшчеләр

«Әгәр дә тормыш ак һәм кара юллардан тора икән, син аның агында туктал да шул юл белән алга таба бар!» Кем әйтте икән бу сүзләрне – Надежда анысын хәтерләми. Укытучыларга тиеннәр генә түләгән елларда очын-очка ялгау өчен ике смена укыта ул. Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр мәктәптә. Көченең көррәсенә кадәр чит балаларны тәрбияләүгә бирә, ә үз кызы исә, аны көтә-көтә, ул кайтканчы әбисе куенында йокыга киткән була. Аннан соң, еллар үткәч белдерәчәк әле ул үпкәсен: «Әнием, мин үскәндә сине туйганчы күрмәдем дә», – диячәк. Надежда аның хәтта беренче тапкыр мәктәпкә киткәнен дә күрә алмый – акчасызлыктан, өстәмә эш итеп кафега урнашкан була. Булды инде, булды, төрлесен кичерделәр. Җәйге елларда басуда ялланып суган үстерүләре дә истә. Эштән курыккан юк ла ул!

«Мин беркайчан да укытучы булмаячакмын!» – дигән Наиләләре бүген инде үзе дә педагог. Әтисе шикелле. Казан педагогика колледжында физкультура укыта. Мәктәп елларыннан бирле көрәш белән шөгыльләнә. Спорт мастерлыгына кандидат. Теләсә, спорт мастеры да була алыр иде – кирәксенми. Яңа гына кияүгә чыгып, үз тормышын корган кызның уйлары башкада әле. Ә тренеры... тренеры – теге вакытта әнисен чак кына фармацевтлыкка җибәрми калган абыйсы – Бари Сөләйманов. 17 яшендә аягын сындырып, имгәнеп калса да, тормышта үз юлын, үз урынын тапкан ул егет. Үзен-үзе чыныктыру өчен мәктәптә укыганда ук ирекле көрәш белән шөгыльләнә башлый. Тренажер залы ача, балаларны көрәшергә өйрәтә. Эше өчен хәтта акча да алмый. Әмма 1991 елда, СССР таркалгач, халыкта спорт кайгысы калмый, көрәш залы ябыла. 2001 елда Бари Сөләйманов гаиләсе белән Татарстанга күченеп кайта. Россиянең атказанган тренеры исеменә лаек була. Ул тәрбияләгән спорт мастерларын, спорт мастерлыгына кандидатларын, төрле бәйгеләрдә җиңү яулап, көрәш батырлары булган егетләрне санап чыгыйм дисәң, бер түгел, ике пар кулның бармаклары җитмәс. Үзенең ике улын да көрәшче итеп үстерә ул. Кечесе өченче ел Казанда узган Универсиадада көрәш буенча икенче урынны яулаган. Бари Сөләйманов

быелгы «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» бәйгесенең Алексеевскийда узган төбәк турында «Ир-ат лидер» номинациясендә җиңүче булды.

Татарстанда

Линар белән Надежданы Татарстанга кайтырга күндергән кеше дә – шушы абыйлары. «Кайтыгыз, монда халык кунакчыл, ярдәмчел», – дип кызыктыра ул аларны. Надежда кайтырга риза, әмма ире белән кайнанасын күндерүләре менә... Күченеп кайтуга кайнанасы теше-тырнагы белән каршы тора. Югыйсә туыпүскән җире бит, кендек каны шушында тамган. Надежда бу каршылыкның сәбәбен аңлый. Үскәндә бәрәңгедән гайре ризык булмавын, гел туяр-туймас йөрүләрен сөйли торган иде аңа кайнанасы. Алманы да Кыргызстанда яши башлагач кына авыз иткән ул. Шулай да тәвәккәлләми булмый. 2006 елны кузгалалар. Кызлары Наилә әбисе белән Кыргызстанда яшәп кала. «Башта бер ел яшәп карыйк әле, – ди Надежда. – Аннары күз күрер». Үзе, кайту белән үк, Алексеевскийдагы «Кояшкай» балалар бакчасына эшкә урнаша. Эшкә алуын алалар, әмма категориясен киметәләр. Надежда урынында берәү булса, белмим, нишләр иде. Ә Надежда яңадан белемен күтәрү курсларында укып, югары категорияле педагог булуын кабат раслый. Тагын бер елдан аны Алексеевскийдагы «Ромашка» балалар бакчасына өлкән тәрбияче-методист итеп эшкә чакыралар. Методистның эше – бакчадагы тәрбия, укыту эшчәнлеген оештыру һәм аның үтәлешен күзәтүдән гыйбарәт. Бакчада бәйрәмнәр үткәрү, тәрбиячеләрне төрле конкурсларга әзерләү дә методист өстендә. Балалар уйнаган уенчыклар, аларга укылган китаплар, каләм-карандашлар – бар да Надежда апаларының таләпчән күзе аша үткән. Бакча өчен беренче ноутбукны, беренче экранны, беренче проекторны да Надежда ханым юллап алган. Экраны белән проекторы булгач, аларны куллана белүчесе дә булырга тиеш. Фильмнар күрсәтергә, презентацияләр ясарга ул башта үзе өйрәнә, аннан хезмәттәшләрен дә өйрәтә. «Нигә кирәк бу безгә?» – дип авырыксынган кызларга: «Эшегезне күпкә җиңеләйтәсез. Кулдан рәсем ясарга (элек кулдан күпме рәсем ясый торган идек!), иллюстрацияләр эзләп утырырга кирәкми. Балаларга да күңелле», – дип кызыктыра.

Кече-кечедән килә торган бер сыйфаты бар Надежда Имаметдинованың: бертөрлелек тиз туйдыра аны. «Бер урында торырга яратмыйм. Мин яңалык яратам. Кеше гел эзләнергә тиеш. Бу бигрәк тә педагогларга кагыла. Заманнан артта калмыйм дисең икән, аның белән бергә атларга түгел, аз гына алдарак та йөгерергә кирәк», – ди ул. Болай янып, дәртләнеп эшләвенең әҗерен дә күрергә насыйп булган – 2012 елда район администрациясе башлыгының грантын алган Надежда. Ә тагын бер елдан ул эшләгән балалар бакчасы, республика конкурсында катнашып, бер миллионлык грант откан, «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» дип танылган.

Балаларга ни җитми?

Иң элек балаларга бакчада урыннар җитми. Кайсысына гына кермә, балалар белән шыплап тулган булыр алар. Шуннан инде калган проблемалар баш күтәрә: уйнарга – уенчыклар, йокларга – урыннар, ишегалдында тиешле уен мәйданы җитми. Баланың күңелендә ни барын рентген нуры кебек үтә күрүче психологлар, дөрес сөйләшергә өйрәтүче логопедлар җитми. Бер тәрбияче утызлап баланы карап та бетерә алмый, димәк, игътибары җитми. Кай очракларда әти-әни белән тәрбиячененң аңлашуы да җитми. «Берәр проблема булса, әти-әниләр, тәрбиячегә түгел, хәтта бакча мөдиренә дә әйтеп тормыйча, РОНОга йөгерәләр, – ди Надежда. – Проблеманы урында да хәл итәргә була бит югыйсә. РОНО нишли инде? Хәл итү, тикшерү өчен кабат безгә җибәрә. Бакчада балаларны яратмаган, аларны кыерсытырга гына торган әләкемнәр эшли дип уйлап ялгыша ата-аналар. Монда очраклы кеше озакка кала алмый. Бу шундый җир – эшеңне чын күңелдән яратмасаң, сабыйларга карап яшәү көче алмасаң, монда бер көн эшли алмыйсың. Дөрес, килгәли андыйлар, әмма бер-ике айдан китәргә мәҗбүр була.

> *Укытучылар кулында Премьер-министрның төшенә дә кермәгән хакимлек бар.*
>
> *У. Черчилль.*

Баласын бакчага әзерләүче әти-әниләргә киңәшем шул: балагызның үзенчәлекләре, холык-фигыле, яраткан уеннары хакында тәрбияче белән ачылып сөйләшегез. Өйдә һәм бакчада тәрбия алымнары уртак булса, баланың үзенә дә җайлырак. Тәрбияче бертөрле сөйләп, бала өйдә икенчене ишетсә, тәрбиянең бөтенлеге югалмый нишләсен?» Тагын ни җитмиме? Бала өчен иң мөһиме, иң әһәмиятлесе – аңа әти-әнисенең игътибары җитми. Үрнәк алырдай күркәм геройлар җитми. Хәзерге заман баласының уйнаган уеннарын карагыз сез: монстрлар, хәшәрәтләр, роботлар...

...Балалар бакчасы, андагы сабыйлар турында сәгатьләр буе сөйләргә әзер Надежда-Надия. Эшенә чын күңелдән бирелгәнлек галәмәтедер инде бу. Эшэш диеп дөньясын да онытып җибәрергә мөмкин ул. Ә бит өйдә аны ире, кайнанасы, яшелчә бакчасы, гитарасы, һәм бәйли башлаган кофтасы көтә. «Ел хатын-кызы-2014» конкурсының Казанда узачак финалы көтә. Надежда Имаметдинова, абыйсы Бари Сөләйманов кебек үк, быелгы бәйгенең Алексеевскийда узган төбәк турында катнашып, «Язмышым – һөнәрем» номинациясендә җиңүче булды. Өмет дип аталган теге шәм янганда Надежда беркайчан да ярты юлда тукталып калмаячак. Ул шундый Кеше!

«ҖИНМӘСӘМ, ЙӨРМИМ ДӘ!»

ӨЗГӘЛӘНЕП, МӨКИББӘН КИТЕП КЕМ ТУРЫНДА ӘЙТӘДЕР ДИП УЙЛЫЙСЫЗ АНЫ?! ӘЛБӘТТӘ ИНДЕ, МАЛЛАРЫ ТУРЫНДА...

Мәдинә АВЗАЛОВА

Кичәнең иң кызган чагында гына сәхнәдә ул күренде. Өстендә – ап-ак халаты, кулында – ялтырап торган ак чиләге. Аның сәхнәгә килеп чыгуы да башкаларныкына охшамаган иде. Ул: «Ямансулап болыннарны буйлама, / Оныткандыр инде диеп уйлама...» – дип күкрәктән чыккан яңгыравык-калын тавыш белән җырлап җибәрде. Залда утыручылар, тын калып, аңа текәлде.

Җыр дәвам иткән ике-өч минут эчендә без дә, уебыз белән аңа ияреп, басу-кырларны иңләгәндәй, балачагыбызга кайтып, авыл урамнарыннан яланаяк йөгереп узгандай булдык. Җыр кинәт өзелде. Ә ул шундый ук күтәренке рухта сөйли башлады. «Мин инде менә 40 ел фермада сыер савам», – дигәч, халык гөрләтеп кул чапты. Яраткан эше, яраткан һөнәре аны авылының горурлыгы, мактанычы иткән. Аның гомер юлы да, хезмәт юлы да бер сукмактан уза.

«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең зона ярышында, «Язмышым – һөнәрем» номинациясенә яшен булып килеп чыгып, йолдыз булып балкыган бу ханымны, чыгышын тәмамлауга, җиңеннән эләктереп алам.

– Ой, – ди ул, кулларын бала-чага сыман артка яшереп. Аннары, уңайсызланып китеп, яргаланып беткән кытыршы учларын шундук миңа суза.

Янәшәдә гөжләп тормыш кайный: ак ефәк күлмәкләрдән ак күбәләкләргә охшап калган нәни кызчыклар; затлы-матур күлмәкләреннән арлы-бирле йөренгән яшь туташлар; ханымнар; «каушадым әле» дип, сәхнәгә чыгарга кыймый торган ак яулыклы әбиләр...

«Ак барс» холдинг компаниясе агрофирмасының алдынгы сыер савучысы, «Татарстанның атказанган терлекчесе», Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, район хакимияте дипломнарына, кыйммәтле бүләкләргә лаек булган, гомерен үзе яраткан хезмәткә багышлаган, һөнәре чын мәгънәсендә аның язмышына әверелгән Кайбыч районының Хуҗа Хәсән авылы кызы Елизавета Бартязова белән сөйләшүне башлап җибәрүгә, бар дөньямны онытам.

«Фермага качып төшә идем»

– «Җаным-тәнем белән фермага ябештем», алайса, дим, бая сөйләгәннәрен искә төшереп.

– Шулай булды шул... Бәләкәйдән сыер саудым. Без гаиләдә ун бала үстек. Әни гел авырды. Шуңа эшне бүлешеп эшли торган идек: кем идән юа, кем су ташый, кем мал карый... Ә мин – сыер савам. Тугыз яшьләр тирәсе булгандыр миңа ул чагында. Ябештем бит шуларга, – ди ул, янә яраткан сүзен кабатлап. – Шуннан китте инде... Әниемнең сеңлесе Лиза апаның фермага җыенуын көтеп кенә торам да артыннан чыгып чабам. Кечкенә идем әле, Лиза апаның мине аласы килми: «Дәресеңне хәзерлә», – ди. Мине ияртмәс өчен арткы урамнан йөри. Ә мин урам уртасыннан йөгерәм. Фермага аннан алда барып утырам. Аннан кул селтәде: «Йөр лә, зинһарым, туйгач, туктарсың», – диде. Ә мин туймадым, киресенчә, малларымнан башка яши алмаска әйләндем. Менә хәзер дә үзем монда, уем – алар янында. Вакытында ашарларына салдылармы икән, асларын чистарттылар-юындырдылармы икән?

– Юындырдылармы?! – дим, аңламыйча.

– Мин аларны көн саен «мунча кертәм» бит, – ди ул җитди итеп. Кыргыч алам да, җылы су белән ышкый-ышкый юам. Күзлек кебек чиста булалар. Койрыкларына кадәр чистартам, аннары йоннарын җәелдереп җибәрәм, күрсәң, – ди ул бөтенләй хисләренә бирелеп. – Терлекне аны тоярга кирәк. Кул җылысы булырга тиеш. Болай да хәзер бөтен эш механикалаштырылган, төймәләргә генә басабыз. Кулдан эш төште, кыскасы... – ул канәгать елмая.

– Сыер саву аппаратлары кайткач, рәхәтлеккә тиендек дип, сөенгәнсездер?

– Ой, – ди ул тагын, – сөендек тә, көендек тә. Эшләп киткәнче, авыр булды. Җилененә эләктереп кенә куябыз, төшә дә китә, төшә дә китә... «Әйдәгез, кызлар, кул белән савабыз, җәфаланмыйк әле», – дим. Өйрәттеләр аннары безне. Җан рәхәте дибез хәзер.

40 ел стажлы сыер савучыдан: «Арыдым, инде китәрмен...» – дигән сүзне көткән идек.

Георгий Осипов җитәкчелегендәге 16 авылны берләштергән әлеге агрофирма районда беренчеләрдән санала. Бар яңалыкның иң элек аларда сыналуы бер дә гаҗәп түгел. Районда җитештерелгән продукциянең 50 проценты алар өлешенә туры килә икән. Терлек саны да елдан-ел арта бара, мал ашату ягын да үзләре чамалый, үзләре үстерә дип әйтүем. 2200 ләп савым сыеры гына бар аларның. «Төркемнән көненә уртача 600 литр сөт савып алабыз», – дип сөйләгән Елизавета Бартязова 40 ел эшләү дәверендә мондый казанышларга ирешкәнен хәтерләми дә. Ул бүген көненә 20 баш түгел, 50 баш сыер сава.

Елизавета Михайловна пенсия яшендә булса да, эшеннән китү турында башына да кертеп карамый. Бу хакта сүз чыккач, ул кырт кисә: «Балаларым кебек бит алар миңа», – ди. Авыл татлы йокыда чагында – төнге икедән торып фермага йөгерүе, кеше әле йокыдан уянып кына килгәндә, эшен бетереп, ике-өч сәгатькә генә өенә кайтып, «тиз генә ашарга пешереп» килүе, аннан соң янә фермага чабуы турында ул шундый тәмләп, яратып сөйли ки, ирексездән уйлап куясың: чыннан да, кая әле аңа эштән китү?!

– Кызлар миңа: «Бер авырып та караганың юк бит синең, Лиза апа!» – диләр. Эш яшәртә мине, дим.

Фото: Марат Хәялетдинов

Шулай дигәч, алар көлә. Чыны шулай бит. Син әйт менә, – ди ул миңа сораулы карашын текәп, – бер айлык балаңны ташлап эшкә чыгар идеңме?! Юк, чыкмас идең... – ди ул, җавапсыз калуымны күреп. – Уңдым мин эштән...

«Сөт сава торган аппаратларга ияләшү кыен булды. Әйдәгез, кул белән генә дим... Тәки өйрәттеләр бит».

«Кайнанам шәп!»

– Ә гаиләдән? – дим, һаман эше турында сөйләп утырган әңгәмәдәшемә.

– Гаиләдән дә. Гомере фермада узган кешенең нинди шәхси тормышы булсын инде, дисеңме?! Мин унсигезем тулар-тулмас кияүгә чыккан кыз. Бу мәсьәләдә хәтта апаларымны уздырдым, – ди дә яңгыратып көлеп җибәрә. – Өлгердем, барына өлгердем. Әле дә хәтердә, 8 нче сыйныфны тәмамлап, Казанда – сәүдә училищесында укыган чагым. Ә Юра армиядән кайткан гына иде әле. Ул миңа озак уйларга вакыт бирмәде: «Әйдә, Лиза, өйләнешик, болай йөрмик», – диде. «Әйдә!» – дидем. Бер-бер арты өч балабыз туды: олысы Николай – инженер, Себердә яши. Уртанчы кызым Лена да шунда – банкта эшли. Ә кечесе – Казанда. Алисам гаиләсе белән ялга гел кайтып йөри. Хәзер без өйдә өчәү калдык: картым да, кайнанам. Ирем – лаеклы ялда. Эшләгәндә миннән кимен куймады. Ул хуҗалыкның алдынгы механизаторы булды. Ялда, дим дә, өйдә эш җитәрлек. Минем бит өйгә кайтып кергәнем дә юк. Өйдәге эшләрне ул алып бара. Көн саен минем белән бер мәртәбә фермага төшеп менә. Бик булыша миңа: малларның астын чистарта, сыерларны юганда җылы су китереп тора.

Ә кайнанасы Елизавета Константиновнага тиздән 90 яшь тула икән, килене, шаяртып, без ике Елизавета дип сөйли:

– Минем кайнанам мировой ул! Аның 7 баласы, 40 оныгы бар. «7 июльдә юбилеен үткәрергә җыенабыз. Украина, Кырым, Чаллы, Себер буйлап таралышкан балалары, оныклары... барысы да төп йортка кайтачак. Ул бик акыллы, сабыр, дөрес карчык, – ди Елизавета килен. – Без өйләнешкәндә кайнанама 50 яшьләр тирәсе генә булгандыр. Ирем әйтте шул чагында: «Син, әни, эшләмә инде. Ашарга пешереп, безнең эштән кайтканны көт!» – диде. Ул риза булды. Аннары гомер буе безне көйләде, безнең җайда торды. Балаларымны бер айдан ул карый башлады, чөнки мин эшкә чыктым. Балалар мәктәпкә киткәч, хәтта, җыелышка да ул йөрде. Яннарына утырып, дәресләрен хәзерләтте. Шуңа күрә балалар да аның өчен үлеп торалар. Хәлебезне белешеп шалтыратканда беренче сүзләре дә: «Әби ничек?»

Их-х, матур итеп җырлап булмады, әллә нәрсә дулкынландым шунда, – ди ул, үткәненнән бүгенге вакыйгаларга кайтып. – Мин җырларга, биергә яратам. Кызлар хорга чакыра. Барыр идем, китә алмыйм дигәндәй, сыерларым җибәрми, аларга гына җырлармын инде, – ди ул, күзләреннән хәйләкәр очкыннар чәчеп.

Һәр эшкә: «Булдырабыз аны», – дип керешкән хезмәт ветеранының җиңеп чыгуына бер дә гаҗәпләнмәдек. «Җиңмәсәм, йөрмим дә мин аны», – ди бит әнә үзе дә...






Фото «Кайбыч таңнары» газетасы архивыннан алынды

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан Кремленең Тантаналар залында ветераннарга «1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгы» юбилей медальләрен тапшырды. Медаль алучылар арасында Советлар Союзы Герое да, сугыш һәм хәрби хезмәт, тыл ветераннары да, фашист концлагерьлары, Ленинград блокадасы аша узучылар да бар.

■ 2015 елның I яртыеллыгына газета-журналларга язылу буенча «ТАТМЕДИА» ААҖ конкурс комиссиясе «Язылган өчен Ipad» конкурсына йомгак ясады. Төп приз — Айпад — Актаныш районы Иске Байсар авылыннан Ямиев Ринатка тапшырылды. Ул беренче яртыеллыкта 5449,58 сумлык «ТАТМЕДИА» ААҖ басмаларын яздырып ала. Азнакай районыннан Шәйхуллова Миләүшә һәм Гыйләҗев Илдус, Чиләбе өлкәсеннән Салихов Нәркис — цифралы фотоаппарат белән бүләкләнделәр. Беренчеләрдән булып язылу квитанцияләрен җибәргән 50 кеше кызыксындыру бүләкләренә лаек булды. Узган еллар белән чагыштырганда, конкурста катнашучылар саны быел ике тапкырга арткан.

МӘДӘНИЯТ

■ 20 мартта К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында «Авыл кызы» Бөтенроссия бәйгесенең финалы узачак. Аны Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты белән берлектә «Сөембикә» журналы оештыра. Ә 3 мартта Казан Кремленең «Манеж» күргәзмә залында «Сөембикә» журналы укучыларына таныткан хатын-кызлар иҗатына багышланган күргәзмә ачылачак. Алар арасында – рәссамнар, зәркәнчеләр, күн бизәү һәм чигү осталары.



■ Казан туризм өлкәсендә беренче тапкыр федераль грант отты. «Гаҗәеп Казан» велосипед маршруты проекты РФ мәдәният министрлыгы тарафыннан вело һәм җәяүлеләр маршрутлары буенча уздырылган Бөтенроссия конкурсында җиңеп чыкты. Әлеге проектны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан 15 миллион сумлык грант тапшырылачак.

■ Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре «Татар әдәбияты тарихы» сигез томлыгының беренче ике томын киң җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим итте. Моңа кадәр 1980 елларда чыккан алты томлыктан аермалы буларак, яңа басмалар чорлар шаукымын исәпкә алып, фәнни ачышлар белән баетылган.

МӘГАРИФ

■ 2013–2014 елларда мәгариф өлкәсендә зур нәтиҗәләргә ирешкәне өчен илнең иң яхшы 500 мәктәбе билгеләнде. Алар арасында Казанның тугыз уку йорты да бар. Татарстан буенча аларның саны – 17. Бу мәктәпләр – БДИ күрсәткечләре, Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадалары нәтиҗәләре буенча алдынгылар дип табылды. Ә 131 нче лицей Россиянең иң яхшы 25 мәктәбе исемлегенә кергән.

■ Чаллыдагы 36 нчы инновацион технологияләр лицей-интернатының «Золотая горка» командасы Мәскәүдә узган VII «Робофест» робототехник Бөтенроссия фестивалендә ике бронза медаль яулады. Беренчесе – машина төзелеше производствосы өчен җитештерү-технологик линияләрне эшләгәннәре, икенчесе биремнәрне тиз үтәп чыкканнары өчен тапшырылды.

■ Укытучыларның һәм укучыларның Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган II Республика конференциясенә старт бирелде. Ул язучының иҗади мирасын киңрәк өйрәнү һәм популярлаштыру максатыннан уздырыла. 12 мартта Татарстан районнарыннан килгән мәктәп укучылары Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиядә чыгыш ясаячак. Халыкара театр көнендә җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы көтелә.

КОТЛЫЙБЫЗ



■ Әнкара шәһәрендә Төрки дөньяның 23 массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларына «Төрксой»ның дәрәҗәле премиясе тапшырылды. Бүләкләнүчеләр арасында Татарстаннан «Татар-информ» агентлыгы күзәтчесе Люция Камалова һәм журналист, җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиев тә бар.

СПОРТ



■ Казанның Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт академиясендә нәфис гимнастика буенча Россия беренчелегенә ярышлар уза. Анда илнең 11 федераль округыннан 100 гә якын 15 яшькәчә иң көчле гимнасткалар чыгыш ясый. Казанда оешкан җыелма команда нәфис гимнастика буенча Европа чемпионатына китәчәк.



ҖАН ӨЗДЕРГЕЧ МОҢ БУЛЫП...

Без кемнәр? Каян килəбез? Нинди өмет-хыялларны җилкəн итеп чорлар-еллар кичкəнбез? Үз халкының чыгышы, тарихы, үткəне, бүгенгесе хакында уйланган һəркемне кызыксындыра торган сөаль-сораулар ич болар! Əлбəттə, каян килүебез, бигрəк тə кая баруыбыз хакында фəһемле фикер йөрткəндə тарих сəхифəлəренə мөрəҗəгать итү мəслихəт. Əйтик, Фукска!



«Өч йөз ел элек буйсындырылган Казан татарларының чит халыклар басымы астында, руслар арасында таралып яшәп тә, үзенчәлекле үз милли йөзләрен, борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, әхлак сыйфатларын югалтмый саклый алулары күзәтүчән этнограф игътибарына лаек, – дип язып калдырган табиб, ботаник, этнограф, тарихчы, медицина докторы, профессор Карл Фукс. 1823–1829 елларда ул Казан университеты ректоры була. Немец галименең фикерләре, татарларга биргән бәясе ике йөз елдан соң да искерми, күңелне җылытып тора. – Әдәп-әхлаклы, йорт җанлы татарлар диннәре, чыгышлары белән горурланалар, – дип дәвам итә ул. – Алар шат күңелле, кунакчыл, шөһрәт сөючән, чиста-пакь, көмеш яратучан, мәгърифәткә тартылучан, әзләнүчән. Үзара дус-тату, сәүдәгә күңелләре ята. Эш сөючәнлек, әзрәк мактанчыклык та хас аларга. Хатын-кызлар йорт-җирләрен тәртиптә, чиста тота. Икмәк пешерергә осталар. Алардагы кебек куе, тәмле каймак бүтән бер җирдә дә юктыр. Татар кызлары кул эшенә бик оста. Тукылган ашъяулык, сөлгеләрнең бизәкләре гаҗәеп нәфис. Читтән килгән кеше Казан татарларының кайберсе европалылардан гыйлемлерәк булуын күреп хәйран кала. Укый-яза белмәгән татар исә үзен якташлары хөрмәт итәсенә ышана алмый. Шуңа күрә һәр ата баласын укытып кеше итәргә, дини тәрбия, гыйлем бирергә, укырга-язарга өйрәтергә тырыша».

Безнең халыкның иң яраткан мәкале: «Авызың тулы кан булса да кеше алдында түкермә», дигәнедер, мөгаен. Ихтимал, Германиядән килгән, рус һәм хәтта татар телләрен дә су кебек эчкән, Идел буенда яшәүчеләрнең тормыш-көнкүреше белән фәнни максатларда җитди кызыксынган галимгә күбрәк мәгърифәтле, алдынгы карашлы татарлар белән аралашу насыйп булгандыр. Хәер, без шундый, мондый дигәндә... Җәлилчеләр, әсирлектә җәзалап үтерелгән милләттәшләр язмышы искә төшсә гаҗәпме?! «Татарлар елмаеп үлделәр» дигән шигырендә Шагыйрь халыкның холкын-йөрәген ача да сала ич әнә: «Читләр алдында елмаеп, / Коръән алдында елап...» киткән ич алар да.

* * *

Әгәр үткән гасырда иҗат иткән шагыйрә иҗатына күз салсак... «Дөньяга килдем иректә, хөр булып, шат кыз булып, / Алды язмыш хөрлегемне, үтте гомерем хур булып. / Хөрлегемне алдылар миннән, богаулап куллары. / Кайтмады хөрлек кире, үтте гомерем кол булып. / Азмы яшь түктем, ялындым, хөрлегемне бирче, дип, / Кире кайтты тавышым җаннар өздергеч моң булып».

1914 елда басылып чыккан «Татар кызы» дигән бу шигырьнең авторы – Заһирә Байчурина. Кем соң ул Заһирә Байчурина, нигә шулкадәр моңлы соң аның йөрәк тавышы диярсез? Шигырь бит ул күңел халәте, җан-бәгырьдән ургылып чыккан хисләр өермәсе. Халыкның уй-хисләре, кичерешләре җырларында, бәет-шигырьләрдә чагылыш табуы берәүгә дә сер түгел.

Заһирә Байчурина минем якташым. Дөрес, үзе исән чакта аның белән күрешү-аралашу насыйп булмады. Әгерҗе районы Тирсә авылы мулласы Гали хәзрәт

гаиләсендә 1890 елда дөньяга килә Заһирә. Аңа өч яшь тулганда әтиләре үлеп китә. Әниләренә – дүрт кыз бала белән тол калган хатынга тормышның очын-очка ялгаулары бер дә җиңел булмагандыр. Йортта ир заты калмагач, аларга имана җире дә тими. Дөрес, әнкәләре аштанашка бәлеш ашап йөргән абыстай гына түгел аларның, заманасы өчен гыйлемле: кырык ел буе кыз балалар укыткан укытучы ул. Заһирә дә башлангыч белемне башта авыл мәктәбендә, әнкәсеннән ала. Ә унбер яшендә аны атаклы Мөхлисә Бубый җитәкләгән кызлар мәктәбенә укырга бирәләр. Тирсә белән Бубый арасы егерме биш чакрым чамасы, өйгә кайтып йөрү, йорттан ризык, һичьюгы бәрәңге булса да алып килү турында хыяллanасы да юк. Яшәргә кирәк. Хәллерәк гаиләдән чыккан кызларга вак-төяк хезмәт күрсәтеп, уку авыр бирелгәннәренә дәрес әзерләргә булышып тамагын туйдырырга мәҗбүр була ул. «Ятим кыз балага тормышның әчесентөчесен шактый татырга туры килде ул елларда», – дип яза әле соңрак, үзенең «Тәрҗемәи хәлендә». Шунысы куаныч, Бубый кызлар мәктәбе һөнәр бирә: укытучымөгаллимәләр әзерли. Кызлар, укып бетергәч, балалар укытырга хокук бирүче таныклык алып чыга.

Унбиш яшьлек Заһирә Байчурина 1905 елда туган авылына мөгаллимә булып кайта. Әмма кыз баласының аң-белемгә сусавын күреп, авылга гыйлемле мөгаллимә кайтканга сөенүчесе генә бик аз булган заман шул бу. «Кыз бала – кеше кешесе. Барыбер кияүгә китәсе. Әлефби-тисине белсә, шул җиткән. Язу таныса, егетләргә хат яза башлар. Кирәкми аңа уку», – дип аяк терәп укытырга каршы торучысы күпме?! Крестьян балаларын җыеп юк-бар бәягә сабак укытырга алынган яшь мөгаллимә янына алай да авылдашлар эзне суытмый. Кичләрен солдат хатыннары ирләренә хат яздырырга, читтән бәхет эзләгән туганнарына сәлам юлларга кемгә барсыннар? Аңа – авыл укымышлысына киләләр! Зар-моңнарын сөйләп эчләрен бушаталар. Тегe яки бу фаҗигале вакыйгага багышлап «бәет тә әйттерәләр» әле. Менә шул чорда Заһирәнең күңелендә кайнаган уй-хисләрен шигырь калыбына салу теләге туа да инде. Ул күп укый, Тукайны, Мәҗит Гафури әсәрләрен ярата, үзе әйтмешли, «күңел күзе ачыла». «Гафуриның «Яшь гомерем» мәҗмугасын укып, беркемнән дә җавап ала алмаган фикерләремә теләктәшлек таптым». Гафурины ул, хөрмәтләп, гомер буе үзенең остазы, укытучысы санаячак.

1907–1914 елларда башта Уфада башкорт кызлары приютында, аннары Пермь шәһәрендә күбрәк эшче балаларын укыта. Эшчеләр арасында яшәү, аларның авыр хезмәтен, кызыксыз, ярлы тормышын күрү аңарда гадиләрне кызгану, аларга теләктәшлек итү теләген көчәйтә. Күңелендә кайнаган шул хисләрне шигъри юлларга салудан үзенә юаныч таба. Шуңа да аның бу чор иҗатында татар хатын-кызының хокуксызлыгы, язмыштан зарлану мотивлары өстенлек итә. Гомерен ул игелекле эшкә – татар балаларына аң-белем таратуга багышларга карар кыла. Һәм чыннан да кырык ел буе укытучы булып эшли, әмма икенче канаты – иҗат эшчәнлеге дә гомерлек юлдашына әйләнә. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, чарасызлыктан кан коярга мәҗбүр булган ватандашларының сугышка нәфрәтен чагылдырган әсәрләре «Сөембикә» журналында бер-бер артлы басыла башлый. Ә революциядән соң, татар телендә газета-журналлар чыга башлагач, шагыйрәнең үткен, хисле шигырьләре матбугатта аеруча еш күренә. Ул, Пермьнән торып, Мәскәүдә һәм Казанда чыга торган газета-журналларга актив язышa. Шигырьләренең күбесенә «Татар хатыны» имзасы куя. 1918 елда Пермьне Колчак гаскәрләре басып алгач һәм активистларны кулга алып җәзалап үтерә башлагач, ул әүвәл Алабугага, аннан Казанга күченеп кайта. 1918–1925 еллар – шагыйрәнең иҗаты киң колач алган дәвер. «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналында, газеталарда аның зур сәяси вакыйгаларга – хөрлек, милли азатлык вәгъдә иткән большевиклар хакимиятенә, кызыл сугышчыларга дан җырлаган әсәрләре басылып тора. Тигез хокуклылык, гаделлек идеяләре белән рухланып, яңа тормыш төзергә керешкән хезмәт кешеләренең, бигрәк тә хатын-кызларның хыялдагы образын иҗатында гәүдәләндерә. Ана, хатын-кыз образы гаҗәеп бер җылылык белән, тирән кичерешләр аша тасвирлана. Шагыйрә баштагы әсәрләрендә татар кызын кимсетелгән, дөнья баскан, ире өчен «ким кеше» итеп күзалласа, Октябрьдән соң ул инде ирләр белән бер сафта ил төзүче, яңа тормыш коручы, яңашәдәгеләргә киңәш бирүче, күңеле төшкәннәрнең рухын күтәрүче итеп тасвирлана. 1919 елда дөнья күргән «Ил кызына» шигыре җете төсләр белән Заһирә Байчуринаның үзенең дә теләк-хыялларын чагылдыра: «Ялтырап чыксын җиһанга киң йөрәкле ил кызы; / Бу кара илне агартсын илнең изге йолдызы! / Тор! Уян! Бас син аякка, ал әләмне алдыңа! / Күп гомер уздырдың инде, үкенеп туганыңа!»

«Күтәр башың, турайт сыңың – син хатын-кыз!»

1922 елга кадәр язган шигырьләренең байтагы тупланган «Шигырьләр мәҗмугасы» дигән җыентыгы 1923 елда басылып чыга. Шул ук елны бер бәйләм шигырьләре Фәтхи Бурнаш төзеп чыгарган «Көрәш җырлары» дигән җыентыкта да урын ала. 1959 елда «Ана сүзе» исемле китабы дөнья күрә. XIX йөз ахыры һәм XX йөз башында иҗат иткән татар хатын-кыз язучыларының әсәрләре тупланган «Өмет йолдызлары» исемле күмәк җыентыкта да (1988) Заһирә Бурнашева шигырьләре урнаштырылган.

1935–1939 еллар арасында Заһирә Гали кызы Казанның район советында депутат була. Тормышының кырык елын укытучылык эшенә багышлаган тынгысыз йөрәкле шагыйрә гомеренең соңгы көннәренә кадәр (ул 1977 елның 26 декабрендә Махачкала каласында вафат була) бөтен көчен һәм тормыш тәҗрибәсен яшь буынны тәрбияләү эшенә багышлый.

Роза КАМАЛЕТДИНОВА



ПАРТИЗАН КЫЗ ЧӘЧКӘ

Чәчкә Миңнегали кызы Заһирова 1923 елның 21 июлендә Сарман районының Анак авылында туган. 1940 елда Чистайда урта мәктәпне тәмамлаган. Шул ук елны Мәскәү авиация институтына имтихансыз гына укырга кабул ителгән. Беренче курсны тәмамлап өлгергән Чәчкә, үзе теләп, сугышка китә. Разведчик-диверсант буларак, 1941 елның октябреннән 1944 елның 20 июленә кадәр дошман тылында хәрәкәт итә. Аннары, сугыш тәмамланганчы Совет Армиясе сафларында була. Партизан кыз Чәчкә Заһированың батырлыгы Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, I дәрәҗә «Ватан сугышы партизаны», «Мәскәү оборонасы өчен» медальләре белән билгеләнә. Сугыштан соң, Мәскәү авиация институтын тәмамлагач, Чәчкә Заһирова озак еллар авиация заводында эшли, фәнни эш белән шөгыльләнә, институтта укыта. Ул 2013 елның 14 апрелендә Казанда вафат булды. Әтисе истәлегенә багышланган «На пути к твоей памяти» дигән китап язуны ул тормышының бер изге максаты итеп куйган иде. Яңа гына типографиядән чыккан китабын күкрәгенә кысып, Чәчкә ханым соңгы сулышын ала.

Чәчкә Заһирова белән мин аның вафатына ике ел кала танышкан идем. Батыр партизанканың сугышчан юлы хакында сөйләтү нияте белән өенә килгәч, ул кырт кисеп: «Мин ул хакта үзем китап язам. Китап чыкканчы баштан кичкәннәрем минем серем булып торсын әле. Миңа ярдәм итәсең килсә, син миңа 16 нчы санлы машинка тасмасы табып бир», – диде. Машинка тасмасын табып илттем. Аңа бик куанды. Үзе инде бу вакытта почмакта торган компьютерга да сынап-сынап карап ала башлаган иде. Мөгаен, ул аны да буйсындыра алгандыр. Чәчкә ханым белән очрашуларда ул һаман сугыш юлларында хәбәрсез югалган әтисенең соңгы сугыш урынын табу, тапкач, аның исемен мәңгеләштерү мәшәкатьләре хакында гына сөйләргә омтылды. Чыннан да, ханымның гражданлык каһарманлыгы да олы бәягә лаек иде. Әтисенең каберен эзләп тапкач, ул анда һәйкәл куйдырта, аннары, Моцартка ияреп, ун бүлектән торган Реквием иҗат итә. Яуда һәлак булган авылдашлары истәлегенә яңартылган Кырык Чишмә, Анак авылын төреп алган алма бакчасы, Казандагы 70 нче мәктәп ишегалдында әтисенең сугышчан дусларына, 99 нчы мәктәп каршында легендар Зоя Космодемьянскаяга куелган һәйкәлләр...

Бу Чәчкә Заһирова кылган игелекле гамәлләрнең беразы гына.

Инде, ниһаять, аның партизан юлы бәян ителгән китапны кулыма алдым. Искиткеч китап. «Корыч ничек чыныкты», «Чын кеше», «Кигәвен» кебек китаплар белән янәшә торырлык, тәрбияви, мәгънәви китап яза алган Чәчкә Заһирова. Иң мөһиме – анда бернинди ялган, дәлилсез җөмлә юк. Ләкин бу китапның тиражы нибары 100 данә!!! Кемдер: «Акчасы йөз данәлек кенә булгандыр», – дигән җөмлә ташлады. Ояла да белмибез инде. Югыйсә Җиңү көне тәхетенә яшьлеген салган кеше бит ул!

Чәчкә Заһирова исемен халыкка якынайту өчен, шул – «На пути к твоей памяти» дигән китапның кайбер урыннарын тәрҗемә итеп, журнал аша сезгә тәкъдим итәргә булдык.

Асия ЮНЫСОВА

Көзге урманны яратмыйм

«Безнең институтны Алма-Атага эвакуацияләделәр. Ходай биргән форсаттан – броньнан мин файдаланырга теләмәдем. Туган илемнең башкаласы Мәскәүнең капкасын дошман шакый, һәм мин аны сакларга бурычлы идем. Фронтка китәргә, кулыма корал тотып сугышырга тиеш идем. Шәфкать туташы итеп кенә җибәрүләреннән шикләнеп, хәрби комиссариатка барып тормадым. Турыдан-туры Комсомолның Үзәк комитетына киттем. Анкета тутырттылар. Кичтән килергә куштылар. Мәскәү язмышы кыл өстендә торган көннәрдә барысы да тиз хәл ителә иде.

Кичтән мин инде түшенә Кызыл Байрак ордены таккан майор Спрогис каршында утыра идем. Минем анкетам белән танышкач, Спрогис (ул милләте белән латыш иде) болай диде: «Сезнең шәфкать туташы дигән хәрби белгечлегегез бар (курсларга йөргән идем), шул юлдан китсәгез, дөресрәк булмасмы? Разведкада бик авыр һәм хәтәр бит. Дошман тылында шартлату-разведка эшләре алып барырга туры киләчәк. Мәскәү янында дошман тора. Сезне үтерергә мөмкиннәр. Бик куркыныч безнең эш. Кат-кат уйлагыз». «Уйладым инде», – дидем. Аннары сөйләшүебез беркадәр романтик төсмер алды. «Чәчкә дигән исем разведчик өчен түгел, башка исем табарга кирәк булыр». Мин үземә исем сайлаган идем инде: Рита – «Корыч ничек чыныкты?» романындагы кызның исеме. Бу исем Спрогиска да ошады.

Шулай итеп, 1941 елның 15 октябрендә минем сугышчан юлым башланды. Безне нибары биш көн укыттылар: винтовкадан, автоматтан атарга, разведка мәгълүматы туплау серләренә, мина кую осталыгына өйрәттеләр. 19-20 октябрьдә төркемнәр оештырылды. 19 октябрьдә минем янга уртачадан озынрак буйлы егет килеп басты. «Мин Боровиков, сезнең командирыгыз булам», – диде. Шуның белән шул. Ул командирларны да командалык итү осталыгына укытып тормаганнар иде бугай.

Соңгы ике көндә безне киендерделәр, корал бирделәр, биш көнлек азык тоттырдылар. Кием дигәннән, кирза итек белән аяк чолгавы инде ул. Шәл белән бишмәт үзебезнеке. Корал дигәннән, ике граната, наган, икешәр мина, һәм тагын әле мина өчен берничә запал... Безнең коралның иң хәтәре запал булгандыр. Мин аны бишмәтемнең эчке кесәсенә салып куйдым. Аз гына бәрелүдән дә запал бик тиз шартлый. Берничә килограмм шартлаткыч тол да алганбыз икән әле. Шуларны салгач, биштәрнең авырлыгы ун килолап булгандыр. Шулай итеп, без, өч төркемнең разведчиклары, дошман тылына үтеп керергә әзер идек. 9903 нче гаскәр составындагы өч төркемнең сугышчылары – барысы 27 кеше Мәскәү өлкәсенең Можайск шәһәре тирәсенә тәгаенләп чыгып киттек. Безне тугызар кешелек өч төркемгә бүлделәр. Фронт сызыгын гаскәр разведкасы ярдәмендә кич соң гына кичтек. Фронт сызыгы дип йөртелгән урын тар гына буйурман. Кайдадыр еракта туплар шартлый. Әмма без кичкән урында тыныч иде. Буйурман беткәч, гаскәр разведкасы безгә имин юл теләп, кире борылды. Немец тылында без үзебез генә калдык. Ачык урыннан бара башладык. Көн болытлы булса да, яңгыр яумый иде. Иртәнгә кадәр бардык шулай. Аннан ял итәргә туктадык. Шунда ук йоклап киткәнбез. Тик безнең йокыны ату тавышлары бүлде. Безгә төбәп аталар иде бугай. Пулялар баш өстендә генә сызгырып үтә.

«Башларыгызны күтәрәсе булмагыз!» – диде командир. Беренче атыш вакытында ук төркемебез сибелеп китте. Атыш тынгач, киткәннәрнең кире борылып килгәнен көтеп алдык. Тик барыбер ике кешебез әйләнеп килмәде. Пулемет утына дучар булган сирәк урманлыктан алдагы куерак урманга 300 метрлап ара бар иде, аны йөгереп узарга тырыштык. Алай да урман авызына кереп барганда тагын атыш башланды. Шул урманда төн үткәрдек.

Икенче көнне иртән җитәкчебез Боровиков мине үз янына дәште. Алдында карта ята. «Рита, сиңа разведкага барырга туры килер, – диде ул. – Кызыл бишмәт киеп килгән кызларны җибәреп булмый бит инде. – Әнә теге авылның исемен белеп кил. Алайса, без адашырбыз. Әгәр авылда немецлар булса, аларның санын, гаскәр төрен ачыкла». Мин командирга наганымны, запалларны калдырдым да беренче разведкама киттем. Берәр чакрым барганнан соң, урман бетте. Каршымда, уйсулыкта авыл җәйрәп ята. Авыл өч яктан урман белән уратылган. Күзәтә башладым. Бер урамлы авылда йөзләп йорт санадым. Немецлар бар иде. Алар күп иде. Сөйләшкәннәре миңа кадәр ишетелеп тора. Курыктым, ләкин авылга керергә кирәк иде. Мин киттем. Тәвәккәлләп, бер өйнең бәрәңге бакчасына илткән сукмактан атладым. Җилкапканы ачып, ишегалдына кердем.

Ишегалдында бер төркем немецлар шаяра-көлә юынып яталар иде. Мине күрмәделәр дә бугай. Кара син боларны, үз өйләрендә кебек кыланалар! Аларның әрсезлеге миңа көч бирде. Шакып-нитеп тормый гына өйгә кердем. Урта яшьләрдәге хатын миңа сәерсенеп карап тора, ә мин аңа үз әкиятемне сөйлим. Имеш, адашканмын, окоп казыган җирдән Истра шәһәрендәге тутама кайтып барам. Юлны белмим, кебегрәк.

Апа миңа мичтә пешкән ике бәрәңге бирде. «Кит тизрәк, өй саен биш-алты немец тора. Тиздән бөтен бәрәңгене ашап бетерәләр инде», – диде. Әһә, димәк, бу авылда биш йөзләп немец тупланган. Гаскәр төрен чамалаган идем инде. Авыл исемен дә белеп алдым. «Берүк, бәрәңге бакчалары аша йөрмә. Атарлар. Немецлар партизаннардан бик курка. Төнгә авыл тирәли сак куялар. Аллаһ юлдашың булсын!» – дип озатып калды мине игелекле хатын. Мин безнекеләр янына исән-имин кайтып җиттем.

Моннан соң да әле Боровиков мине күп мәртәбәләр разведкага җибәрде... Тик берьюлы ул үзе дә югалды. Командир югалганчы күпер шартлатырга барганыбыз хәтердә. Мин запал биреп тордым. Күперне күккә очыргач, калган миналарны алып, таш юлга таба киттек. Шунда мин үз кулларым белән беренче миналарны урнаштырдым. Аннары запалны салдым да сәгать меха-

низмын көйләп куйдым. Сәгать текелдәгән арада минаны туфрак белән яшердем. Аннары икенче минаны куйдым... Үзебез ераккарак киттек тә ни булырын көтеп тора башладык. Мотоцикл үтте, мина шартламады. Тиздән йөк машиналары күренде. Бер-бер артлы ике шартлау ишетелде. Өченчесе... Сакта калган Боровиков безнең янга йөгереп килде: «Заһирова куйган миналарда ике машина, Юшина минасында бер машина шартлады», – дип хәбәр итте ул. Немецлар эзгә төшкәнче качарга ашыктык.

Бу минем беренче имтиханым иде. Канәгать калган идем бугай. Дошман тылына мин бит фашистларны үтерү нияте белән барган кеше. Ул беренче заданиедә немецлар кинәт ата башларлар да мина минем кулда чагында ук шартлар дип нык курыкканымны хәтерлим. 1942 елның җәендә бер чатырда йоклаган, бер котелоктан ашаган, дошман басып алган Белоруссия җирләре буйлап йөзләрчә чакрымнарны бергә атлаган Паша Целуйконың ягымлы йөзе күңелемдә яңара. Ул иң оста шартлатучыларның берсе иде. 14 мәртәбә шартлату операциясен менә дигән итеп башкарып чыкканнан соң, унбишенче заданиене үтәгәндә һәлак булды. 1944 елның җәе җиткәч, инде безнең гаскәрләр Белоруссия җирләренә аяк баскач бит әле – шунысы бигрәк аяныч. Аягын гына табып күмдек.

Үлемнәрнең төрлесен күрдем. Бервакыт Мәскәү тирәсендә заданиедән кайтып киләм. Урман бетте дә алдагы авылга кердем. Аңынчы бик озак авылны күзәтеп тордым. Тормыш әсәре сизелми, хәтта этләр дә өрми. Берданбер урамнан атлыйм. Бер кеше очрамый. Урамның азагына килеп чыккач кына аңлап алдым. Монда сугыш булган. Авыл читендәге берничә йорт җимерелгән. Куаклыкта, күптән түгел генә казылган окоплар янында безнең солдатларның үле гәүдәләре ята. Якын килеп карагач, котым очты: бер генә дә бөтен гәүдә калмаган иде. Башлар, аяклар, куллар ята... Кешеләрнең йөзләре танымаслык хәлгә китерелгән. Безнең сугышчылар соңгы сулышкача сугышып үлгәннәр иде. Авыл кешеләре, мөгаен, урманга качып калганнардыр. Ә фашистлар Мәскәү тарафына киткәннәр булыр.
Бу үлеләр тавы – сугышның рәхимсез чырае мине гомер буе эзәрлекләр. Сугыш юлларында үлем белән күп мәртәбәләр очраштым. Минем кулымда көрәштәшләрем җан бирде. Алар кичергән газаплар мине әле дә әрнетә. Болар барысы да аннары. Әлегә без Можайск шәһәреннән төньяктарак урманда торабыз.

Тугыз кеше өч төркемгә бүленеп, ягъни өчәр-өчәр булып, әрәмәлектән зур урманга таба чабып үттек. Нигә көн яктысында эшләткәндер инде моны командир – әле булса да аңлый алмыйм. Үзе беренче төркемдә китте. Мин икенче төркем белән идем. Безгә ата башладылар. Көч-хәл белән урман авызына килеп җиттек. Шулай да егетләрнең итегеннән этләр каптырып алгалады.
Бер егет этнең авызына винтовка түтәсе белән бәреп котылды. Эт, шыңшый-шыңшый, хуҗалары янына чабып китте. Без тизрәк урманга чумдык. Немецлар да бераздан кире киттеләр. Инде алгы төркем белән киткән командирыбызны – Боровиковны көтәбез. Килешенгәнчә, сызгыргалап алабыз. Юк, килмәде командир. Соңгы өчлек тә безнең янга чыга алмады. Командирыбыз нилектән безне ташлады? Мин бу хакта гомер буе уйландым, җавап таба алмадым. Ике урман арасын кичкәнче мин Боровиков яхшы командир дигән уйда тора идем.

Төнне ылыс түшәп кундык. Ашарга беткән иде инде. Шартлаткычлар да бетте. Өчебезгә өч мина бар. Карта, компас ише әйберләр дә юк. Бу өч минаны без таш юлга куярга булдык. Мин үземдәге гранаталарны да миналар янына салырга булдым. Көчлерәк шартласын! Егетләр дә шулай эшләделәр. Ераграк киттек тә көтәбез. Тиздән ике шартлау ишетелде.

Инде тамак ягын кайгыртырга кирәк. Мин, тәвәккәлләп, бәрәңге басуы эзләп киттем. Ике чакрымнар баргач, уңышы җыеп алынган басуга килеп чыктым. Кырыйдарак казылмый калган рәтләр бар икән. Кулларым белән чокый-чокый бер биштәр бәрәңге җыеп алдым. Мин әйләнеп килгәч, аны көлгә күмеп пешердек.

Кире кайтыр якка борылырга, юлны чамалар өчен разведка ясарга кирәк иде. Командир булып калган Вересов якындагы авыл аша турыдан үтәргә тәкъдим итте. Мин каршы идем, тыңламады. Имеш, финнар белән сугышканда авыл аша йөргәннәр, берни булмаган. Кердек авылга. Немец патрульләре күренде. Таныш сүз яңгырады: «Хальт!» Безне фаралар белән яктырттылар. Атмыйлар әле. Вересов уңга омтылды. Читтәнгә үрмәләргә азапланганын гына күреп калдым. Патруль аның артыннан ташланды. Без Данилкин белән сулга ыргылдык. Фаралар яктыртып туктаганчы җиргә сеңеп тордык. Фаралар сүнгәч, күпер астына ташландык. Безнең арттан ата башладылар. Күпер астыннан шуышып чыгып, үр өстенә үрмәләдек. Бу үр буйлатып тар тимер юл үтә икән. Аны да шуышып үттек. Теге якта тирән чокыр башлана. Чокыр төбеннән пычрак су ага. Немецлар безне югалттылар, әмма эзләүдән туктамадылар. Чокыр төбеннән шуышып бара торгач, цемент заводына килеп төртелдек. Үзебез дә цементка батып беттек. Чокыр заводның теге ягында дәвам итә икән. Шул якка омтылдык. Тик... безне патруль каршылап торган булып чыкты. Без каптык!

Шушы хәлиткеч мизгелдә Данилкин бер карарга килде: «Рита, мин үзем генә чыгам. Икәү булсак, партизаннар дип уйларлар, атарлар. Курыкма, мин сине сатмам. Әкрен генә артка таба шуыш. Мин винтовкамны суга ташладым». Юаш кына булып күренгән 18 яшьлек егет әсир төшәргә китте. Аның: «Мин үзем генә, үзем генә...» дип кабатлаганын ишетеп тордым, һәм чарасызлыктан чокыр төбендә елап яттым.

Ялгыз калдым. Бу каһәр төшкән урыннан ераграк китәргә кирәк иде. Чокыр төбеннән шуыштым да шуыштым. Чокыр юлга килеп терәлде. Әле караңгы иде, ләкин юлның аръягында урман барын абайладым. Гәрчә бу бәләкәй урман тыныч урын булып чыкмады. Ул һәр яктан немец танклары белән урап алынган иде. Шулай булса да, урман мине коткарды. Урманга җиткәч, ике

йөз метрлап эчкә кердем. Киң ябалдашлы чыршы төбендә коры урын таптым. Әкренләп һушымны җыеп, өс-башымны караштыра башладым. Тәмам цементка пычранып беткән идем. Аяк чолгауларын алыштырдым. Пычрак чолгауларны яңгыр суында юдым. Көч-хәл белән бишмәтемне чистарттым. Итекләремне юдым. Аннары коралымны карарга керештем. Наганым балчыкка батып беткән икән. Аны сөрткәләп, кабат кобурага салдым да чыршы астына куйдым, өстен коры ылыслар белән капладым. Торып торсын әле. Битләремне сөрткәләдем, күзгемнән карадым. Бер-ике сәгать үткәндер.

Ни белән генә мәшгуль булсам да, шушы ике көндә баштан кичкән фаҗигале хәлләр тынгылык бирми. Бер яктан караганда, хәрби хезмәтем уңышлы гына башланып киткән кебек иде. Авылга разведкага әйбәт кенә барып кайттым, күпер шартлатуда катнаштым, миналар куеп машиналар шартлаттым... Кызганычка каршы, фаҗигале хәлләр күбрәк икән шул: төркемебез таркалды, иптәшләрем, бәлки, һәлак булганнардыр. Ни генә булмасын, мин бит әле һаман 9903 санлы диверсия-шартлату частенең сугышчысы булып калам. Димәк, мин илбасарларга каршы көрәшне дәвам итәргә бурычлы. Ничек көрәшергә икәнен уйлармын әле. Карарым нинди генә булмасын, миңа көнчыгышка таба барырга, үзебезнең базага әйләнеп кайтырга кирәк. Ләкин моның өчен иң элек бу урманнан чыгарга кирәк. Сак кына йөреп, урманның тирә ягын күзләп чыктым. Бөтен якта танклар. Димәк, биредә зур гына танк часте урнашкан. Йөзләп танк санадым. Урманның көнчыгышка ачылган тарафында гына танклар юк. Аның каруы, анда патрульләр йөреп тора. Шул яктан юл да уза.
Фронт сызыгын кичеп кайтыр юлымда мәгълүмат туплый барачакмын – шулай хәл иттем. Димәк, миңа урманнан чыгарга кирәк.

Мин берәр сәгать юлны күзәтеп тордым. Ара-тирә йөк машиналары уза, кайвакыт кешеләр дә күренгәли. Аларны патруль туктатып тикшерә. Фронт сызыгына кадәр 60 чакрымлап бардыр дип уйлыйм. Һәр авылда диярлек немецлар, юлларда патрульләр. Мин наганны калдырырга булдым. Урманнан корал тотып чыгу үлемгә бәрабәр. Наганымны коры чүпрәккә төреп, күмеп куйдым. Эзләп килермен әле. Икенче адым – урманнан чыгу. Патрульләр юк вакытны чамаладым. Можайск ягыннан ике хатын килә иде. Тиз генә шуларга иярдем. Исәнләштем. Алар миңа сөенделәр дип әйтә алмыйм. Үземнең моңсу әкиятемне сөйләргә керешкән идем, берсе тиз туктатты: «Без мондый тарихларны күп ишеттек инде. Сиңа бездән ни кирәк?» – диде. Мин, мескенгә сабышып, гафу үтендем. «Берүземә генә куркыныч, немецлардан бик куркам, юлны белмим. Бәлки, миңа сезнең белән бер яккадыр», – дидем.

Бу хатыннар белән мин ике юл чатына кадәр бардым. Аннары алар миңа көнчыгышка юлны күрсәттеләр. Исемнәрен сораша-сораша авыллар аша үтәм. Патрульләр туктата, капшый, аннан җибәрәләр. Авылларның берсендә куна да калдым. Өенә теләр-теләмәс кенә керткән хатын минем әкиятемне тыңлап та тормады. Туеп беткәннәр инде. Алай да юынгычка су салып юындырды, чуеннан бәрәңге ашатты. Сорамасам да, разведчик өчен кызыклы бик күп нәрсәләр хакында сөйләде. Мин һәр мәгълүматны башыма сеңдерергә тырышам. Фронт сызыгын ничегрәк кичү хакында да сүз башлады. Хатын миңа алга таба юлдан бармаска кушты. Цементка каткан чәчләремне юдыртты. Иртән мине озатып калды. Ул күрсәткәнчә, урман аралатып китеп бардым. Тик, кызганыч ки, урман юллары мине фронт сызыгына якынайтмады. Сазлыклы урман аша бару тәмам йончытты. Шул заманнан мин көзге урманны яратмас булдым. Минем сугыш юлларым башлана гына иде әле. Алда бик авыр көннәр булыр, әмма шул көннәр арасында мине шушы урман юлы китергән дүрт көн аерым бер урын били. Монда немец хәрби частенең штабында эшләп алу да, концлагерьда булу да, аннан качу да бар. Мин ул көннәрдә яшәү белән үлем арасында булдым. Разведчик сыйфатында кыйммәтле мәгълүматлар туплый алу кадәресен бәхеткә санадым үзе. Ул көннәрдә минем белән булып узган вакыйгалар кеше ышана торган түгел иде.

Асия ЮНЫСОВА тәрҗемәсе.

(*Дәвамы киләсе санда.*)



ТИРӘКЛӘР

(Баллада)



Рәсимә
ГАРИФУЛЛИНА

Имәннәрне ирләр белән тиңләп,
Йөртә халкым йөрәк түрендә.
Сабырлыгын шул имәннәр белән
Чагыштыра гомер-гомергә.

Имәннәр күк иде алар да нәкъ,
Кырык бернең җәе җиткәндә.
Ил өмете, киләчәге иде –
Бөтен эшләр шушы җилкәдә...

Берәм-берәм түгел, төркем белән,
Хәбәр килде бөтен авылга.
Ирләр кирәк иде яу кырына –
Дошманнарга каршы барырга.

* * *

...Каенлыдан чыгып китте алар,
Утыз берәү иде – ат өсте.
Хатыннарның кайгы яшен сөртеп,
Юатырга теләп, җил исте.

Кыр капкасын чыккач, аттан төшеп,
Тын калдылар бермәл барсы да.
Кочагына яшь тирәкләр тотып,
Авыл карты чыкты каршыга.

– Күңел сизә, бик зур афәт килә,
Көрәш авыр булыр, балалар.
Утыртыгыз шушы тирәкләрне,
Сезнең ядкарь итеп карарлар.

Йөрәкләрдә кан-яшь дөрләгәндә
Шуңа карап сагыныр аналар.
Озак көтеп хатлар килмәсә дә,
Өмет хисе белән янарлар...

Киң күкрәкле, нык бәдәнле ирләр
Тыңладылар олы карт сүзен.
Тып-тын гына агач утырттылар...
Инсан йөрәкләре бик түзем.

Сүзсез генә чокыр казыдылар,
Туган җир бит, газиз, кадерле.
Әллә инде казыдылар алар
Үзләренә дигән каберне.

Яуга киткәннәрнең төсе булып
Тезелеп калды яшь-яшь тирәкләр.
Аксакаллар намаз укыдылар:
Дога булсын диеп теләкләр.

Утыз бере бергә чыгып китте,
Утыз бере кире кайтырмы?
Утыз бер төп тирәк утырып калды...
Барысы да тоташ кайгылы.

* * *

Китсәләр дә төркем-төркем булып,
Берәм-берәм килде хатлары.
Киткәннәрнең утыз бере түгел,
Унбише дә кире кайтмады.

Җанны сызып, ят конвертлар килде,
Фронттагы хәлне сөйләргә.
Алар белән яман хәбәр килде,
Кайгы килде ятим өйләргә.

– Яуда башын салды, – дисәләр дә,
Өмет рухы барыбер сынмады.
Сагынуга түзә алмаганнар
Тирәкләрне кочып елады.

Ә тирәкләр яшәү вәгъдә итеп,
Яз җитүгә яфрак ярдылар.
Толлар күңеленә дәва булып
Бөреләргә өмет салдылар.

* * *

Тылдагылар барсына да түзде:
Ач килеш тә иген иктеләр.
Фашистларны җиңеп
кайтсыннар дип,
Күпме михнәт, газап чиктеләр.

Алар гына ачка интекмәсен,
Башкайлары гына сау булсын.
Газизләре илгә Җиңү яулап,
Исән-имин кайтыр яу булсын!

Барысы да кайта алмады шул,
Кабул булмадымы теләкләр.
Якыннары өзелеп көтсәләр дә,
Шаулап үссәләр дә тирәкләр.

Имәннәр күк ирләр төсе булып,
Калды бары шушы тирәкләр.
Утыз бере бергә искә төшеп,
Сулыгып-сулыгып куя йөрәкләр.

Утыз бердән өчәү кайтты алар,
Аяксыздан-кулсыз – гарипләр.
Имән төсле ирләр иделәр бит...
Җаннары бар кем соң гаепләр?

Аяксыздан-кулсыз булсалар да,
Җаны иде алар авылның.
Батырлыкның зур үрнәге иде,
Кайтавазы үткән давылның.

* * *

Яралары тынгы бирмәделәр –
Кайтканнар да мәңгелеккә күчте.
Ачы югалтулар артты бары:
Алар китте, тирәкләре үсте.

Һәм тирәклек зиярәт кыла торган
Изге җиргә калды әйләнеп.
Картлар килеп дога кылган чакта,
Яшьләр куйды чәчәк бәйләме.

Кем үтсә дә баш киемен салып,
Сәлам биреп кала тирәкләр.
Бу тирәкләр тере һәйкәл бүген,
Сезне сагынып шаулый, егетләр.

Нәкъ имәннәр төсле иде алар,
Кырык бернең җәе җиткәндә.
Бөтен авыл озатып калган иде
Яу кырына чыгып киткәндә.

Кырык бердә чыгып киткәннәрнең
Бик күпләре кире кайтмады.
Көрәшләрдә башын салган ирләр
Ватан исемен, данын яклады.

СӨЕНЕЧКӘДЕР – ӨЧЫНАМ...



Эльвира
САФИНА

* * *

Күзләреңә карыйм –
Салкын...
Кайчан гына иде –
Төпсез ялкын.
Сүзләрең дә никтер
Хиссез...
Аңлаша идек бит
Сүзсез.
Сөю чәчкәбез ник
Иссез?
Мәхәббәт калганга
Төссез?
Яшим шулай
Төссезлектә...
Хиссезлектә...
Әллә ничек –
Көйсез...

Иң зур бәхет

Тоеп яшим әти-әни яратуын,
Илһам алам күреп таң атуын.
Яшәү көче бирә сине яратуым,
Моннан да зур бәхет
бармы җирдә тагын?

Тормышыма мәгънә өсти
якыннарым,
Өметләрем, борчуларым,
шатлыкларым.
Тоеп яшим янәшәмдә сөю барын,
Моннан да зур бәхет
бармы җирдә тагын?

Матур уйлар уйлап,
моң җырларым җырлап,
Илләр-җирләр гизәм,
яшим өмет белән.
Ләззәтләнәм күреп
җиһан матурлыгын,
Моннан да зур бәхет
бармы җирдә тагын?

Күбәләкле яшьлек

Балачакның матур җәйләренең
Бүтән инде әллә ямьнәре?!
Кулларымда кипкән кыр чәчәге,
Иренемдә җиләк тәмнәре.

Күбәләкләр генә һаман шулай,
Куна чәчәкләргә чәчәктән.
Алып килгән сыман куаналар,
Кайнар сәлам безгә яшьлектән.

Гомерләрнең җәе генә түгел,
Була икән язы, көзләре.
Җәйдә генә түгел, көзләрдә дә
Шаулап чәчәк атсын гөлләре.



Лилия
ФӘТТАХОВА

Нигә сүзләр?!

Каләмемне алдым, куйдым бүген...
Куйдым... алдым...
Телем – ярлы.
Вакланмасмы хисләрем дип,
Уйга калдым.
Үҗәт акыл дилбегәне йомшартты да –
Сулу алдым –
Дөнья шулкадәрле гүзәл икән!
Хәйран калдым!
Сөю көен көйли җаным –
Нигә сүзләр?!
Күңел багым уртасында –
Синең эзләр.

Керфегемә Төн эленгән

Керфегемә инде
Төн эленгән...
Айдан төшкән
Өлгер Зөһрә-кыз
Бер әкият сөйли
Моңлы көйгә.
Ул әкият –
Сөю турындагы –
Синең турындагы татлы төш.
Бүген Көнем
Синсез төссез иде,
Төнем якты итте тулган Ай:
Йолдызларны
Бераз читкә этеп,
Күктән сукмак салып
Килгән ул
Һәм Төш элгән керфек очына.
...Бер тамчы яшь
Тәгәрәде биттән.
Сөенечкәдер ул –
Өчынам...

Туй

Мәхәббәт таҗын кидерә
Сөйгәннәр сөйгәненә.
Шаһинә тәхете әзер
Сөйгәннең йөрәгендә.

Татлы төшнең дәвамы ук
Яратып, назлап дәшү.
Якты хисләр танго бии
Үз телендә серләшеп.

Мәңге дәвам итәр кебек
Төшле-өнле бу халәт.
...Бүген – бер өйдә туй гөрли,
Өй түрендә – мәхәббәт.

Сиптем – җыям

Сиптем – җыям уйларымны,
Сүттем – җыям.
Көйсезен дә, көйлесен дә
Бергә куям.

Минем уйлар – минем язмыш –
Үрелеп бара.
Асыллары тыйнаграк,
Чүбе – сара...

Башсыз җайдак чагым була –
Көчсез чагым.
Йомычкадай алып китә
Көчле агым.
Ишкәкләрне – уйларымны
Кулга алсам,
Офыкларны күреп алып,
Ишәм тагын.

Мин – иясе уйларымның,
Мин – хуҗасы.
Ничек сызсам сызымымны –
Шул буласы.



Гүзәл ӘДҺӘМ

СӘЙДӘ, СЫЕРЧЫК ҺӘМ ЯЗ

(хикәя)

Сәйдә әнисенең күлмәк итәгенә сарылды:

– Әни, ими бир!

Сания дерт итте, томырылып кызчыгына төбәлде:

– Тагын, тагын кабатла!

– Ими бир!

– Бирәм, бирәм, балам. Ник бирмим, ди!

Кызын җитез генә алдына алып, кабалана-кабалана изүен чиште:

– Кызымның теле ачылган! Үскәнем бит ул минем!

Сәйдә исә йомшак җылы күкрәккә борынын төртте. «Тик әбисе генә сизмәсен! Тагын ачулануы бар! Кичә дә әнисенә эләкте...»

... – Тагын имезәсеңме?

– Әз генә булса да эченә сөт керсен дим...

– Дүрт яшен тутыра лабаса. Имезмәсәң дә була... Сине кызганып әйтүем лә... Чыкмаган җаның гына калып бара, тәмам күләгәгә әйләнгәнсең ләбаса!

– Ашарга бигрәк берни калмады бит, әнкәй. Ярый әле, бәрәңге коткара.

– Сыерыбыз исән-имин бозауласа, рәтләнеп китәрбез, Алла боерса.

– Сыер бозаулаганчы гына имезим инде... Күп калмады бит...

Шундый тәмле ими белән сыер арасында нинди бәйләнеш булуын Сәйдәнең нәни йөрәге һич кенә дә төшенеп җитә алмый, ул җылы рәхәтлеккә изрәп, әнисенә сыена.

«Әби генә сизә күрмәсен!»

Сизмиме соң?! Ни арада ишетүе дә, ни арада килеп тә җитүе. Тик, нигәдер, ачуланырга уйламый үзе. Тешсез авызын ерган да, әллә нигә кеткелди шунда:

– Сөбханалла-машалла! Кызыма сыерчыклар тел алып килгән түгелме соң?!

Әнисе дә шат. Сәйдәне тагын да кыса төшеп, борын очыннан үбеп алырга да өлгерә:

– Үзе, үзе сорады. «Ими бир әле», – ди бит. Маясмага (Маһиәсма) бик ачуым килгән иде. «Дүрт яшен тутыра бит инде. Ул кызыгыз ник сөйләшми суң? Әллә телсезме?» – дигән була. Нишләп сөйләшмәсен, ди? Сыерчыкларны көткән ул, имә, кызым!

Сәйдә бер генә мизгелгә имүдән бүленеп, алсу иреннәрен җәйде:

– Сы-ер-чык...

– Сөбханалла! «Сыерчык», – ди! Дөрес итеп әйтүен күрче!

Сәйдәнең теле ачылу сугыш сөреме каплаган күңелсез йортны ямьләндереп җибәрде...

...Атна-ун көн дә узмагандыр, әбисе, Сәйдәгә тел алып килгән сыерчыкларны мактый-мактый, кызчыкка әллә никадәр сүз өйрәтеп тә өлгерде. Сәйдә инде өй эчендәге һәрнәрсәне дә исеме белән әйтә. Өстәл, сәке, мендәр, юрганнарга әбисенең төртеп күрсәтүе була, хәзер чатнатып әйтеп тә бирә. Әбисе аны гел мактый:

– Минем кызым сакау түгел, – ди.

Сүзләр шундый күп икән! Яңалары көннән-көн өстәлеп кенә тора. Бик матурлары, әйтергә рәхәтләре, тәмлеләре бар.

– И-пи... И-пи.. И-пи-и-и-и...

Сәйдә бу сүзне бигрәк тә якын итә. Әйтүләре бигрәкләр дә рәхәт инде... «И-пи-и-и-и» дип, иренмичә сүз да тор. Кичен, өстәл янына утыргач, әбисе шүрлектәге ак төргәктән берәр телем ипи биреп тә куйса! Дөрес, ул ипи телеме шундый юка, ике читеннән ике кулың белән тотмасаң, авызга китергәнче сыгылып-сынып куюы да бар. Ипи бик сирәк эләккәнгә яратадыр инде бу сүзне Сәйдә. Ә менә әнисенең ипигә бер дә исе китми. Үзенә тиешле сыныкны да ашап бетерми әле ул, өч баласына бүлә дә бирә. Ул бәрәңгене якынрак күрә шул. Әбисе белән дә гел сөйләшәләр, Аллага шөкер, шушы бәрәңге кышны чыгарды, диләр...

Сәйдә инде кышны да белә, тик бәрәңге ул кышны каян чыгарды икән? Менә анысын әлегә аңлап җиткерми. Әнисе беләдер инде. Сорарга иде дә... Әнисен сирәк күрә шул ул. Сәйдә йокыдан торганчы ук, әллә нинди бер «калхуз» диган җиргә чыгып киткән була. Анысы тагын нәрсәдер – күргәне юк. Өстенә кияргә бишмәте булсамы? Әнисе артыннан шыпырт кына барып, теге «калхуз»ны әллә кайчан карап кайткан булыр иде.

...Ә урамда әле суык. Анда – кар. Ап-ак кар. Ишегалдында – сыер. Сәйдә инде анысын да белә. Әбисе аңа сыерчыкны да күрсәтте. Сыерчык кара икән. Тик Сәйдәгә дип алып килгән теле генә күренми. Кайчан бирер икән Сәйдәгә ул бүләген?

Абыйлары Зариф белән Закирга рәхәт, ичмасам. Бишмәтләре булгач, урамга чыгып, рәхәтләнеп уйныйлар. Закир абыйсы тәгәри генә карда, бүреге булмауга да исе китми аның. Әбисе үзенең башлыгын кигертә дә, өстеннән шәлен урый да куя.

– Колак туңмаска шәп була, – ди.

Ишегалдында шундый рәхәт икән! Абыйлары уйнаганда, Сәйдә тәрәзә төбеннән төшми дә. Их, бишмәте булса!

– Кар – йомшак, тәмле, – ди Зариф абыйсы.

Әбигә күрсәтми генә, Сәйдәне дә кар белән сыйлыйлар. Бик матур икән шул. Үзе – ак. Үзе – түгәрәк. Бәрәңге кебек. Үзе салкын тагын. Сәйдә яңа уенчыгын бик ошатты. Туйганчы уйнарга иде исәбе. Тик югалтты шул. Эзләп-эзләп тә карады, таба гына алмады. Ә Зариф белән Закир шаркылдый гына. Әллә алар яшереп куйды микән?

Беркөнне өйдә икәү генә утыралар иде, тәрәзәдән кемнедер күреп, әбисе «ах!» итте. «Сине ялгыз калдырып булмас», – дип, Сәйдәне ашыга-кабалана шакмаклы зур шәленә төрде дә, култык астына гына кыстырып, урамга чыгып та йөгерде. Бөтен битен каплаган шәлне аралап, тирә-юньгә туйганчы күз салырга да өлгермәде Сәйдә, күрше Маясмаларның түр сәкеләренә бастырып та куйдылар үзен. Ә Маясма әби, таяклы бер абыйны кочаклап алган да, елый да елый. Аңа Сәйдәнең әбисе дә кушылды. Елыйлар икәүләшеп.

Алар елаша торды, ә Сәйдә бик ныгытып теге абыйны күзәтте. Әллә нинди сәер абый икән бу. Аягы никтер берәү генә аның. Икенче аягын әллә бозау чәйнәде микән? Сәйдәнең әбисе чүпрәктән бер курчак тегеп биргән иде. Үзләре күрмәгәндә, юньсез бозау курчагының аягын чәйнәп өзгән. Йөри хәзер аяксыз булып.

Кара, кара, бу абый «кәртечкә»дәге әтигә охшаган түгелме соң? Башындагы бүреге, озын бишмәте дә нәкъ шуныкы кебек. «Әтиең кайда?» – дип сорасалар, гел шул «кәртечкә»дәге абыйны күрсәтә Сәйдә. Закир белән Зариф: «Безнең әти нимесләрне кыйный!» – дип мактанышa. Мөгаен, шул үзедер. Бу абый – минем әтидер!

– Әти-и-и-и!

Барысы да аңа борылып карады.

– Ул синең әтиең түгел! Минем әти!

Почмак якта тагын берәү барлыгын Сәйдә шунда гына күреп алды. Буйга Сәйдәдән бераз калкурак, күлмәге дә аныкыннан матуррак кызның йөгереп килүе булды, Сәйдәне төртеп тә екты.

– Ул бит минем әти!

– Чү-чү, Нәсимә кызым, нишләвең бу?

Теге абый Сәйдәне торгызды, үз янәшәсенә сәкегә утыртты.

– Кайтыр, Алла боерса, кайтыр. Менә сугыш кына бетсен, синең әтиең дә кайтыр.

Капчыгын актарып, нәрсәдер эзләде. Тапты, ахрысы, Сәйдәгә сузды. Әллә кар инде? Үзе ак.

Сәйдәнең үзен мактатасы, күп белүен күрсәтәсе килеп китте:

– Бу – кар! Кар ак! – диде ул.

– Бу – шикәр, балам. Аша, тәмле ул.

Каты, ак әйберне авызына капты Сәйдә, тешләре белән кетердәтте. Бөтен авыз эче тәмле рәхәтлек белән тулды. Сәйдә бәрәңгене дә, ипине дә белә. Сыер бозаулагач, сөтне дә туйганчы эчеп карады.

– Ши-кәр... Ши-кәр...

Карале, «шикәр» – бигрәк матур сүз икән бит! Бик матур һәм тәмле сүз!

Ике кызый, Нәсимә белән Сәйдә, чырык-чырык килеп, шикәр кетердәтте. Абый гына, никтер, көлмәде, башын чайкап, уфтанып куйды. Әллә елый да инде? Мөгаен, аның бозау чәйнәгән аягы авыртадыр.

...Сәйдәнең әтисеннән тагын хат килде. «Язлар җиткәч, кайтырмын, дип язган», – ди әнисе.

Ул язлар кайчан җитә икән? Тизрәк кайтсын иде инде. Беркөнне әбисе әйтә: «Яз да килде», – ди. Сәйдә дә үрелеп-үрелеп тәрәзәдән карады. Шул килгән язны күрәсе килде аның. Ә тышта беркем дә юк иде. Анда – кап-кара. Шикәр кебек ак кар да әллә кая киткән. Тагын теге шикәр искә төште. Бигрәк тәмле иде шул. Нәни генә булса да, барысына да җиткән иде: Закирга да, Зарифка да, әнисе белән әбисенә дә.

Закир «кәртечкә»гә бармагы белән төртә дә:

– Әти кайткач, миңа үзенең бүреген бирә, – дип мактана.

– Ә миңа – каешын! – дип аны да уздырып кычкыра Зариф.

– Миңа шикәр апкайта, – ди Сәйдә. – Ак шикәр... Кар кебек...

...Закир абыйсының бүрек юклыгына әллә ни исе дә китми хәзер – яланбаш кына җилдертә.

– Урамда – җылы! – ди ул.

– Яшел чирәм чыккач, тыштан да кермәссең инде, рәхәтләнерсең уйнап, – ди әбисе тәрәзә төбендә утырган Сәйдәгә. – Сыерчыклар да бала чыгара башлаган әнә.

– Сыерчык, сыерчык! Миңа апкилгән телең кайда? Бир инде!

Сәйдә аларга тәрәзә кага.

Көннәр үтте. Сәйдәнең сүзләре арта барды. Ишегалды да хәзер – ямь-яшел чирәм. Ялантәпи йөгерсәң дә, берәү дә сүз әйтми, әби дә ачуланмый. Рәхәтләнеп уйна гына! Ишегалды дөньясы тагын да кызыграк икән. Монда тавыклар чүпләнә. Бер, ике, өч, дүрт, биш! Биш тавык һәм бер әтәч! Сәйдә инде санарга да өйрәнеп килә. Аларның ике кызыл, өч ак тавыклары бар. Әбисе шулай ди. Сәйдә тагын саный башлый:

– Бер, ике, өч, дүрт тавык!

Яннарында әтәчләре кукраеп йөри. Ә бер тавык кайда соң?

– Кыт-кыт-кыт-кытак! Кыт-кыт-кыт-кытак!

Тәки эзләп тапты Сәйдә качкын тавыкны. Лапас почмагындагы үрелгән ояда утыра икән бит. Тавык оядан чыгып китүгә, Сәйдә шунда үрелде. Караса – шаккатты! Никадәр тәти! Шундый матурлар! Үзләре ап-ак! Үзләре түгәрәк! Аның мондый тәтиләрне әле беренче генә күрүе иде! Күр әле әбисен, Сәйдәгә уйнарга да бирмәгән шуны.

Бер тәтине күлмәк кесәсенә шудырды, башкаларын итәгенә җыйды. Рәхәтләнеп уйнасын әле бер! Тик тәтиләр әллә нишләп ямьсезләнәләр, Сәйдәнең кулын юешләп пычратып бетерәләр. Ул учларын бер-берсенә ышкый, теге ябышкак юештән арынмакчы була...

– Сәйдә, чукынмыш, нишләвең ул? Ничә күкәйне харап иткәнсең бит, җүнсез! Күкәй налугыннан котылам дип торганда гына...

«Күкәй налугы?» Тагын бер яңа сүз!

Бераздан Сәйдәне чолангa алып керде ул. Исән калган өч күкәйне кәрзин төбенә салды. Шундый матурлар! Рәхәтләнеп уйна гына. Тик ярамый шул. Ул күкәйләрне сугыштагы әтиләргә җибәрәләр икән. Көчле булсыннар, нимесләрне җиңсеннәр, тизрәк өйгә кайтсыннар, дип.

Яңа сүзләрне күп ишетте ул көнне Сәйдә. Ул тәтиләрне тавыклар ясый икән бит! Менә кызык!

– «Күкәй!» «Тавык күкәе!»

Ипи, бәрәңгене пешергән кебек, күкәйне дә пешерәләр, ашыйлар икән лә! «Күкәй ашаган кешегә күкәй кадәр көч керә», – диде әбисе.

– Әби, күкәй тәмле буламы?

Әбисе никтер дәшмәде, Сәйдәнең битен-кулын юды, дәшми-тынмый гына өстенә чиста күлмәк кидерде.

Ә Сәйдәнең беләсе килә бит.

– Әби, күкәй шикәрме ул?

Әбисе һаман дәшми. Соңрак ул кемнәрнедер ачулана башлады.

– Нәләт суксын шул сугышны! Нимес дигән мәлгуньне җир йотсын!

– Әби, күкәй бик тәмлеме? Шикәр кебекме?

Әбисе кәрзиндәге күкәйләрне алды, үзе авыз эченнән нидер сөйләнде:

– Күкәй налугы дип инде... Бетмәс сугыш булмас ла... Күкәй налугы, имеш...

Шактый кыштырдады карчык, самавыр капкачын бер ачты да бер япты, чыра телеп, ут кабызды. Инде самавыры кайнап, чәй эчәбез, ахрысы, дип торганда, өстәлгә өч күкәй куйды:

– Ашагыз, балалар!

Үзе, кабаланып, намазына утырды. «Йә Ходам, ярлыка мине!» – дигән сүзләре ишетелеп-ишетелеп китте.

Закир белән Зариф мондый затлы ризыкның тәмен онытмаган икән, куанышып чыр-быр килделәр.

– Минеке – зуррак!

– Юк! Минеке! – дип бәхәсләшеп тә алдылар, аннан, күкәй тотып, урамга чаптылар.

Сәйдә күкәйне тешләп тә, ялап та карады, ашый белмичә шактый изаланды әле. «Катылыкка шикәр кебек икән дә, тик, нишләптер, тешләп булмый үзен». Шунда гына аны әбисе күреп алды.

– И-и-и юньсезләр, сеңелләренә күкәй әрчеп тә бирмәгәннәр... – дип сөйләнә-сөйләнә, медер-медер догаларын укып, күкәйне чистартты да нәни кызның кулына тоттырды. Күзләре, никтер, яшьле иде аның.

Моңарчы татып карамаган, үзгә бер тәм Сәйдәнең авызын рәхәтләндерде. Ипигә дә, бәрәңгегә дә охшамаган иде бу тәм. Шикәр дә түгел! Әнисенең имие кебек тәмле икән ул күкәй. Сәйдәне тагын шунысы шаккаттырды: ак күкәй эчендә сары түгәрәк тә бар икән бит! Анысы тагын да тәмлерәк!

Күкәй сарысын учына кысып, Сәйдә урамга йөгерде.

«Күрсен әле Нәсимә дә. Күрсен дә шаккатсын әле! Икәү бергә ашасыннар әле күкәй сарысын! Нәни булса да, икесенә дә җитәр әле!»

Тик Нәсимәне сыйларга өлгермәде ул. Капканы ачуга, аңа ике апа белән бер абый очрады. Әллә



Рәсем: Наталья Васильева

кунаклар киләме? Шундый зур, симез абзыйга килеп тә бәрелде Сәйдә.

– Ай-яй, кызу йөгерә икән бу кыз!

Абзый Сәйдәнең битенә текәлеп карады.

– Нинди тәмле әйбер ашадың? Бөтен авызың – сап-сары.

Сәйдәнең бүгенге яңалыкны бу абыйга да әйтеп мактанасы килеп китте.

– Мин күкәй ашадым. Зариф абый да, Закир да ашады. Шундый тәмле!

– И-и-и, боларның күкәйләре күп икән, – дип кеткелдәде абзый.

Сәйдәнең мактанасы килү теләге артты гына:

– Күкәй бездә – бер сандык! Мин кү-ү-ү-п итеп ашадым. Бер, ике, өч, дүрт, биш күкәй!

Сәйдә тагын да күбрәк итеп әйтер иде дә, тик бишкә кадәр генә саный белә шул.

Алар өйгә керделәр. Кунакларны күргәч, әбисе нигәдер каушады.

Абзыйның тавышы да инде үзгәргән: усал, кырыс яңгырый. Дәфтәрен ачып, ниндидер язуларын актарды:

– Налукларыңны ник түләмисең? – дип әбисенә кычкыра башлады.

Әбисе каушады, бөтенләй кечерәеп, бөрешеп калды:

– Түлибез, түлибез, Алла боерса. Менә сыерыбыз яңа бозаулады, исән-имин үссен генә бозавы... Түләрбез, түләми ни... Менә тавыкларыбыз бишәү генә шул. Күкәй налугы...

Әбисе тагын нидер әйтмәкче иде, тик абзый кеше тагын да ныграк кычкырды:

– Намаз карчыгы башы белән ялганлап торуын күр әле! Налук түләми, күкәй ашап ятасыз, оятсызлар! – дип тагын әллә ниләр әйтеп бетерде.

...Кунаклар киткәч, әбисе бик озак сүзсез торды. Аннары яшьләрен сөртеп, Сәйдәне кочаклап алды:

– Сугыш кына тизрәк бетсен иде... Күкәй ашаган кешегә күкәй кадәр көч керә, ди. Мин сиңа күп итеп күкәй пешереп бирермен, Алла боерса...

...Сугыш бетәргә дә әллә ни күп калмаган икән. Бу шатлыклы хәбәрне дә әбисенә Сәйдә җиткерде. Кое янындагы хатыннардан ишетүе булды, бар көченә өйгә элдертте.

– Әби! Әби-и-и-и! – дип кычкырды ул өйне яңгыратып.

– Әү, балам! Ни булды?

Сәйдә, көчкә тын алып, ярып салды:

– Сугыш беткән, әби! Тизрәк күкәй пешер!

...Язлар килә торды, китә дә торды... Сыерчыклар да әллә ничә рәт килеп, әллә ничә тапкыр бала чыгардылар. Тик әтисе генә, никтер, кайтмады аның. Күкәй ашарга да тиз генә насыйп булмады әле...

...Сәйдә үсте, матур кыз булды, аннан әни дә булды. Хәзер инде ул – үзе әби. Әллә нигә оныкларын күкәй белән сыйларга ярата:

– Күкәй ашаган кешегә күкәй кадәр көч керә, ди. Ашагыз, балалар, ашагыз!

...Ә малайлар бер-берсенә карап елмаеша. Аларның инде – үз сыерчыклары.

Урамда инде бүтән язлар...


Казанның Ботаника бакчасы илебездәге иң борынгы бакчаларның берсе булып санала. Аның кызыклы тарихы бар.
Ботаника бакчасына нигез 1806 елда Казан университеты ишегалдында салына. Бакчаның беренче директоры профессор Карл Федорович Фукс анда экзотик үсемлекләр үстерү өчен теплица булдыруга ирешә. Вакыт узу белән бакча зурая, аңа бу кечкенә мәйдан җитми башлый. 1827 елда университетның ректоры итеп Н. И. Лобачевский билгеләнә һәм ул монда зур төзелеш башлап җибәрә.






Ботаника бакчасы урынына обсерватория төзү планлаштырыла, ә бакча өчен Кабан күле янында шактый зур җир участогы алына. Биредә тропик һәм субтропик үсемлекләр үстерү өчен зур оранжерея төзелә. Әкренләп бакча Россиядә иң зур бакчаларның берсенә әверелә. Узган гасырның ахырында биредә яшь бакчачы П. Н. Крылов эшләгән. Күпләргә ул атаклы ботаник-флорист буларак билгеле. Крылов бакчаның коллекциясен туплауга зур көч куя. 1885 елда Томскига киткәндә, ул үзе белән 700 данә кыйммәтле оранжерея үсемлеген дә алып китә, алар үз чиратында хәзер илдәге иң зур бакчаларның берсе булган Себер ботаника бакчасына нигез сала.
Гражданнар сугышы елларында бакчага шактый зур зыян килә. Ул дәресләр үткәрү урыны буларак файдаланылмый башлый, университет белән дә элемтә өзелә. Андагы агачларны – 100 гә якын субтропик үсемлекне – бакча өендә яшәгән бер бакчачы, зур авырлыклар белән коткарып кала.







БОТАНИКА БАКЧАСЫ



Гражданнар сугышыннан соң, университетта С. И. Петяев җитәкчелегендә юннатлар түгәрәге эшли башлый. Энтузиаст студентлар бакчаны тернәкләндерү бурычын куя һәм 1926 елның җәендә бакча яңадан үзенең капкасын ача. Бу датаны бакчаның яңа туган көне дип тә атарга мөмкин. Шул ук вакытта түгәрәкчеләр туган якны өйрәнү музеенда хәзерге зоопаркның нигезен тәшкил иткән җанлы почмак булдыралар. Җәнлекләргә урын җитми башлагач, яшь зоопарк ботаника бакчасы территориясенә урнаштырыла. Шулай итеп, 1931 елда яңа учреждение – Казан зооботаника бакчасы булдырыла. Бөек Ватан сугышы елларында бакча тагын зур сынаулар кичерә. Әмма юкка чыкмый, халык тырышлыгы белән сакланып кала. Сугыштан соңгы елларда бакчаның оранжереясе яңартыла, аны төрле җирләрдән кайтартылган экзотик үсемлекләр белән тулыландыра башлыйлар. Хәзерге вакытта Казан ботаника бакчасы үсешен дәвам итә. 1911 елгы күрсәткечләр буенча, оранжереядә меңнән артык экзотик үсемлек булуы билгеле.



Казандагы яңа зоопаркның проекты.

Бүгенге көндә оранжереядә 5941 экзотик үсемлек саклана. Аларның 500 ләп төре ябык җирдә, ә 200 дән артыгы ачык бакчада күрсәтелә. Агачларның 20 төре Кызыл китапка кертелгән. Узган гасырда утыртылган экзотик үсемлекләрнең беркадәресе бүгенге көннәргә кадәр сакланган. Ботаника бакчасына килүчеләр маниок, бругмансия, мирсина, эписция, шинус, маньчжурия чикләвеге, себер эрбете, амур сирене, магнолия, лимон, анар, инжир, кипарис, самшит, кофе агачы, драцена, абага, кактус, гасыр ярымнан артык яшәгән пальмаларның трахикарпус төрен һәм башка күптөрле үсемлекләрне очрата, алар белән таныша, хозурлана ала.
Бакча хезмәткәрләре хәзер биредә экскурсияләр уздыра, сирәк үсемлекләрне үстерү буенча консультацияләр бирә, балалар өчен кызыклы, файдалы чаралар оештыра.

Материаллар И. А. Черновның «Ботанический сад Казанского университета от Фукса до наших дней 1806–2006 гг.», Р. Я. Гыйльметдиновның, А. В. Малевның «Казанский зооботсад история создания ботанического сада» хезмәтләреннән һәм Казан зооботаника бакчасының рәсми сайтыннан алынды.

Сәхифәне ТР Милли музееның матбугат үзәге хезмәткәре Ленар НӘГЫЙМОВ алып бара.
Фотолар: ТР Милли музей фондыннан.



Бураннар

Сиңа кайтыр юлларымда җәяүле буран,
Юлларымны йөгерә-йөгерә
чистартып куйган.
Колач җәеп каршы алды
нәкъ синең сыман –
Сиңа кайтыр юлларымда җәяүле буран...

Синнән китәр юлларымда өермә буран,
Юлларыма өем-өем көрт сарып куйган.
Җибәрмәде, кире борды
нәкъ синең сыман –
Синнән китәр юлларымда өермә буран...

Нигә икән юлларымда шул ике буран
Чиратлаша һаман-һаман
язмышлар сыман:
Сиңа кайтыр юлларымда җәяүле буран,
Синнән китәр юлларымда өермә буран...

Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА,
шагыйрә;
Татарстанның
атказанган
сәнгать
эшлеклесе

ҖАНЫМНЫҢ БУРАННАРЫ

Дөресен әйткәндә, шигырьләремә иҗат ителгән җырларның санын үзем дә төгәл генә белмим. Хәер, мөһим дип санасам, төгәл саны барланган булыр иде. Юк, мөһиме ул түгел. Минем өчен иң мөһиме, һәр җырның булмаса да (күп очракта кемдер шигыремә җыр язганын белми дә калам!), һәр шигыремнең диярлек язылу, дөньяга туу тарихы бар. Һәм әйтергә кирәк, кайберләре бигрәк тә гыйбрәтле. Андый чакта мин: «Кеше берни дә белмәгән килеш тыңлый бит инде бу җырны...» – дип, ачынып уйлап куям. Моннан унбиш еллар элек Татарстан радиосында «Остаханә» тапшыруын ачып җибәрүем дә тыңлаучыга җырның шигыре, көе ничегрәк язылуын, җырчы нинди гамьнәр белән башкаруын ачыклап бирү җәһәтеннән иде бит. Ялгышмаган булып чыктым, тыңлаучыларыбызның иң яраткан тапшыруларыннан иде ул «Остаханә»!

Ярар, хуш! Инде минем, ягъни Шәмсия Җиһангированың шигырьләренә язылган җырларга якынрак килик. Беренче җыр моннан кырык ел элек мәшһүр композиторыбыз Фасил Әхмәт иҗат иткән «Нишлим», бераз соңрак композитор Илфат Дәүләтшинның талантлы җаныннан саркып чыгып, дөньяга аваз салган, җырчы Габделфәт Сафин башкаруында бөтен халык күңелен яулаган «Ак күлмәгем»... Бик күп җырларның кызыклы гына тарихлары бар. Бүген мин үзем өчен бик тә кадерле вә кыйммәтле, сезнең өчен дә шулайдыр дип ышанган берсенә – «Бураннар» җырына тукталырга булдым. Моның өчен 1991 елга, аннары 1992 елның гыйнвар аена кайтып килергә кирәк. 1991 елдан башлыйк. Язмышымның асты-өскә килгән чаклар бу. Ирем Назыйм инде өч ел яман чир белән авырый. Үзе бу турыда белмәгәч, мин дә күзенә карап, «Синдә яман чир юк, яшәячәксең!» – дип көн-төн тәкрарлап торгач, ул тән сызлаулары белән генә көрәшә. Ә мин... Минем җаным гына түгел, бөтен вөҗүдем әрни һәм төшенкелеккә бирелергә генә тора. Шулай да ике балаң, ирең бөтен өметен сиңа баглап торганда, тешеңне кысып яшәргә тырышырга, көрәшергә... көрәшергә генә кала.

Көннәрдән бер көнне киттем Арчага. Газ плитәсе алырга. Әйбернең кибеттә юк чагы. Казанның 10 нчы интернат-мәктәбендә бергә гыйлем җыйган сабакташымның сәүдә базасында эшләгәнен белә идем, шул хәбәр итте. Пешеренергә бик яратам шул. Ә плитәм юньләп эшләми, бәләкәйлегә дә җәфа. Авылдаш апам машина табып бирде...

Без юлда. Ә юлда! – җәяүле буран. Ул гүя минем менә-менә ялгыз калачагымны белә, шуңа тырышып-

тырышып барыр юлымны ачып-әрчеп куярга ашыга! Ә минем җанымда өермә буран котырына. «Каласың! Каласың! Каласың!..» Шул «каласың»ны җиңәргә тырышып-тырмы, көтмәгәндә күңелемдә шигъри юллар бөтерелә башлый: «Сиңа кайтыр юлларымда җәяүле буран...» Ул да булмый, шофер сүзката, русчалап Арчага кая, ни өчен баруымны сорый. Белгәч, ул плитәне кем белән күтәреп машинага салачагым турында кызыксына. Ул күтәрешмәсә, үзем генә икәнлеге аныклангач, шактый дорфа тавыш белән: «Нигә сез ир кеше эшенә алындыгыз?» – ди. Соң чиккә җиткән түземемне җуеп: «Әгәр ул булмаса!» – дип, ачыргаланып елап җибәрәм. Җанымда бөреләнә башлаган илаһи шигырем кырыс чынбарлыкка бәрелеп, челпәрәмә килә...

Еллар буе хыялланган зур таба сыя торган плитә кухня түренә менеп кунаклагач, телләреңне йотарлык өчпочмак, пәрәмәч, бәлеш... турында хыялланып, хәләл ит юнәтүне кайгырта башлыйм. Дөресрәге, аны Мөслим районының Баек авылында яшәүче әнием кайгыртып куйган инде. Алып киләсе генә бар.

...Мин тагын юлда. Бер машинадан икенчесенә күчә-күчә, кире як дип саналган Баегыма кичләтеп кайтып төшәм. Мунча кереп, тәмле бәлеш ашап, сап-сары итеп юылган, агач исе, туган йорт исе аңкып торган идәнгә йомшак мендәр салып, алда үземә усал язмыш әзерләп куйган киртәләрне ни хәлләр итеп үтәремне бер мизгелгә генә онытып, изрәп йоклап китәм. Мине әнкәемнең назлы тавышы уята: «Караватка күчеп ят, бәбекәем...» Күчеп ятам ятуын, ләкин... кая ул йоклау! Тышта өермә буран котырына. Әллә нинди усал тавышлар белән сызгырынып, өй түбәсен куптармакчы була. Өй түбәсен генәме соң?! Менәменә бар усаллыгын җыеп, котырынып килер дә әнкәемнең җыйнак ак өен урыныннан кубарып, ак кораб шикелле бөтереп, җиһан киңлегенә очыртып алып китәр шикелле. Сабый беркатлылыгы белән куркынып, тәрәзгә багам. Ә аннан өермә буран миңа бармак яный: «Каласың! Каласың! Каласың!..» Аңа үч иткәндәй, җанымны ярып, шигырь саркып чыга:

Синнән китәр юлларымда өермә буран, / Юлларыма өем-өем көрт сарып куйган. / Җибәрмәде, кире борды нәкъ синең сыман – / Синнән китәр юлларымда өермә буран...

Чү! Тукта! Бер атна элек Арча юлында җанымда бөреләнә башлаган шигырь ничек иде әле?! Әйе! Әйе!

Сиңа кайтыр юлларымда җәяүле буран, / Юлларымны йөгерә-йөгерә чистартып куйган. / Колач җәеп каршы алды нәкъ синең сыман – / Сиңа кайтыр юлларымда җәяүле буран...

Бу – шигыремнең башы булган лабаса! Икенче куплет яңа туды. Әнә, өченчесе дә күңелемнән саркып чыгып килә:

Нигә икән юлларымда шул ике буран / Чиратлаша һаман-һаман язмышлар сыман: / Сиңа кайтыр юлларымда җәяүле буран, / Синнән китәр юлларымда өермә буран...

Турап ике капчыкка салып куелган итне мең бәлаләр белән ничегрәк Казан каласына алып кайтып җиткерүемне сөйләп тормыйм. Ул хәлләрнең чын шигърияткә катнашы бөтенләй юк. Шулай да үземә төрле очрашулар вакытында бик еш биреләә торган сорауга ачыклык кертеп үтәсем килә. «Ничек сез бөтен шигырьләрегезне дә диярлек яттан беләсез?!» дигән сорау ул. Аларны махсус ятлаганым юк. Әле генә сезгә бәян иткән очрактан чыгып та сорауга дөрес җавапны белеп була түгелме?! Шундый халәттә җаныңны ертып дөньяга бәреп чыккан шигырең ничек хәтереңнән җуелырга тиеш соң?! Юк, җуелмый, мәңгелеккә уелып кала ул!

Сүз башымда 1992 елның гыйнварын телгә алган идем. Инде шуңа якынрак килик. Гыйнвар аенда Казан циркында республикабызның үзешчән композиторлары иҗат иткән җырлардан төзелгән концерт булды. Дөресрәге, бәйге иде бугай ул. Чөнки без – жюри рәисе Илһам Шакиров, әгъзалары – Әлфия Афзалова, Мәсгут Имашев, Рамил Курамшин һәм мин – урыннар билгеләп утырганыбызны хәтерлим. Кайбер төгәлсезлекләр китә калса, гафу үтенәм. Төп сүзем бәйгенең нечкәлекләрен тәгаенләү түгел чөнки. Шул кичәдән соң районнардан килгән берничә үзешчән композитор, җыр язар өчен дип, шигырьләремне сорап алдылар. Күрәм, кыюсыз гына бер читтәрәк басып торучы ир-егет миңа карап елмайды да: «Мин Әлмәттән Рәис Нәгыймов *(фотода без бергә)* дигән кеше булам, миңа да берәр шигырегез юкмы?» – ди. Исемennән үк Гамил Афзал шигыренә «Авыл» дигән гаҗәеп җыр иҗат иткән композитор икәнен чамалап, мин дә уңайсызланып кына: «Өләшеп бетердем шул... Күңелдә бер шигырем бар да, тик ул җыр яза торган шигырь түгел бугай...» – дим. «Бирегез сез миңа шул шигырегезне... Миңа җыр язып булмый торган булса да ярый...» Як-ягыма карангалап торуымнан кәгазь-каләмем юклыгын чамалаптыр, күрәмсең, ул тиз генә кесәсеннән кәгазь кисәге һәм ручка алып миңа сузды...

Берничә көннән радиодагы эш бүлмәмдә телефон шалтырады. Әлмәттән. Рәис абый шалтырата. «Бураннар» дигән җыр әзер икән. Үзе баянда уйнап, шыңшып-җырлап та күрсәтте. Һәм, җыр миңа ошаган очракта, Мирсәет Сөнгатуллин башкаруга карата фикеремне сорады. Мин ризалаштым. Күп тә үтми, Мирсәет Сөнгатуллин җырны радиода яздырды да. Төрле сәбәпләр табып, радио фондына ул җырны алдырмаска тырышулар турында язып тормыйм. Җыр, тиз арада дөньяга бәреп чыгып, популяр булып китеп, ул «тырышулар»ның хаксыз икәнен раслады инде. «Бураннар» Фердинанд Сәлахов, «Сәйлән» төркеме башкаруында да матур яңгыраш тапты. Миңа берзаман Троицк шәһәреннән әлеге җырның Фәрит Якупов башкарган язмасын да алып кайтып тыңлаттылар. Берничә ел элек «Бураннар» «Фәридә-Алсу» дуэты башкаруында яңа яшәеш тапты! Моның чын сихри көчен тоемлаучы халкыбыз күңелендә «Бураннар»ның мәңге яшәячәгенә бик тә ышанам!



Кешене яхшырак аңлыйм дисәң, ул узган юлдан үтеп кара, диләр. Әйтәсе сүзеңне аннары әйт. Тик минем бәяныма ак кәгазь битенә язып булырдайлары гына керде: кәгазь битләре ул кичергәннәрнең барысын да күтәрә алмый. Тормыш катлаулырак...



Гөлнур САФИУЛЛИНА

ДИҢГЕЗ КИЧКӘН БӘХЕТ...







– Мин бит ул чакта шулай тиеш дип белдем... Бездән алда укыган чуаш группасында да өйләнешүчеләр булган. Аларның да балалары туган. Алар да аны «Дом ребенка»га биргәннәр. Укытучылар шулай диделәр...

Бала тудыру йортыннан ук Ләйсәнен «Балалар йорты»на озатып калган Әнисә шул көнне үк училищега, дәресләргә йөгерә. Читтән караучыларга унтугыз яшьлек яшь әнинең тормышы әллә ни үзгәрмәгән кебек тоелгандыр: иртән ул дәресләрдә, кичен репетицияләрдә. Ачы таңнан әллә кайдагы «Балалар йорты»на кызын имезергә йөгергәнен, репетицияләр арасында аулак почмак табып, әрнешеп тулган күкрәкләрен саварга утырганын, тамчысына кадәр кадерле булган ул сөтле шешәне кысып тотып, кичләрен кабат бәләкәче янына ашыкканын азлар белгәндер. Ә күңелдәгесен... «Яшьлегем белән күп нәрсәне аңлап бетермәгәнмен», – дисә дә, өзгәләнүләр әлбәттә, булган.

– Оныгын күрергә дип авылдан кайнанам килде. Ә балалар йортын карантинга яптылар! Ике айга! Грипп вакыты иде. Тәрәзә янына барып бастык та ул елый, мин елыйм...

Әнисә бикле ишекләр артындагы кечкенә кызчыгын сагынып елагандыр, ә авылдан ук җыенып килгән кайнанасының күз яшьләре аларның икесе өчен дә коелгандыр: яшь-яшь килеш шундый сынаулар кичәргә мәҗбүр булган килене дә, шулкадәр юл узып килеп, кулына алып сөя дә алмаган оныгы да жәл тоелгандыр аңа... «Ярдәм итә алмыйм», – дип тә үртәлгәндер.

...Актаныш районының Пучы авылы кызы ул Әнисә. (Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының элеккеге артисткасы Әнисә Сабирова (Әнисә Сабир) турында сөйләвемне кемнәрдер, бәлки, инде аңлап та өлгергәндер.) Гап-гади гаиләдә үскән. Әти-әниләренә белгертмичә генә кечкенәдән үк «артист булам» дип хыялланган. Кызларының Казанга укырга дип әлеге хыял артыннан киткәнен өйдәгеләр аңламый да кала. Әнисә үзе исә, ул елны җыелган төркемне Мәскәүгә, Щепкин исемендәге Югары театр училищесына укырга җибәрәчәкләрен белмичә, юлга кузгала. Актаныштан Казанга самолет очкан вакытлар әле: күрше утыргычтагы кыз да театр училищесына бара булып чыга – икәү фатирга урнашалар, икәү имтиханга китәләр. Аңа кадәр әле Марсель Сәлимҗанов һәм театрның унлап артистыннан торган комиссиягә үзләренең нәрсәгә сәләтле икәнлекләрен күрсәтәләр.

Группада алар унсигезәү булалар.

Булачак ире аңа беренче көннән үк күз сала. Әнисәдән сигез яшькә олы егет кызны башкалардан карчыга кебек саклый: берәүне дә якын китерми. Өченче курста укыганда алар өйләнешәләр. Аннан Ләйсән туа.

– Дәресләр иртәнге тугыздан кичке тугызга кадәр. Академик ял алу мөмкин түгел – ике елдан училищеда тагын татар студиясе булыр дигән өмет юк... Ләйсән «Дом ребенка»да сигез айга кадәр яшәде. Әмма хәзерге акылым булса, мин баламны анда һич бирмәс идем... Начар карамаганнардыр анысы. Әмма ана җылысы барыбер җитмәгәндер. Хәзер Айданны кулыма алып яраткан саен, Ләйсәннең кечкенә чагын уйлап, аны жәлләп, җаным елый...

Әмма сәхнә – бер, тормыш икенче шул...

Ниһаять, диплом кесәдә! Кызын кочагына кысып, ире белән Казанга кайтып төшкәндә Әнисә, мөгаен, шөкер, сынауларны кичтем, дигәндер. Сөенергә иртәрәк икәнен кайдан белсен соң ул?!

Юк, эшкә кая урнашыйк икән дип бәрелеп-сугылып йөрүләр булмый анысы. Икесен дә Камал театрына кабул итәләр. Беренче рольне режиссер Дамир Сиразиев ышанып тапшыра, икенчесен – Празат Исәнбәт. Марсель Сәлимҗанов рольләр бирә башлаганчы бер-ике ел уза әле. Халык исә ул арада Әнисәне «Язгы аҗаган» (Мәхмүт Хәсәнов) телеспектаклендәге Гөлүсә роле аша танырга, яратырга өлгерә. Аннары Фәрит Бикчәнтәев кайта һәм «Казан егетләре»н (Мансур Гыйләҗев) куя. Әнисә анда – Асия. «Хуҗа Насретдин»да (Н. Исәнбәт) – Сәлви, «Галиябану»да (М. Фәйзи) – Рабига, «Җимерелгән бәхет»тә (А. Островский) – Оля, «Идегәй»дә (Ю. Сафиуллин) – Ханәкә, «Ике хуҗаның хезмәт-









чесе»ндә (К. Гольдони) – Смеральдина... Әнисә Сабир турында: «Үсеп килүче көчле драматик, лирик пландагы яшь артистка», – дип сөйли башлыйлар.

Анда – сәхнә артында, тамашачылар күзенә чалынмаган башка дөнья да бар: бер артистның икенчесенә аяк чалулары, көндәш, конкурент санаулар, берсе икенчесен юкка чыгарырга тырышулар... Ирен – талантлы яшь артистны да юлларында киртә итеп күрүчеләр табыла. Ул арада йомшак ягын да сизеп алалар: төрле сәбәпләр табып, хәтта, төнге икеләрдә кунакка килеп керүләр ешая. Иртән әле айнырга өлгермәгән кешенең репетициягә бара алмавы билгеле бит инде... Аракы сөреме белән аңы томаланган ирнең бик еш хатынына кул күтәрүен исә ул «дуслар» белмәмешкә салыша... Нишләтәсең, эчтеме, икенче кеше була да куя. Тоташ мәхшәргә әйләнгән төннәр бер-берсенә кушыла. Әмма түзүнең, сабыр итүнең дә чиге була шул.

«Кызым, синең хакка! Синең киләчәгең хакына!..» – әни кеше иртән дә, кич тә шул сүзләрне кабатлый.

– Шундый төннәрнең берсендә үз уемнан үзем куркып сискәнеп киттем: «Йокласын да, аяк-кулларын бәйләп, башына берәр нәрсә белән сугам...» «Әнисә, нишлисең?! Синең кечкенә балаң бар!» – дидем үз-үземә...

Һәм ул өч яшьлек кызын җитәкләп өйдән чыгып китә. 29 декабрьнең салкын төне була ул...

Аннан театрда партбюро җыялар. Яшь гаиләгә биргән фатирда кемне калдыру мәсьәләсен хәл итәләр. Ир хатынны гаепли: «Аңа ирек кирәк! Миннән китеп иректә булмакчы ул!» – ди. Ә хатын, үзен яклыйсы урынга, елый да елый гына... Соңгы сүзне күренекле артистка әйтә: «Алай ирек дип бик хыяллангач, Әнисә тулай торакка чыксын!»

Шулай итеп, фатирда ул кала (талантлы ир-егетләр гел хөрмәттә!). Тик театрда элеккеге ире инде тагын азга гына тоткарлана – безне капчыкта озак саклап булмый – озаталар... Кемнәрдер өчен юлдан киртә алына.

Ялгыз бала үстерүләре җиңел түгел. Артист халкына бигрәк тә. Соң кайтулар, гастрольләр... (Ләйсәннең җәйләре авылда уза, ә башка вакыт сеңлесе Фәнүсә, дус кызлары ярдәмгә килә.) Акча җитмәүләр...

2001 елны Камал театрын Финляндиягә икенче тапкыр гастрольгә чакыралар. Бу юлы Туфан Миңнуллинның «Җанкисәккәем» комедиясен алып баралар. Әнисә анда Нәсимә ролендә уйный. Артистларны фин татарлары, отельгә түгел, урман эчендәге дачаларына урнаштыралар. Соңгы кичне кунаклар өчен бәйрәм оештырыла. Аралашулар караңгы төшкәнче бара. Әнисә янына Зирәк килеп басканда учактан төшкән ут шәүләсе инде бөтен кешенең дә йөзен яктыртмый башлаган була. Сөйләшеп китәләр. (Зирәкнең нәсел тамырлары Ютазы якларыннан булып чыга. Әнисе Гәүһәр Туганайның шигырьләре «Казан утлары» журналында да басылып чыккан. Ачлык елларында, бер балабыз булса да исән калсын дип, әти-әнисе аны фин ягына китүче туганнарына ияртеп җибәрәләр.) Сүз арасында Зирәк аның яшен сорый. «Кырык», – ди Әнисә. Ә үзенең утыздан яңа узган чагы! Нигә шулай әйткәнен аңламый да кала. («Язмыш инде...» – бүген дә әле ул шулай гына дия ала.)

Иллесен тутырган ир башканы уйлаган икән (сорауны юкка гына бирмәгән!): Казанга ул һәр кичне шалтырата башлый. Гел уйнап-шаяртып сөйләшәләр. Шуңа күрә Яңа ел төнендә Зирәкнең: «Миңа кияүгә чыгасыңмы?» – диюенә дә, Әнисә: «Чыгам! Нигә чыкмаска?» – дип җавап бирә. («Шундый җитди әйберне телефоннан хәл итәр дип кем уйлаган?!») Икенче шалтыратуларында ир инде туй турында сүз кузгата, Әнисәне ярәшелгән кешесе итеп санап сөйләшә. Кызы белән икесен кунакка чакыра. Шул очрашуларында Әнисә аңа үзенең яшен әйтә. «Син минем өчен бик яшь икән бит!» – дип, Зирәк башта аптырап кала. Аннан, бик озак уйланганнан соң: «Әйдә, бергә торып карыйк. Поездлар бит һәр көнне йөри – ошатмасаң китәрсең», – ди.

«Торып карар» өчен никахны рәсмиләштерергә кирәк, язылышалар. Аннан ярты ел виза көтәләр. Ярты ел буе Әнисә кызын көйли. Ундүрт яшьлек Ләйсән аяк терәп каршы килә: «Китмик! Мин класста староста, мине бөтенесе хөрмәт итә, дусларым, укытучылар мине ярата...»

Ничек яшәп китәләрме? Җиңел түгел, әлбәттә. Әмма Әнисә дә, Зирәк тә бик тырышалар. Киләчәккә планнар коралар, уртак бала турында хыялланалар. Зирәк Ләйсән белән бик тиз уртак тел таба. («Фин ирләрендә андый проблема, гомумән, юк. Балага мөнәсәбәт башка анда. Ләйсәнне дә Зирәк үз баласы кебек карады. Әтисеннән андый хөрмәт күргәне булмады кызымның. Безнекеләр аерылышкач, баланы белми дә бит».)

Ләйсәнне фин мәктәбенә бирәләр. Ярты ел эмигрантлар классына йөргәннән соң, аларны бер сыйныфка артка күчереп утыртырга тиеш булалар, ә Ләйсән, телне яхшы өйрәнгәч, үз яшьтәшләреннән калышмый, елын югалтмый. Әкренләп дуслар да табыла. Әнисә башта тел өйрәнә – курслар тәмамлый, аннан укырга керә.

Ә Зирәк белән яшь аермалары унсигез ел...
Ул көннән-көн үзен күбрәк сиздерә. Кайчандыр ирнең үз бизнесы булган, тун кибете тоткан. Беренче хатыны – фин татары – белән аерылгач, Зирәк эшен югалта, өметсезлеккә бирелә. Хатыны белән сигез ел буе судлашалар – мал бүлләр алар. Ир инде дөньяны да, тормышны да күргән, яшәп арган... Бүген инде мәрхүм булган Зирәкне Әнисә бары әйбәт яктан гына искә ала. Әмма тормышлары барып чыкмый шул.

«Чемоданыңны җыярсың да, кире кайтып китәрсең», дип әйтергә генә җиңел. Ялгыз булса, әйе, китәр иде. Бала бар бит. Димәк, юлның башкасын сайлыйсы...

Финляндиягә килүенә дүрт ел булды дигәндә, Әнисә кызы белән урамда кала. Ике кулда – ике чемодан. («Зирәк белән безнең контракт бар иде: кем нәрсә белән килә, шуның белән китә».) Беренче төнне буш фатирда

идәнгә газета җәеп йоклыйлар. Кая ул зарлану, баш өстендә түбә табылганга сөенә-сөенә төн кичәләр. Россиядән килгәннәрне фатирга кертергә бирәү дә атлыгып тормый. Бер татарның фатирларны арендага бирүен белеп, Әнисә, аптырагач, аңа шалтырата. Беренче сорау: «Түли аласыңмы?» – була. «Түлим, ничек тә түлим!» Әмма милләттәшләр гел шулай киң күңеллелек күрсәтеп тормый шул. Аның каруы, каты бәгырьлелек адым саен очрый.

– Зирәктән җәй көне, каникул вакытында киттем. Акчасыз дисәм дә була. Мәхәллә каршындагы балалар бакчасында, моңарчы ике ел рәттән башкарган эшкә өметләнеп торган идем. Шул елны мине алмадылар. Ләйсәнне дә... Бер тиенгә тилмергәндә, андагы хезмәт хакы – 200 евро безнең өчен зур акча иде. Кызым белән санап чыгардык: бер көнгә 5 евробыз бар, аңа ипи дә чәй кил... Әрнедем инде... Ярты ел бик авыр яшәдек.

Укуымнан практика үтә идек, шунда хуҗа – фин кешесе: «Эшләргә теләмисезме?» – дип сорады. Сөенеп ризалаштым! Ләйсәннең лицейда бергә укый торган дус кызы опера театрында җыештыра иде. «Мин эшләп ардым, син теләмисеңме?» – дип, ул эш тәкъдим итте. Ләйсән көндез укый, кичләрен эшли башлады. Җан биргәнгә, Ходай җүн бирә ул...

Фин бизнес мәктәбен тәмамлап, эшкә урнаша Әнисә, фатир сатып ала. Бар нәрсәсен дә булдыра. Ул арада Ләйсән үсеп җитеп, татар егетенә кияүгә чыга. Алан туа – Әнисә кырык яшендә әби була. Үзе хакында онытып, кызы, оныгы өчен яши башлаганда, Ходай аңа Айданны бүләк итә. Хәер, башта Марккуны әле.

– Хыялларымның берсе – күп балалы бәхетле зур гаилә иде. Оныгым туганчы бу хакта хыялландым әле, Алан тугач кына тынычландым. «Кырыкта инде бала тапмам, янадан кияүгә чыкмам», – дип, үз хыялларымнан үзем үк баш тарттым. Оныгым дип уяндым, оныгым дип эштән соң өйгә чаптым... Йоклый алмый интегүләр онытылды. Бөтен нәрсәм бар, барыбыз да саусәламәт, бер җитешмәгән нәрсәм юк... Тормышымның шундый түгәрәк чагында Марккуны очраттым. Башта бик җитди карамадым аңа, вакытлы мавыгу дип үземне ышандырырга тырыштым. Әмма ул үзенең мәхәббәт ятьмәләрен тирә-юнемдә үрә торды. Балыкчы бит, диңгезче! Аучы! Дөнья күргән, чит илләрдә эшләгән, яшәгән, белмәгән нәрсәсе юк.

Танышуыбызга әле бик аз гына вакыт узган иде, Маркку мине 22 яшьлек улы белән бергәләп җилкәнле көймәдә Таллинга барырга чакырды. Нихәтле карышсам да, үзенекен итте, ризалаштырды. Матур юка киемнәремне киеп киттем. Диңгез кичкән кешемени мин?! Кузгалып киткәнче үк ул миңа күңел болгануга каршы дарулар эчерде, аптырадым... Хельсинки ярында безне иртән озатып калган кояш, тора-бара, болыт артына кереп китеп, җил-давыл кузгалды: көймәбез су өстендә йомычка кебек тирбәлә, җилкәннәре белән диңгезгә ятып ук бара! Тирә-якта биек дулкыннардан башка берни күренми... «Маркку биргән теге даруларны нигә күбрәк эчмәдем икән?» – дим. Белгәннәремне укып, Ходайдан гөнаһларым өчен әллә ничә кат гафу сорап өлгердем. Ә алар улы белән икәү рәхәтләнәләр генә җилкәннәрне тегендә-монда борып, исләре дә китми... Көне буе бардык, кояш баеганда еракта Таллин төсмерләнә башлады. Менә шунда – туңудан сизми башлаган аяк бармакларымны уа-уа йон оекбашлар кигергәндә гашыйк булдым инде мин аңа...

Мөмкинлек чыккан саен мине нәрсәгә дә булса өйрәтә ул. Маркку белән беренче тапкыр балык тоттым, сквош уйнадым, роликлы тимераякта шудым, су мотоциклы, моторлы көймә йөртергә, ишкәкләр белән гади көймәдә, канотта ишәргә, гольф уйнарга да ул өйрәтте. Диңгез төбенә чумып, икәү «мәрҗән» эзләдек... Әмма бөтен хикмәт Марккунын мондый һөнәрләр белән тормышны бизәвендә генә түгел, ә миңа ышануында, мине шәхес буларак үстерүендә, канатландыруында. Шуларны уйлаганда, Мәскәүдә укыган елларымны искә төшерәм. Никадәр мөмкинлекләрне кулдан ычкындырдым анда. Француз теле өйрәнергә, гитара буенча дәресләр алырга теләгәч, янымда шундый терәк булмады. «Нәрсәгә кирәк инде ул сиңа?» – дип көлде генә «ир».

Мигрантлар, гадәттә, җиде ел дигәндә эшкә урнаша, минем аның кадәр көтәргә мөмкинлегем юк иде.

Әтиемнен вафатына бер ел булганда Маркку белән Татарстанга бергә кайттык. Гадәт буенча театрга кердек. Шамил абыйның исән чагы иде әле. Безне шундый җылы итеп каршы алды, күңелле итеп сөйләшеп утырдык, артистлар белән күрештек. Тәнәфестә очраклы рәвештә генә миннән интервью да алдылар... Марккуга бу сәфәр бик ошады. Элеккеге тормышымны яхшырак күз алдына китерә башлады. «Син туган илеңне, дустуганнарыңны, яраткан эшеңне калдырып киткәнсең. Ничек тәвәккәлли алдың?» – дип гаҗәпләнде. «Аның каруы, мин сине таптым!» – дидем аңа. Нәрсәләр югалтканымны һәм ниләр тапканымны бары тик үзем генә беләм. Бәлки, әле кайберләрен белеп тә бетермимдер. Ул сөйләшү вакытында тагын бер-ике елдан бәби алып кайтасым уемда да юк иде бит...

Кырык дүрт яшендә кабат әни була Әнисә. Айдан әтисе белән – финча, әнисе белән татарча сөйләшә. Төркиядә, Ак диңгез буенда, улына татарча эндәшүен ишетеп борылдым мин алар ягына. Тавышын алдарак таныдым: Әнисә Сабирова! Шунда ук «Язгы аҗаган»дагы Гөлүсәсе күз алдына килеп басты. Хәтерлибез, сагынабыз икән... Язмышын беләсем килә иде, менә очраштык... Сөйләтү, күңеленә ачкыч ярату – анысы вакыт эше булды.

Ә сәхнә... Ул инде артта калган. Бер җырдагыча: «Араларда еллар – киртәләр...» Без аны кабат яңа рольләрдә күрмәбез. Әмма мин күргән соңгы роле – кечкенә Айданның чибәр әнисе булу аңа шундый килешә иде!

16+

ХИСЛӘР ИХЛАС БУЛГАНДА...

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.



Мансур ГЫЙЛӘҖЕВ, драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; өйләнгән; гаилә стажы — 26 ел. Бер кыз һәм ике малай атасы.

1 Иң элек син хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсең: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

Әлбәттә, беренче чиратта, тышкы кыяфәтенә игътибар итәм. Бу очракта мин үземнең табигый инстинктларыма, геннарыма күбрәк ышанам, алар алдамый: кайсы хатын-кызның миңа сау-сәламәт балалар тудырачагын, кем белән миңа рәхәт булачагын барыбер сиздерәләр. Минем бу теләк-таләпләремә туры килгән хатын-кыз сау-сәламәт булырга, тышкы кыяфәте белән үк үзенә тартып торырга тиеш: барысы да мөһим – зифа буй-сыны да, тән тиресе төсе дә, тешләренең аклыгы да... Аннан әтинең гел әйтә торган бер сүзе бар иде: «Улым, балаларың матур булсын дисәң, чибәр хатын сайла», – дия иде ул. Бу киңәшнең нигезендә мин гел кешелеклелек, зирәклек ята кебек тоя идем.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

Мин шактый таләпчән кеше, шуңадыр якыннарымда кимчелекләр бик аз булырга тиеш дип саныйм. Яраткан хатын-кызымның глобаль максатлары булмавын (балалар тәрбияләп үстерүдән тыш, билгеле), җиңелчә генә хәтерсезлеген кичерә алам...

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идең?

Хыянәтне гафу итмим! Берниндиен дә!

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: җыештыручылар һәм пешерүчеләргә. Сиңа аның кайсы якынрак?

Бу сорауны бик аңлап бетермәдем, шуңа күрә аңа җавабым юк. Минем хатыным җыештыручыларга да керә ала, пешерүчеләргә дә...

5 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

Хәләлем минем өчен дус кына түгел, бөтен башлангычларымда төп таянычым да ул. Дөрес әйтәләр, мәхәббәт ул бер-береңә карау түгел, ә икең бер якка карау.

6 Хатыныңа ничек тәкъдим ясаганыңны хәтерлисеңме?

Мондый вакыйганы ничек онытып булсын инде?! Тормышымда бер генә тапкыр булган хәлне! Ул миңа үзенең бер гаеп эше турында сөйләде һәм мин аңа шунда ук тәкъдим ясадым. Күңелен ачуы белән гашыйк итте дә куйды шулай.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр...

Нәкъ шулай! Боларның барысы да аңасты дәрәҗәсендә бара. Безгә бишек җыры көйләгән, башыбыздан сыйпаган, безне яраткан, күкрәк сөте имезгән, җырлар җырлаган хатын-кыз образы сабый чакта ук күңелебезгә, аңыбызга кереп урнаша. Ә ир-атка киләчәктә шушылар гына кирәк тә бит инде...

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар...

Шактый катлаулы очрак бу, бигрәк тә татар гаиләсе өчен. Чөнки гасырдан-гасырга безнең гаиләләрдә тәртип башкача булган. Әмма тормыш

хәзер бик нык үзгәрде, нигезләр какшады. Ир-атларга бик күп нәрсәләргә түзәргә, бик күп әйберләр белән килешергә туры килә. Әмма бүгенге татар гаиләләрендә барган үзгәрешләрнең иң куркынычы бу түгел әле...

9 Гашыйк булуын башлап хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсың?

Кыз бала яратуын беренче булып үзе әйтмәсә дә, егет аны, һичшиксез, сизәчәк. Әгәр дә аларның икесе арасында чын мәхәббәт кабынган булса... Һәм, гомумән, иң мөһиме – хисләрнең ихласлыгы, ә бер-беренә кем нәрсә әйтә, кем башлап әйтә, анысы алай ук зур роль уйнамыйдыр. Кайчакта бер сүз дәшмичә дә бик әйбәт аңлашабыз лабаса.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә?

Хатын-кызда инстинкт шулай ук бик көчле. Ул һәрвакыт ир-атларга булачак балаларының әтиләренә караган кебек карый. Шуңа күрә аның күзе төшкән ир-ат көчле, гайрәтле һәм калын кесәле, хәлле кеше булырга тиеш. Аңардан сау-сәламәт бала туарга, ул аны тәрбияли, тәэмин итә алырга тиеш. Мин бу темага төрле илләрдә уткәрелгән сораштыруларның нәтиҗәләрен бик күп укыдым. Һәркайда гүзәл затлар бертөрле җавап бирә: ир-ат, иң беренче чиратта, киң күңелле, акыллы, романтик, хуҗалыкчыл, намуслы... булырга тиеш, диләр. Барысы да сүз боткасы, хәйлә генә! Хатын-кыз иң беренче урынга көч, сәламәтлек һәм акчаны куя! Ышанygыз миңа!

11 Хатын-кызлардан үзең игътибар көтәсеңме?

Минем инде янәшәмдә парым бар һәм ул мине ярата. Мин соңгы көннәремә кадәр аның белән бергә гомер итәргә телим. Шунлыктан, башка хатын-кызлардан инде берни дә көтмим.

12 Ир-ат артык чибәр һәм көчле хатын-кыздан курка.

Йомшак, көчсез ир-атларга гына кагыладыр бу... Аннан, чибәр һәм көчле хатын-кызлар бик еш кына салкын була, дәртләндермиләр. Чын ир-атлар андыйларга тартылмый да.

13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзең аңламаган берәр очракны искә төшер әле.

Бервакыт дус егетләр белән мунчага бардык. Озак итеп, рәхәтләнеп утырдык без, чабындык, массажга кердек. Сыра эчтек, аның янына балыгыбыз да бар иде... Өйгә мин ул көнне шактый соң кайттым. Шулкадәр рәхәт иде миңа, язмыш үземне нәрсәгәдер бүләкләгән кебек тойдым хәтта. Ә хатыным миңа бик нык үпкәләде... Йә, нәрсә өчен инде?!

14 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар.

Аучы белән гаилә учагын саклаучы икесе бертөсле үк логикага ия була алмый инде. Әгәр бу шулай булса, бөтен галәм җимерелер иде бит. Логикалары бездән үзгә булганга яратабыз да бит инде без хатын-кызларны. Әллә ул аларда бөтенләй юкмы соң? *(Шаяртам!)*

15 Хаклы икәнеңне яхшы беләсең, әмма хатыныңның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишләргә?

Элегрәк мин хатыным белән бик еш сүзгә килә һәм бәхәсләшә идем. Уртак тел таба алмаган чакларыбыз күп булды. Юк кына нәрсәдән эләгешеп китә идек. Еллар узган саен, бәхәсләшүләр кимегәннән-кими барды. Хәзер инде мин аңа һәрвакыт диярлек юл куям, дәшмим... Бер-беребезгә шулай ияләшүме икән бу, әллә картаю галәмәтеме?.. Белмим. Әмма мин нигәдер теге вакытларны – бәхәсләшкән чакларны искә төшерәм һәм... сагынам!

16 Ир кеше ачыгып, арып-талып эштән кайтып керә, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатын, мин ардым дип, диванда кырын ятып тора...

Ситуациягә карап хәл итәсең инде. Әмма минем хатыным беркайчан да диванда болай гына, сәбәпсез генә ятмый! Ашарга пешерүнең исә минем өчен бер авырлыгы юк аның. Гадәти эш! Җиңнәреңне сызганасың да, әйдә!.. Нәрсә-нәрсә, тик ашарга әзер булмау талашуга берничек тә сәбәп була алмый инде.

17 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

Бу сорауда әлеге ситуация инде бик төгәл итеп сурәтләнгән. Ул бөтен гаиләләрдә дә бертөсле – стандарт дисәк тә була, димәк – гадәти күренеш. Хатыннарыбызны алыштырмыйбыз, бернәрсәне дә үзгәртмибез! Барысы да ничек бар, шулай калсын! Әйе, без бер-беребезгә охшамаган, тик тормышның бөтен матурлыгы да шунда бит! Мин һәрвакыт хатынымны лифт кырыена чыгып көтеп торам. Һәм тагын күп еллар көтәргә әзермен.

18 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

Хатыным миңа өч бала тапты – моннан да зуррак бүләкне күз алдына китерү мөмкин дә түгел! Минем инде хәтта оныгым да бар! Анысы, гомумән, Ходай бүләге аның! Ә бүләк дигәндә, бер-беребезгә күп еллар бирешмибез. Мәгънәсе юк бит аның. Безнең инде бөтен нәрсәбез дә бар. Ә нидер сатып аласы булганда, кибеткә икәү чыгабыз да, кирәкле әйберне бергә сайлыйбыз. Һәм аны бүләк дип атыйбыз. Минемчә, бик җайлы, акыллы һәм дөрес юл. Күңелле дә...

Фотода: киноактриса Орнелла Мути белән. Мөселман кинофестивалендә. Казан.



БӘЯНЫМА КЕРЕШКӘНЧЕ, АЛДАН УК ИСКӘРТЕРГӘ КИРӘКТЕР. БУ — УЙЛАП ЧЫГАРГАН ХӘЛ ТҮГЕЛ. ГЕРОЙЛАРНЫҢ ИСЕМНӘРЕ ГЕНӘ ҮЗГӘРТЕП БИРЕЛӘ.

КЫРАЛАК ӘНИ

Лилия ГӘРӘЕВА

«Беркайчан да «беркайчан да!» димә. Алданиләр күрәсеңне белмисең бит. Әгәр дә кемдер миңа бу хәлләрне элегрәк сөйләсә, гомер ышанмас идем. Минме??? Беркайчан да!!!» Без аның белән күптән түгел таныштык. Күршедәге фатирга бер ел элек кенә күченеп килде ул. Исәнмесез-саумысыздан башланып киткән танышлык зурайды, сер сыярдай дуслыкка әверелде. Икебезнең дә тормыш бер тирәдә кайнаша безнең. Балаларыбыз бер бакчага йөри, бер түгәрәккә илтәбез – кайвакыт мин аныкын алам, кайвакыт ул минекен. Көчле рухына, дәрманына сокланам мин аның. Тормыштан зарланмый, ара-тирә миннән әҗәткә алгалап торса да, үзенекен үзенә җиткереп бара. Ирен яманлаганын да ишеткәнем юк, киресенчә, аны яратканы, көткәне сизелеп тора. Ни хакында гына сүз башласак та, җеп очы гел шул кешегә барып тоташа. Әмма, ир дигәне аның өмет утын бер тында өреп сүндерде. Ул икенче хатын белән никахлашканда алар әле рәсми аерылышмаганнар да иде. «Яңадан кушылырбыз, баланы ятим итмәбез», – дип өметләнеп яшәгән күршемнең ниләр кичергәнен аңлата алмам мин сезгә. Ир бирмәк – җан бирмәк. Бар өмете чәлпәрәмә килде.

Баласының туган көне иде. Әтисендә кунак булган сабый андагы тормышның матурлыгына, җитешлегенә, яңа туган энекәшенә исе китеп кайткан. Сөйли дә сөйли. Әнисенең үзәген өзгәнен белми шул ул.

«Бүген Алиса килеп китте, – диде күршем, балалар зур якка уйнарга чыгып киткәч. Алиса – аның дус кызы. Бар белгәне – интернет. Ашаганда да – шул, йоклаганда да. – Ничек кенә берәр өстәмә эш табасы, дигәч: «Ник донор булып бармыйсың, әйбәт кенә акча эшләр идең», – ди. Белмим дә инде, әллә барып карыйм микән, берочтан сәламәтлегемне дә тикшертер идем?..»

Донор? Кан биргән өчен акча түләмиләр түгелме соң?! «Күкәй күзәнәк доноры булу турында әйтәм мин», – диде күршем. Шушы эш белән шөгыльләнүче агентлык бар икән. Риэлторлар шикелле: монда – сатучыны, анда алучыны табалар. Бр-р-р! Гөнаһтыр бит ул алай!

...Инде икенче мәртәбә донор булып бара күршем. Ярыйсы гына түлиләр икән (35 мең сум тирәсе ди). Өстәвенә, бөтен анализлары бушлай. Аның сәламәтлегенә шикләнмәгән дә идем, авыру кешенең көче аныкыдай ташып тормас. Өйдә тик утыра белми ул. «Авырттымы?» – дим, эчемә энәләр кадалгандай, калтыранып. Күршем белән соңгы вакытларда утырып сөйләшергә җай да чыкканы юк. Донор хатыннарны, күзәнәкләрне сатып алучыларны тапкач, ун көн уколга йөртәләр. Фолликулалар гадәттәгедән зуррак булып үссен дә, аларны алырга уңайлырак булсын өчен гормоннар кадыйлар икән. Бу эшкә 35 яшькә кадәргеләрне генә сайлыйлар, һәм ул кеше Татарстанда нибары дүрт тапкыр гына донор була ала.

...Бүген аңа клиникадан шалтыратканнар. Суррогат (кыралак) әни булуын сорыйлар. Аның бөтен күрсәткечләре шуңа туры килеп тора. Үзе ялгыз (биологик аталар бик көнче булалар икән. Ничек инде, анда эчтә аның баласы үсеп ята, ә бу хатын монда ниндидер бер ир белән мәхәббәт... Юк, аның баласы моны күрергә тиеш түгел!), инде бер баласы бар, ярып алмаганнар, үзе тапкан, яшькә дә яшь (клиникада утызга кадәрге хатын-кызларга өстенлек бирсәләр дә, биологик ата-аналар утыз биш-утыз алты яшьлекләргә ныграк ышана, ди), бөтен анализлары яхшы. Ризалашмаган. Кабат гаилә корып, үз балаларын табарга хыялланган хатын моңа ничек риза булсын инде? Күршемнең, юк аның гына түгел, бәләкәй кызының да олы хыялы бит ул – әтиле, бәбиле бәхетле гаилә булып яшәү! Баласының бу хыялын ничек тартып алсын ул? Әтисендә кунак булып кайткан саен, аларның ничек яшәүләрен, энесенең дә, сеңлесенең дә үз бүлмәләре булуын, әтиләренең аларны машинада гына йөртүен, аңа да машинада йөрүнең бик ошавын сабыйларча мактанып сөйләгәндә, күршемнең җаны парә-парә телгәләнә: «Гафу ит, балам, бәгърем! Боларны бирә алмавым өчен, әтиеңнең мәхәббәтен саклый алмавым өчен гафу ит!»

...Бәндә меңне уйлый, Алла берне юллый. Тормыш без уйлаганча гына барса икән лә! Бу араларда күршемнең яшәү урыны белән проблемалары килеп чыкты әле. Фатир бүлешеп яшәүче күршесе икенче шәһәргә китеп барды. Фатир хуҗасы: «Йә тулысынча үзең түлисең, йә китәсең», – дигән. Фатир бүлешеп яшәрдәй кеше таба алмый гаҗиз ул. Уналты мең хезмәт хакы алып, аның ундүрт меңен фатирга түләсенме? Башкасына күченим дисә, бала кызганыч, болай да биш бакча алыштырды бит инде. «Бу тилмерүнең ахыры-чиге күренми. Балам укырга кергәч тә мәктәптән-мәктәпкә йөрербезме? Әллә риза булыйм микән шуларга бала табарга? Ичмасам, ипотекага квартира алыр идем!»

Тугыз ай буе азапланып күтәргән баланы тап та кешегә бир? Мөмкинме бу? Ул, бәлки, үзен ничек тә күндерер, килешер. Ә әти-әнисе, авылдагы күршеләре, эштәгеләр? Алар нәрсә уйлар? Иреннән аерылды да зинадан бала таба диярләрме? Әти-әнисенең битенә ыштыр каплау бит бу! Тормышында берәр ир-ат пәйда булуга: «Әнием, син аңа кияүгә чык. Без дә бәби алып кайтыйк!» – дип өзгәләнгән кызына ничек аңлатыр?

Кызым мине көнгерә дип атый, ә мин исә үземне инкубатор дим.

...Ул бүген барысын да хәл иткән. «Мин бик озак уйладым. Бер билге җибәрүен сорап, көн-төн Ходайга ялвардым. Аллаһы Тәгалә үзенең ризалыгын бирде бит, балам авызы белән әйттерде! Беркөн телевизорны кабызсам, суррогат әни турында фильм күрсәтәләр. Фильм беткәч, кызым: «Ник ул апа бәбине тегеләргә бирде?» – дип сорый. «Бәби аныкы түгел иде бит, ул теге кешеләрнең бәбие иде. Апага бик тә акча кирәк, торыр урыны юк», – дип аңлаттым. Аңлады сабыем. Бик-бик акыллы ул минем, хисләремә үтә сизгер. «Ә ник без шулай итмибез? Безнең дә акча юк бит!» – «Кызым, ул бәбине аннан соң чит апага бирергә туры килә бит, ул безнеке булмый», – дим. «Чит апага бирмибез, үз әнисенә бирәбез, без бит аңа булышабыз гына».

Клиникага барсам, анда эшләүче Елена да авырлы. Игезәкләр икән. Аның өчен куандым да, көнләштем дә. «Сез нигә суррогат әни булырга ризалашмыйсыз соң? Алай сез уйлаганча куркыныч әйбер түгел бит ул, – ди Елена. – Мин аны хәтта саваплы эш тә дияр идем әле. Тилмереп бала көткән кешеләргә дөньяның иң зур бүләген бирәсез сез». «Үзем тапкан баланы чит кешегә бирә алмам мин», – дим. «Әйдәгез, шундый очракны уйлыйк әле. Мәсәлән миңа дүрт-биш айга каядыр китәргә кирәк, һәм мин баланы сезгә калдырып торам. Кайткач, сез аны миңа кире бирмәс идегезмени?» – «Бирер идем, ул бит сезнең балагыз». – «Бу да шундый ук очрак. Ул сезнең балагыз түгел, ул сездә вакытлыча».

...Аңа парны (биологик ата-ананы) бик тиз таптылар. Бүген күршем алар белән очрашуга бара. Бер-берләрен ошатсалар, килешү төзиячәкләр. Күршем бала табып

Фото интернеттан алынды

бирергә тиеш кешеләр чит илнекеләр икән, хатыны дүрт тапкыр ЭКОга барса да, ана булу бәхетенә ирешә алмаган. Ул ишектән күренүгә сорауларга күмеп ташладым: «Йә, нәрсә, очраштыгызмы? Ошаттылармы? Ничек хәл иттегез?» Мин аның ниләр кичергәнен, җанында нинди хисләр актарылганын аңлыйм.

...Күршем авырлы. Нибары бер тапкырдан бар да уңышлы килеп чыкты. Пробиркада үсә башлаган яралгы бик нәзберек була, аз гына хәрәкәттән дә үлеп китәргә мөмкин икән. Шуңа күрә күршемнең аяк-кулларын бәйләгәннәр, кисәк хәрәкәт ясамасын дип, наркоз да биргәннәр. Йоклата торганны түгел, ниндидер башканы. Барысын да экраннан үзе күреп торган. «Озын нечкә шланг белән кечкенә шарчык керттеләр дә, ул, тибрәнә-тибрәнә, каядыр кереп югалды. Бернинди дә авырту тоймадым», – диде күршем минем ничек тә, ничек дип аптыратуларыма каршы. Аннан чыккач, авылга кайтып, мунча да кереп килде әле. Гәрчә, юлда йөрү, мунча керү атна-ун көн тыелган булса да. Хәзер аңа бик күп нәрсә – бала туганчы чит илгә чыгу, ир-ат белән йоклау, эчү-тартуны әйтмим дә, үз белдеге белән дарулар эчү тыела. Ай саен ашау-эчүгә 15 мең сум акча түлиләр. Баланы табып биргәч, тагын 600 мең сум гонорар бирәчәкләр. Ул акча инде күптән аның счетында ята, бала тумыйча торып, файдалана гына алмый.

Чарасызлыктан баралар бу эшкә. Акчасызлык, фатирсызлык этәрә моңа.

...Иртән-иртүк телефоным шалтырады. Күршем икән. Ашыгыч ярдәм чакырткан. Ашыгыч ярдәм?! Соңгы вакытта коточкыч токсикоздан интекте ул. Газаплаганын күрмәсен дип, кызын да әти-әнисенә кайтарып куйган иде. Тыным-өнем бетеп, күрше фатирга томырылдым. Керсәм, урын-җир, идән-келәмнәр кан гына. Туктаусыз укшудан, аналык мускуллары тартылып, бала яткан урын куба башлаган. Күршемне хастаханәгә салдылар. Хәзер аңа берара хәтта утырып та торырга ярамаячак. Эшендә тагын сүз булыр инде, болай да кырын карый башлаганнар иде.

...«Бүген моның әнисе килә», – диде күршем, бармагы белән генә корсагына ымлап. Аңа бала хакында мөмкин кадәр азрак уйларга кушканнар – рухи бәйлелек барлыкка килә күрмәсен. Кызык... Үз балаңны көткәндә аның турында гына уйлыйсың бит ул: күзләре нинди булыр, чәчләре... Аның тәпи китүләрен, тәүге авазларын – барысын-барысын уйлап хыялланасың. Күңелеңнән генә аның йомшак битләренә үзеңнең битеңне куясың. Эх, тизрәк-тизрәк тусын иде, дисең, шул бәхетле көнне тының белән тартып китерердәй булып. Ә монда бөтенләй башка. Сиңа бу баланы тугач хәтта күрсәтмәячәкләр дә. Син аның күзләрен дә, чәчләрен дә мәңге күрмәячәксең. «Мин үземне бер савыт итеп хис итәм. Аяклы савыт», – ди күршем.

...Күршем баланың йөрәген тикшертеп кайтты. «Әнисенең ни уйлаганын бала тоеп тора», – дигәнне һәрберебезнең ишеткәне бар. Ана белән баланың күренмәс кыллар белән ялганганын, икесенең йөрәге бердәй типкәнен үз күзләре белән күргән ул. Кырык минут бернәрсә турында да уйламыйча, тыныч кына ятып торырга кушканнар аңа. «Кырык минут буе ничек кенә ятармын, бик күп бит ул», – дип борчылган күршем. Шул мәлдә баланың йөрәге дә телгә килгән: «Дөп-дөп-дөп-дөп!» Аннан соң телефоны шалтыраган, ә сөйләшергә ярамый икән. Баланың йөрәге тагын да катырак дөпелди башлаган. «Дулкынланмагыз», – дип, журнал алып килеп биргәч, күршем бераз тынычлана төшкән. Баланың да йөрәге тынычланган. Бераздан йокы баса башлаган. Баланың йөрәге дә: «Дөп... ...дөп... ...дөп» – ул да йокыга талган.

...Клиникада эшләүче Елена чын дөресен әйтмәгән бит. Ул да үз балаларын түгел, чит кешенекен күтәргән. Күзләрендә нур сүнгән, боек хатынны күршем хәтта танымаган да. «Елена, сиңа ни булды, балалар белән ул-бу бармы әллә?» – дигәненә: «Әгәр дә сиңа баланы имезергә тәкъдим итсәләр, беркайчан да ризалашма. Аннан соң мәңге оныта алмаячаксың», – дип җаваплаган.

Елена игезәкләрне бер ир кешегә табып биргән икән. Ялгызы гына яшәүче бай кеше, ди. Елена аларны өч ай имезгән. Өч айдан соң, аңа китәргә кушканнар. Балаларны нәнкәләр үстерәчәк, ди. Игезәкләргә шулкадәр ияләнгән бичара хатын алар янында озагракка калу өчен ничек кенә өзгәләнмәгән. Бала караучы итеп алыгыз дип тә караган, булмаса, миңа өйләнегез, балалар үскәнче генә яннарында булыйм дип, теге ирнең алларына тезләнеп ялварган.

...Бала туарга бер айдан кимрәк вакыт калды. Күршем инде булачак фатирына матур савыт-сабалар җыя. «Баладан аерылуны күз алдыңа китерәсеңме?» – дим. «Мин аны уйламыйм да, мин үз баламны уйлыйм. Яңа фатирда аның белән куанып яшәр көннәремне уйлыйм», – ди ул. Баксаң, күршем кебек суррогат ана булырга теләүчеләр күп икән ул хәзер. «Бигрәк тә авылныкылар күп килә. Акча эшләүнең чагыштырмача җиңел юлы бит», – ди күршем. Җиңел?!! Каян килеп җиңел булсын??? Токсикозын әйтмим әле, тулгак газаплары, эчеңне тотам-тотам умырып, сөякләреңне берәм-берәм сындыралар кебек тоелгандамы җиңел?

...Бүген баланы тудырттырырга тиешләр. Анда аның әти-әнисе инде көтә. «Нигә карамадым, дип, гомер буе үкенерсең, бер генә булса да күз сал», – дим. Ул үзе дә шулай уйлый. Нигәдер, күз алдында шул баланың йөрәк тибешен күзәткән теге мизгел. Колагында – аның борчылуына җавап итеп дөпелдәгән бәләкәй йөрәк тибеше. Аның үз йөрәге белән бергә типкән бәләкәй йөрәк. Әйе, ул – аның үз баласы түгел, ул аннан бүген мәңгегә аерыла. Әмма күршем аларга бүген шул бала белән бергә үз йөрәгенең дә бер өлешен бүләк итә. Аның урынына үзендә бушлык кына кала...

БУ КЫЮ КЫЗГА ҖИҢҮ ТАҢЫН КҮРЕРГӘ НАСЫЙП БУЛМЫЙ. ӘММА АНЫҢ БАТЫРЛЫГЫ БУЫННАН-БУЫНГА ВАТАНПӘРВӘРЛЕК ҮРНӘГЕ БУЛЫП СӨЙЛӘНӘ.

КЫРЫМ КЫЗЫ

Советлар Союзы Герое, танкист Мария Октябрьская 1905 елның 8 мартында Кырымда туган. Мария Октябрьская (кыз вакыттагы фамилиясе – Горгуля) 1925 елда хәрби училище курсанты Илья Рядненко белән өйләнешә. Язылышканда гаилә үзләренә Октябрьскийлар дигән фамилия ала. Бу хәл – яшьләрнең ни дәрәҗәдә ватанпәрвәр булуына бер дәлил. Хәрби офицер гаиләсе ил буйлап байтак күченеп йөри. Кайда яшәсәләр дә, Мария иренә лаек булырга тыраша. Машина йөртергә дә өйрәнә, «Ворошиловча төз атучы» дигән исемне дә ала, граната ыргыту, пулеметтан төз ату осталыгына да ирешә. Җитмәсә, дөньяда бер кул эшләре остасы дигән даны да була.

Бөек Ватан сугышы башланганда алар Кишиневта яшиләр. Илья Октябрьский – сугышның беренче көненнән алгы сызыкта. Мария исә ерак Себергә эвакуациягә китә. Ире Илья 1941 елның августында Киев янындагы сугышларда һәлак була. Мария сөекле иренең һәлакәтен бик авыр кичерә. Новосибирск шәһәренә Томскидан делегат булып хатын-кызлар корылтаена баргач, Мария Октябрьская уллары яки ирләре фронтта һәлак булган хатын-кызлар белән таныша. Аларның ничек итеп ир-ат һөнәрләренә өйрәнүләрен тыңлап тора. Хәлиткеч карарны да ул шунда – корылтайга баргач кабул итә. Аның урыны алгы сызыкта!

Болай да сугышка ыргылып торган хатынны хәзер бер ни дә тылда тыеп тота алмый кебек. Ләкин бала чакта кичергән туберкулез чире аңа фронтка юлны яба. Шулай да, ул бертуктаусыз хәрби комиссариат юлын таптый бирә.



Дошманга үче кайнаган хатын иренең һәлакәте өчен үч алуның да юлын таба. Ул бөтен булган мал-мөлкәтен сатып, танк төзетү өчен акча җыярга керешә. Җыйган акча гына аз булып чыккач, төннәр буе ашъяулыклар, келәмнәр чигеп, аларны базарда саттырып, ниһаять, танк алу өчен җитәрлек 50 мең сумны туплый да, Сталинга телеграмма юллый. Телеграммада ул үзенең фронт өчен әзерлекле булуын дәлилли. «Ватан өчен сугышта минем ирем – полк комиссары Илья Октябрьский һәлак булды. Аның өчен, һәлак булган меңнәрчә кешеләр өчен дошманнан үч алырга телим. Дәүләт банкына 50 мең акча күчердем. Шул акчага танк төзетеп, ул танкны «Боевая подруга» дип атап, мине танк йөртүче сыйфатында фронтка җибәрүләрен үтенәм».

Сталин имзалаган җавап телеграммасы озак көттерми. Анда Мариянең теләге үтәләчәге әйтелә. Үзе сатып алган танкның йөртүчесе сыйфатында сугышка Мария Октябрьская үзе барачак!

Танкның сыртына Уралдагы завод конвейрыннан төшкәндә үк «Боевая подруга» дип языла. Шулай итеп, Омск танк училищесын тәмамлаган Мария фронтка китә. «Боевая подруга» Ельня гвардия танк бригадасы составына теркәлә. Беренче мәртәбә сугышка Мария Октябрьская экипажы ире һәлак булган урынга якын гына җирдә керә. 1943 елның 18 ноябрендә «Боевая подруга» дошман оборонасына беренче булып бәреп керә. Дошманның танкка каршы пушкасын юк итә, утызлап солдатын дөмектерә. Ләкин шул сугышта «Боевая подруга» да зарарлана. Яралы Мария, сугышчан дуслары килеп коткарганчы, ике тәүлек буена дошман камаган танктан чыга алмый.

1944 елның гыйнварында Витебск өлкәсенең Крынки авылы янында каты сугышлар була. Сафтан чыккан танкның чылбырларын төзәтеп торган Мариянең башына мина кыйпылчыгы килеп тия. Мария 1944 елның 15 мартында Смоленск госпиталендә үлә. Моңа кадәр I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнгән Мария Октябрьскаяны Советлар Союзы Герое исеме белән бүләкләү турындагы карар 1944 елның 2 августында чыга.

Танкист Мария һәлак булганга карап, «Боевая подруга» сугышчан юлын туктатмый. Исемен саклаган хәлдә, бер танкны икенчесе алыштыра-алыштыра, дүртенче танк Кенигсбергка барып җитә. Чөнки танк экипажын нинди дер кодрәт, могаен, Мариянең рухыдыр, саклап тора.


Томскидагы 24 нче мәктәп Мария Октябрьская исемен йөртә. Мәктәп каршында танкист ханымга һәйкәл куелган. Смоленскида һәм Җанкайда (Кырым) Мария Октябрьская исемен йөрткән урамнар бар.

Асия ЮНЫСОВА әзерләде.



«Ял итәргә икәү генә барыйк инде! Баланы әби-бабасына илтсәк була бит», — дип күндердем иремне. Шулай итеп, өч яше тулмаган сабыебыз яраткан әби-бабай кочагында калды, ә без кояшлы Италиягә юл тоттык.

БАЛАСЫЗ БАЛ АЕ



Сөмбел ГАФФАРОВА

Казаннан туп-туры Римини шәһәренә очтык. Италиягә бару турында ничек кенә хыялланмадым мин, әмма менә хәзер бу илнең туфрагына аяк басуыма ышана да алмый торам... Җәйге чилләне яратмаганга көзне сайладык – пляжда аунамыйча, мөмкин кадәр күбрәк йөрергә иде исәп.

Римини

Римини – Әдрән диңгез буендагы туристлар шәһәре. (Отельгә дүрт йолдызның ни сәбәпле бирелгәнен аңламадык. Чагыштыру өчен: Төркиядә шул ук отельләр күпкә матуррак һәм уңайлырак.) Отельләр тирәсендәге кибет сатучылары инглизчә сөйләшә, итальянча тел сындырып торасы юк. Өстәвенә, сатучыларның күбесе йә урысча сукалый, йә алар ватандашларыбыз ук булып чыга. Монда килгәнче өч атна буена итальян телен юкка гына өйрәнеп утырдым микәнни?! Ипилек-тозлык өйрәнә алдыммы-юкмы, итальяннарга туган телләрендә эндәшүем була, йөрәкләренә бәлзәм ягылгандай, авызлары ерылып, карашлары җылынып китә иде.

Шәһәр эчендә автобуста йөрер өчен чат саен торучы «Tabaccio» кибетләрендә билет сатып алырга кирәк, шуны махсус тартмада тиштереп, автобуска узасы. «Куян» булып барам димә! Контролерлар сагалап кына тора,



■ Император Августның триумфаль аркасы безнең эрага кадәр 27 нче елда төзелеп, XVIII гасырда торгызылган. Ул Рим аркаларының иң борынгысы!

■ Тиберий күперенең төзелеше император Август заманында безнең эраның 14 нче елында башланып, император Тиберий вакытында 21 нче елда тәмамланган (ашыкмаганнар!).



штраф та салырлар, виза бүлегенә сезне фаш итүче мәгълүмат та җибәрерләр. Чит илдә закон бозып йөрмәгез дип әйтергә телим. Без исә бер тапкыр да автобуска утырмадык – иртәдән кичкә кадәр Римини урамнарын җәяү урадык. Аяк табаннары янып чыкмыйча отельгә кайтып торыш юк (Кулдагы кәгазь картаны әйләндердек-боргаладык та, аны читкә куеп, телефонда навигаторны көйләп, шуның белән генә йөрдек – бик уңайлы икән.) Түләүле экскурсияләрдә ашыга-ашыга йөрүләрдән баш тартып, Италияне үзебез генә өйрәнергә булдык. Теге яки бу бинага карап, кызык фактка юлыгып, үзара фикер алышу, мантыйкны җигеп, аның хакта әллә ниләр уйлап чыгару никадәр кызык!

Ә хәзер уйдырма түгел, чын мәгълүмат белән уртаклашыйм. Император Августның триумфаль аркасының диварлары дүрт метрдан калынрак гап-гади арка бөеклеккә, тантанага һәйкәл булып тора. (Казанда Бауман урамындагы сәгать янында очрашулар билгеләнгән кебек, монда да очрашу көткән гашыйклар тезелешкән.) Арканың Рим Аллалары Юпитер һәм Апполон сурәте төшерелгән фасады – Римга, Нептун һәм Рома сурәтлесе – Риминига карап тора. Бу сурәтләр нигәме? Апполон император Августка Антоний белән Клеопатрага каршы сугышта җиңәргә булышкан, диңгездәге бәрелешләрдә исә Нептунның ярдәме тигән, ди. (Элек менә ничек булган, ә!) Аркадан узып, шәһәрнең үзәк урамына килеп эләктек. Кибет тәрәзәләрендә ясатылган чәчле, модага туры китереп киенгән халык чагыла – һәркем башкаларны күзли, үзен күрсәтә.

Алга таба киттек. Тиберий күперен тикмәгә генә Шайтан күпере дип йөртмәгәннәрдер – испаннар, готлар һөҗүмен, җир тетрәүне, ташкынны, Икенче бөтендөнья сугышы һөҗүмнәрен кире кага алган ул!

Күпер аша машиналар уза, кешеләр уза. Уйлап карасаң, аяк астыңда ничәмә гасырлык тарих ята, ә син аның аша елганы кичеп чыгасың да дөнья кууыңны дәвам итәсең. Ә без ашыкмыйбыз. Туктадык. Үзебез генә туктап калмадык, Вакыт галиҗәнапларын итәгеннән тотып, елга дулкынында чайкалган акчарлакларга карап, үзебезне хәзерге мизгел кочагында итеп тойдык. Без. Шушы секундта. Борынгы Тиберий күпере өстендә. Италиядә... Басып торабыз. Кан тамырларыбызга кадәр тоемлап. Моны аңыбызга сеңдереп. Һәм... Юлыбызны дәвам итеп, шәһәр эченә йотылабыз.

Кавур мәйданы Римининың мәдәни үзәге санала. Мәйдан уртасына басып, әйләнә-тирәдәге биналар белән хозурланырга керештек – XIII–XVI гасырларда салынган сарай фасадлары, Павел V һәйкәле, XVI гасырда ак мәрмәрдән уелган «Күркә» фонтаны (соңгысы заманында Леонардо да Винчины сокландырган дип сөйлиләр! Суы эчәргә яраклы – без дә пластик шешәбезгә суын агызып алдык). Әнә тегендә Театро Коммунале – 1857 елда Джузеппе Вердиның «Гарольд» операсы белән ачылган мәшһүр театр.

Италиядәге һәр бина, һәр ишегалды, һәр юл билгесе безгә кызык, һәрберсенең үз тарихы бар!

Телеңне йотарлык туңдырма белән сыйланган арада аякларга да ял бирдек бераз. Интернетта казынып алдык. Рубикон елгасы нәкъ Римининың төньягында ага икән. Озынлыгы бары тик егерме тугыз километр гына булса да, кешелек тарихында кала алган! Гай Юлий Цезарьның «Рубиконны



Сан-Миниато-аль-Монте базиликасына оза-ак барып арыдык. Аның каравы, калкулыкта урнашкан базиликадан ачылган манзара безнең өчен зур бүләк булды. Әнә Санта-Мария-дель Фьоре соборы – нәкъ открытка-альбомнардагы күренеш!



кичү», ягъни «авыр карар кабул итү» дигән канатлы сүзе монда туып, бөтен Җир шарын әйләнеп чыккан! Һәркемнең тормышта үз Рубиконы була. Цезарь үзенекен кичеп, әнә, Римны кулга төшергән. Ә без?..

Флоренциягә сәяхәтне без Казанда ук планлаштырдык – отельгә урнашуны да, поездга билет алуны да интернет аша хәл иттек.


Римини биш Оскар иясе Федерико Феллини рухы белән ныгытып сугарылган. Атаклы режиссерның балачагы-яшьлеге биредә узганлыгын шәһәр бар көченә файдалана – аның исемен йөртүче музей, аэропорт, парк исеме, кинематография фестивале, аның фильмнары турында сөйләүче баннерлар туристларга бик ошый. Күпмедер вакыттан соң үзеңне режиссерда кунакта дип хис итә башлыйсың.

Флоренция

Флоренциягә багышлап ничәмә мәкалә укылды, интернеттагы фотолар каралды, һәм менә ул – хыялның чынга ашу мизгелләре башлана: без Римини тимер юл вокзалында! Иң баштан Болонья шәһәренә барасы, шуннан башка поездга күчәсе. Кая, ничек барырга кирәклеге аңлашыла – адашып бетәрбез дип курыккан идем, кирәк булганда баш та эшли, онытылган инглиз һәм итальян сүзләре дә искә төшә икән үзе тагын. Алга китеп сөйлим әле – кайтыр юлга чыккач, маҗарага тарыдык! Билетыбызда күрсәтелгән вакытта, безгә кирәкле перронда туктаган поезд... безнеке булып чыкмады! Поездның соңарып килүе табигый икән монда. Контролер туташ бер станциядә төшереп, кире Болоньяга билет алырга кушты. Аннан исә алдан алынган билетларыбыз белән Риминига илтүче поездга утырырга өлгердек – өч сәгать дәвамында кулланыла ала икән ул. Бусы өчен рәхмәт.

Безнең отель шәһәр уртасында, вокзалга бик якын урнашкан. Дүрт көн торасы отельне бик тиз табып алдык. Кечкенә генә бүлмә кичен кайтып аварга, иртүк чыгып чабарга көйләнгән. Европаның үзе сыман иске, ләкин пөхтә, нәкъ фильмнардагы шикелле! Сумкаларыбызны ташлап, Флоренциягә «чумдык».

Флоренция – Данте Алигьери, Франческо Петрарка, Джованни Боккаччоларның туган шәһәре, яңарыш чорының башлангыч ноктасы! (Бу җөмләне кабат укыгызчы! Алигьери, Петрарка... җыр кебек агыла бит!) Ренессанс архитекторлары Филиппо Брунеллески, Леон Батиста Альберти күп гасырлар дәвамында байтак шәһәрләрнең төзелешенә тәэсир иткән. Без дә тәэсирләнеп, Санта Кроче базиликасына кереп киттек. Әлеге базилика (XIV гасырда төзелә) – шәһәрнең иң зур чиркәүләреннән берсе. Дивар буйлап каберташлар тезелгән. Сәнгать әсәре саналган кабер ташлары янына килсәк... Биредә 300 атаклы сәнгать, фән, сәясәт әһелләренең кенотафлары (кабер тактасы куелып, кешесе җирләнмәгән) һәм каберләре урын алган. Мәшһүр язучы Стендаль әлеге чиркәүгә кергәч, биредәге матурлыктан һушсыз калып, йөрәге еш-еш тибә, башы әйләнә башлаган дип сөйлиләр. Хәзер бу халәт Стендаль синдромы дип атала (авыручының сәнгать әсәрен юк итү теләге дә уянырга мөмкин!). Сез көләрсез, әмма шәһәр хастаханәләрендә мондый синдром белән килүчеләр өчен махсус бүлек ачылган! Гадәттә, бу синдромга мәгърифәтле, сәнгатьне аңлаучы һәм аны яратучылар дучар була. Күбрәк япон туристларын китерәләр дип сөйлиләр.







■ Бинокль булса, кешелекнең яралтылуы тарихын сөйләүче бизәкләр, Донателло ясаган сыннар, барельефлар белән чуарланган Санта-Мария-дель-Фьоре соборы диварын сәгатьләр буе әйләнер идем.

■ Пластик шешәләрне ташламагыз. Шәһәрдә чиста сулы фонтаннар бар – ничәдер евроны янда калдырырсыз.



Боларны истә тотып, шәһәрне «йотарга» планлаштырмадык, әкрен-әкрен, күргәннәрне үзләштереп хозурландык.

Флоренция турында «күк астындагы музей», диләр. «Ah!» итеп йөрдек. Иң ошаган урыннар турында сөйлим әле. Питти сарае (1377–1446 елларда төзелә). Уффицци галереясы Питти сараена караганда популяррак санала. Керү билетын алу өчен сәгатьләр буе чиратта тору кирәклеге шул хакта сөйли (алдан интернеттан сатып алырга була – тик... бәясе кыйбатрак). Әмма сез рәсем белгече булмасагыз, нәкъ Питти сараена барырга киңәш итәм. Сарайның Боболи бакчасына да керергә теләдек, әмма аның сезоны ябылган иде инде. Питти сараена керү билеты алганда, анысына да билет алып калсагыз, үкенмәссез.

Флоренция банкиры Лука Питти сарайның хуҗасы булган. Ул сарайны атаклы Медичиларның барлык йортларыннан да зуррак итеп төзетә. Язмыш кызык итә – Лукка Питти биредә байлыгында йөзеп өлгерми, ә менә Медичилар һәм башка династиялар туйганчы торып кала. Сарайда XVI–XVII гасырларның фламанд мәктәбенә караган картиналар саклана. Ничәмә залдан үтәбез... Сандро Боттичелли, Рафаэль Санти, Рубенс, Ван Дейк, Понтормо һәм башка исемнәрне укыганда, йөрәгең кысылып куя. Дөньяның байлыгы хозурымда!

Бераз ял итеп, җиргә төшик. Отелебез бөтен дөньяга атаклы Сан-Лоренцо күн базары янында урнашкан дип әйтмәдем бит әле! Биредә күннән тегелгән чын итальян сумкасы, акча янчыклары, каешлар... тагын әллә ниләр бар! Үзебезгә, туганнарыбызга бүләкләр алып, банкротка чыга язсак та, бик канәгать калдык!

Җил-җил атлап Нәфис сәнгать академиясе (1561 елда ачылган) янына килсәк... безнең ише матурлыкка чумарга теләүче туристлар озын чиратка тезелгән икән! Ике-өч сәгатьсез керәм димә! Адымнарыбыз белән чиратның башыннан койрыгына кадәр үлчәп чыккач, билет кассасына юнәлдек. Икенче көнгә дип алынган билетларның бәясе кыйммәтрәк булу да куркытмады – күңел тилереп гасырлар матурлыгына ашкынгач, нишләмәк кирәк, түлисең.

Академиядә картиналар да, сыннар да байтак, әмма аларга зур игътибар бирмисең кебек, чөнки алдында кешелек талантына һәйкәл – 1504 елда Микеланджело ясаган сын – Давид басып тора. Микеланджело аны башка сынгатьчеләрдән үзгә ясаган – Голиафны җиңгәннән соң түгел, көрәшкә кадәрге торышын сурәтләгән. Аны күрүгә, музейдагы башка экспонатларны карамадык та...

Флоренциягә бара калсагыз, Давид сынын күрми китмәгез. Кеше сәләте белән горурлану тойгысы күңелегезгә чыкмаслык булып оялар.

Сынны ясау тарихы болайрак: XVI гасыр башында башка бер сынчы бу мәрмәр кисәген бозып ташлый. Озак еллар буе тик яткач, «бозылганны бозып булмый» дип, мәрмәрне егерме алты яшьлек Микеланджелога тапшыралар. Баш күтәрми эшләгән сынчы халык хозурына биш метр биеклегендәге «Давид»ны тәкъдим иткәч, шул ук мизгелдә Италиянең бөек сынчысы исеменә лаек була. Соңрак Микеланджело бер сонетында (әйе, ул шагыйрь дә булган әле!) «Мәрмәр кантарының эченә матурлык алдан салынган була, аны шуннан азат итәргә генә кала» дип әйтер.





■ Мәшһүр режиссер Федерико Феллини бу ресторанга көн дә килгән, дип сөйлиләр.



■ Флоренция – Пиноккионы уйлап тапкан Карло Коллодиның туган шәһәре. Биредә «Үлемсез Пиноккиога 4 яшьтән алып 70 яшькәчә рәхмәтле укучыларыннан» язулы һәйкәл тора. Туристлар сувенир Пиноккиосыз китми.

Санта-Мария-дель-Фьоре соборы янынннан беренче тапкыр узганда авызыбыз ачылып калды. (Хәер, икенче, өченче мәртәбә узганда да бу хәл кабатланды.) Зур! Йөз илле өч метрга туксан метр! Төзелеш проектына караганда, собор эченә шәһәрнең бөтен халкы сыеп бетәргә тиеш булган – ул вакытта 90 000 кеше! Собордан күзне алып булмый. Ул 1296 елдан башлап, алты гасыр төзелгән. 1380 елда аны түбә белән каплыйсы гына кала, әмма... бина бик зур булганлыктан, бу эш ул заман төзүчеләренең кулыннан килми. Кырык ел узгач кына соборны мәшһүр Брунеллески гөмбәзе каплый. (Рәхмәт йөзеннән, аңа собор янында һәйкәл дә куйганнар.) Безгә билет өчен түләп, өскә менәргә һәм шуннан шәһәргә карарга тәкъдим иттеләр. Менмәдек. Әмма әлеге соборның үзен һәм шәһәрне күрер өчен башка җиргә киттек.

Минем Санта-Мария-дель-Фьоре соборын кесәгә салып китәсе килде!

Сан-Миниато-аль-Монте базиликаның эчке матурлыгын карап чыгуга урамга ашыктык. Биредә төрбәләр урнашкан – бик искеләр арасында быелтыр гына урнаштырылганы да очрады. Зиярәт ителеп, пөхтә тотылганы да бар, вазалары авып, ташлары ком-тузан белән капланганнары да... Төрбәләрдәге язуларны укыганда, үлемнең сиңа бернинди катнашы юк дип хис итәсең... Ул әле бик еракта дигән уйларыңны алмаштырып... башыңа шул фикернең нәкъ капма-каршысы килеп бәрелә... Төрбәләр арасында йөргәндә – бакыйлык, уч төбендәге шәһәргә карашыңны күтәргәндә – фанилык турында уйга батасың.

Көн саен Арно елгасы аша тызбыз йөреш – ике ярны тоташтыручы һәр күперендә булдык. Шуларның берсе – бөтен дөньяга билгеле Понте Веккьо (Иске Күпер) – Рим заманыннан бирле тора. Күпернең өске өлеше Васарино коридоры дип атала, ул Палаццо Веккьо һәм Уффицци галереясын Питти сарае белән тоташтыра. Бүген анда автопортретлар галереясы урнашкан (аны сирәк ачалар). Электән күпердә азык-төлек кибетләре шаулап торса, XV гасыр ахырында, бирегә зәркәнчеләр күченгәч, аны Алтын Күпер дип йөртә башлыйлар. Банкротлык төшенчәсе нәкъ биредә барлыкка килгән икән – сатучы бурычка баткач, хәрбиләр килеп, кибет сәкесен (banco) ваткан-нар (rotto). Сәкесе булмагач, зәркәнче эшли алмаган. Без алтын кибетенә сугылып та тормадык – бәяләре арзан түгел, тәрәзәләренә генә күз салдык – үзеңә алтын сайлый калсаң, кибеттән мәңге чыгасың юк.

Кичләрен монда урам музыкантлары концерт куя. Моннан да романтиграк кичә була аламы соң? ...Кичке утларда елга җемелди, күпер өстендәге таш җиргә кешеләр утырышкан, музыкантлар итальянча җырлый... Истән чыгармыйк, без бал аенда бит! Баласыз бал ае яңа хискичерешләргә, яңа тойгыларга, яңа мәгълүматка бай булды. Кечкенә бала җитәкләп, без йөргән кадәр йөреп кара син! Кызыбызны бик сагындык – һәр кич саен интернеттан әби-бабасының көне буена төшергән фото-видеоларын карыйкарый еламадык кына. Баласыз бал ае өчен ике атна чамасыз күп дигән фикергә килдек...

Тагын бер кызык әйбер аңладык – отельгә кайтырга чыккан саен: «Әйдә, өйгә таба борылыйк», – дип әйтеп йөргәнбез ләбаса. Бергә уздырган беренче сәяхәтебезнең ачышы бу. Өебез – икебез бергә булган җирдә икән ул.

P. S. http://syuyumbike.ru сайтында ялыбызда төшерелгән фото һәм видеоларны карый аласыз.



Наилә ЛАТЫЙПОВА

Казан дәүләт медицина институты, педиатрия факультеты (1994).

Кияүдә, ике бала анасы.

Карьера:
«Спасение» медицина компаниясе, табиб-эксперт.

Кредо: «Яхшылык җирдә күбрәк!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Мин дөрес юлда!


Узган ел Европа остеопатия мәктәбенә укырга кердем. Медицинаның авыр, четерекле, әмма кызыклы ягы бу! Уйландыра, дөрес сайладыммы, юкмы әлеге юнәлешне? Бу көннәрдә Казан остеопатия мәктәбенә нигез салучы табиб Васил Зыятдиновның лекциясендә, практик дәресендә булырга туры килде. Куллары белән авыруны «сүтеп», яңадан «җыйган» кебек тоелды ул миңа: аяк бармакларыннан башлады, баш түбәсенә менеп җитте. «Билем», – дип, атлый да алмыйча кергән авыру ханым, сөенеп, җиңеләеп – очып чыгып китте. «Укыйм, булдырам, тырышам», – дип кайттым лекциядән.


Туристларның яраткан шәһәренә әйләнәбез!

Ирем Мәскәү өлкәсеннән минем. Соңгы баруда андагы бер гаилә белән аралашырга туры килде. Дөнья буйлап сәяхәт иткән кешеләр, нинди генә илдә, кайсы гына шәһәрдә булмаганнар! Шулар: «Интернеттан рәсемнәрен карадык – сезнең Казан шундый матур кала икән! Бармакчы булабыз әле. Балаларның да күрәселәре килә», – диделәр. Казанны, Татарстанны үзләре моңарчы күргән шәһәрләр белән бер рәткә куюлары мине чын мәгънәсендә куандырды.


Яшьләр киләчәкне уйлый!

Гадәттә, яшь баланы хәзер табибка гел памперста алып киләләр. Ә шушы көннәрдә карыйм, бер яшь гаилә сабыйларына памперс кигертмәгән. Күренеп тора, хәлле кешеләр, памперс кына алырлык мөмкинлекләре бар. «Ә без «Җир-ананы коткарыйк» дигән акция яклы», – диде алар. Яшь әниләрнең бу хәрәкәте Швейцариядә туган. Памперслардагы гель суны үзенә тартып, җирне киптерә икән. Һәм ничә еллар җирдә ятса да, алар череми. Шундый җайлы нәрсәдән баш тарту рәхәт түгел, әмма...

сөендерде 





көендерде 


сөендерде 



көендерде 

сөендерде 



көендерде 

Сагынулар арта гына...

Узган җәй азагында олы кайгы кичердек. Әтине соңгы юлга озаттык... 77 яшен яңа тутырган иде. Ике елга якын авыр чир белән көрәште. Аны җирләргә кайтып җитә алмадым... Дөрес, иртән генә янынннан чыгып киткән идем. Шуңамы икән, Баулыга кайтсам, ул килеп керер кебек тоела. Вакыт дәва диләр, белмим... Үкенечләр арта гына. Нәрсәнедер эшләп җиткермәдем сыман. Укыганда безне: «Туганнарыгызны дәваларга алынмагыз», – дип өйрәттеләр. Җәлләү, кызгану булганда, салкын акылга урын калмый. Ә табибка ул бик кирәк.

Безнең барыбызны да өйдә көтәләр...

Юлга чыгып китсәң, аварияләрнең күплеге шаккаттыра. Бу бәлага ашыгу, кабалану аркасында гына тарымаучылар бар: зур юлларның үз кагыйдәсе – алар шуны үтәми. Ә юл кичерми... Кагыйдәләр җәяүлеләргә дә кагыла. Бигрәк игътибарсызлар! Яшел утка әбиләр чабып чыгып өлгерергә тырыша, ә яшьләр юл уртасында туктап калырга, «смс» язарга да мөмкиннәр. Мондый хәл башка бер илдә дә юк! Ә наушниклар! Аны киеп юлга чыккан яшь кеше – икенче бер зур бәла...

Суның кадере нигә юк?

«Чит илдә шешәле су гына эчәләр» дигәнне ишетү безгә әле кайчан гына гаҗәп тоела иде. Шул көннең үзебезгә килгәнен сизми дә калдык... Краннан су эчмибез хәзер. Торбалар иске булганга гына түгел. Эчәр суы булмаган илләр дөньяда арта бара. Ә күп чирләр су чиста булмаганнан килә. Суны исраф итмичә кулланырга өйрәнеп бетә алмыйбыз әле. Элек-электән бездә чишмәләрне изге итеп саклаганнар. Юкка түгел бит. Шул йола-гадәтне дә югалтмыйсы иде.



ЯЗ, ЯЗ, ЯЗ ҖИТӘ...

Рәмзия
КАШАПОВА

Язгы тамчылар, гөрләвекләр, кошлар җыры, ягымлы кояш, табигатьтәге хуш исләр — болар бар да модада могҗизалар тудыручыларны яңа коллекцияләргә, яңа кәефкә илһамландыра. Төсләр дуены, әрфиядәй җиңеллек, чук-чачаклар, җете төсмерләр, хискә күчә бара торган хатын-кыз нәзакәте 2015 елгы модада төп тренд исәпләнә.

Язгы кәефкә күчүне гардеробыгызны яңартудан башлагыз. Һәм беренче эш итеп плащ йә пальто сатып алыгыз.

2015 елда пальтолар коллекциясенең яз сезоны тенденцияләре модельләрнең, фасоннарның төрлелегә һәм төсләр балкышы белән җәлеп итәчәк. Караңгы, соры төстәге киемнәргә «төренеп», качып калуны башыгыздан ук чыгарып ташлагыз! Мәсәлән, Гөлназ кебек.

Татар дөньясында билгеле шәхес, журналист, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетында мәгълүмати-аналитик бүлек җитәкчесе Гөлназ ШӘЙХИ безнең язгы образ моделе булырга ризалашты. Ул һәрчак күз уңында: якты, ачык кеше.

Наталья Бардаева язгы образлар тудырганда игътибарны моделебезнең отышлы якларына юнәлтте.

РЕКЛАМА

Соңгы мода күргәзмәләрендә бер генә атаклы бренд та пальто фасоннарын игътибардан читтә калдырмады. Һәр кеше үзенең көтелмәгән образлар җыелмасын тәкъдим итте. Исемнәре билгеле дизайнерларның әлеге өс киеменә игътибары аңлашыла да – модалы пальто һәрчак күзгә ташлана. Чөнки ул гардеробтагы иң кирәкле кием. Табигать бездә озак уяна, шуңа да нәкъ менә яз озакка сузылган, явымлы, җепшек, кайчак уңайсыз да тоела. Шулай да яз яз инде, аны яхшы кәеф белән каршыларга кирәк.

Ачык төсләре, көтелмәгән формалары, үзенчәлекле җиңнәре, кызыклы якалары белән «Люкс» бутигындагы хатын-кыз пальтолары җыелмасы быелгы сезонның төп тенденцияләрен үзенә туплаган.

Күңелле яңалыклар да бар. Пальтолар яңа фасоннар белән генә түгел, яңа тукымалар белән дә баетылган. Инде озак еллар дәвамында модалы пальто тегү өчен Италия тукымалары кулланыла. Алар сыйфатлы, чыдам, уңайлы. Тәерчекләнми, төсен һәм сыйфатын югалтмый. Пальто өчен тукымаларны дизайнерлар аеруча җентекләп сайлый. Шуңа да быел язга яңа пальто алырга уйласагыз, ул сезне берничә ел дәвамында сөендерер.

Язын җиңел топ белән яраклашучы костюмнарга, күлмәк, итәк, блузкаларга өстенлек бирелә. Киемнең төрлесен сайлап була, тукыманың гына теләсә ниндиенә тукталырга ярамый. Ефәк, челтәр, шифон һәм атлас тукымалар – иң кулае. Быелгы сезонга 70 нче еллар стиле һәм минимализм хас. Яшерен каптырмалар, кыска һәм ачык киемнәр, кайтарма яки күтәртмә якалар, V-сыман уемнар, күпертмәле җиңнәр, декоратив шарфбантлар да актуаль булачак. Тукыманы мул кулланып тегү дә киемнәргә бәйрәм кәефе өстәячәк.

Нәкъ менә шушы төс модада дип кистереп әйтү кыен. Үзегез ярата торган төсләргә тукталыгыз. Бу сезонда берничә төс модалы санала: җете кызыл, ак, аксыл-зәңгәр, ал, күк, кара, сыек яшел.

Ак... Язгы-җәйге сезонга аеруча килешә торган бу җиңел төс Милан подиумнарында гына түгел, дөньяның башка мода мәркәзләрендә дә бик популяр. Акның төрле төсмерләренә итальян дизайнерлары аеруча игътибар итә. Giorgio Armani, Gucci, Gabriele Colangelo, Antonio Marras, Roberto Cavalli, Versace кебек атаклы брендлар ак төстәге киемнәрнең классик костюмнардан алып спорт стилендәге итәкләргә кадәр күрсәтте. Аларга килешеп торган аксессуарлар һәм аяк киемнәренең шул төстәгеләрен сайласаң әйбәт.

Яз-җәй сезонында ак белән янәшә зәңгәрнең төрле төсмерләре – нәфис ачык зәңгәрдән алып электрик (зәңгәрле-кызыллы) төсенә кадәр кулланылырга мөмкин.

Яшьләрдән еш кына фирмалы әйберләр кыйммәт дигән сүзләрне ишеткәнем бар. Килешәм, ләкин бер брендлы әйбер алып, аны арзанлы детальләр белән яраштырып та була бит, ул бик килешле күренә.

Йомры гәүдәле кызлар, тар күлмәк киеп, фигуралары өчен кыенсынып йөрмәсәләр дә ярый. Иркен фасонлы, җиңел тукымалы, балитәкле күлмәкләр популяр бу сезонда. Алар кайбер җитешсезлекләрне яшереп, буйсынны зифа итеп күрсәтәчәк. Аксессуарлар исә образны тулыландырып җибәрәчәк. 2015 елда туры һәм аска таба киңәеп киткән киемнәргә өстенлек бирелә.

Рәсем-бизәкләр дә күптән кулланыла инде, шуңа күрә алар сәер тоелмый. Мәсәлән, камуфляж бизәкле күлмәкләр яки әллә ниткән анималистик сурәтләр. Энҗеләр һәм челтәрләр белән бизәлгән киемнәр классик гардеробка карый.

Кыюрак булыгыз! Барысын да киеп, үлчәп карагыз: чәч тараудан башлап оек сайлауга кадәр. Детальләргә мөмкин кадәр күбрәк игътибар күрсәтегез. Мода белгечләре тәкъдим иткән күптөрле фасоннар кабатланмас образыгызны табар өчен уйланылган да инде.

Онытмагыз, ирләр күз белән ярата...






Диана безне берсеннән-берсе кызыклы идеяләре белән сокландырып кына тора. Бу юлы кадерле хатын-кызларыбызга бәйрәм бүләге итеп бик матур энә мендәрчеге ясарга тәкъдим итә ул. Ясавы искиткеч гади булса да, үзе бик матур килеп чыга. Әйдәгез, сез дә безгә кушылыгыз.





Мастер-классны Диана ЗӘЙНУЛЛИНА үткәрә.

ЭНӘ ДӘ БҮЛӘК, ЭНӘ «МЕНДӘРЕ» ДӘ...

Кирәк:

- тәлинкәле чәй чынаягы;
- иңе белән буе 20 см ситсы тукыма;
- 0,5 м чамасы челтәр тасма;
- җилем (Момент «Кристалл» яки Титан);
- холлофайбер яки синтепон;
- чынаяк авызы кадәр катыргы;
- бизәү өчен кечкенә гөлчәчәк, яшел яфраклар, эре сәйлән, атлас тасма.

Тартма өчен:

буе – 65, иңе 50 см булган ике бит катыргы кәгазь. (Без «Леонардо»дан алдык. Ул булмаса, ватман кәгазе дә ярый.) Тартманы бизәү өчен 0,5 м челтәр тасма, сүс бау, кечкенә йөрәк.





Эш барышы:

■ Тукымага чәй тәлинкәсен каплап, каләм белән әйләнәсен йөртеп чыгабыз. Тәлинкәне алып, зигзаг тешле кайчы белән шул эздән кисәбез.

■ Тукыма читеннән 5-6 мм эчкәрәк кереп, кул белән генә гади җөй салабыз. Җепнең очын тартып, тукыманы бөрәбез. Бераз бөргәч, эченә холлофайбер яки синтепон тутырабыз.







■ Чәй чынаягын катыргыга каплап, каләм белән эзен төшерәбез. Шушы эздән 2-3 мм эчкәрәк кереп кисәбез. Катыргы чынаяк эченә аз гына керебрәк торырлык булсын. Мендәрчекнең авызын шуның белән томалап, тукыманы ахыргача бөреп бетерәбез. Җепне нygытып тартып төенлибез, аннан кисеп алабыз.

■ Чынаякның аскы итәге буйлап челтәр тасма ябыштырабыз. Аннан соң чынаяк авызына мендәрчек үзе ябыштырыла. Мендәрчек тирәли дә челтәр тасма ябыштырып чыгабыз. (Тасма чите мендәрчек белән чынаяк арасына кертелә.)

■ Мендәрчекнең бер читен яфраклар һәм гөлчәчәк белән бизибез. Без яфракларны япон балчыгыннан ясадык, сез теләсә нинди калынрак яшел тукымадан, мәсәлән, фетр, драп, флис яки юка тукыманы ике катлап, уртасына синтепон куеп калдырып та ясый аласыз.

■ Гөлчәчәкне дә япон балчыгыннан ясарга мөмкин. Алай әле бүләгегез тагын да матуррак булачак, чөнки япон балчыгыннан ясалган гөлләр чын чәчәкләрне хәтерләтә.


■ Күбәләкләп бәйләнгән атлас тасма һәм эре сәйлән бөртеге – бизәкне тәмамлыйлар. Алар да чынаякка җилем белән ябыштырыла.

■ Иң соңгы эш итеп, чынаякны тәлинкәгә ябыштырабыз. Матурлык өчен тәлинкәнең үзен дә берәр ничек бизи аласыз, монысы инде фәкать фантазиягездән генә тора.

■ Япон балчыгы белән ничек эшләргә икәнен «Сөембикә»нең 2012 елгы февраль һәм март саннарында өйрәткән идек. Февраль санындагы мастер-классны сайтыбыздан да карый аласыз (www.syuyumbike.ru).

■ Бүләкне, гадәттә, матур тартмага салып бирәләр. Схемада тартманың бөкләү эзе – шәмәхә сызык белән, кисү эзе кызыл сызык белән бирелә. Буялган шакмаклар кисеп ташлана.

Тартманың үлчәме бүләкнең зурлыгына бәйле. Безнең очракта: тартманың иңе белән буе – 16 см, биеклеге – 10 см.





■ Капкачын 5 мм гына зуррак итеп ясыйбыз. Димәк, иңе белән буе – 16,5 см була. Биеклеге исә – 2 см. Кәгазьне кызыл сызык буйлап кискәч, шул эздән аз гына эчкәрәк кереп, уеп алырга кирәк.

■ Тартманың ян-ягы кәгазь җилеме белән ябыштырыла. Капкачының өске ягын челтәр тасма белән бизибез. Сүс бауны күбәләкләп бәйләп, тасмага тегеп куябыз. Шуңа кечкенә йөрәк беркетәбез. Бүләгебезнең чын күңелдән булуына ишарә бу.

БӘЙРӘМ СЫЕ — ҮРДӘК

Мастер-классыбызның бүгенге хуҗасы — Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Илдус ГАБДРАХМАНОВ. Безнең егетләребез булдыра алмаган эш бармыни соң ул?! Сәхнәдә генә түгел, өр-яңа фатирларының иркен, матур аш бүлмәсендә дә ут уйнатты Илдус абый. «Үрдәк пешереп күрсәтәм мин сезгә, — диде яраткан артистыбыз. — Моңарчы үрдәк пешереп караган юк иде әле, берочтан үзем дә өйрәнермен. Гади генә түгел, кәләпүшле үрдәк ул!» Шаярткан гынадыр инде ул, бер дә пешергәне булмаса, моның кадәр тәмле итеп әзерли алмас иде. Үрдәк телеңне йотарлык килеп чыкты.





Кирәк:
- үрдәк;
- 1 айва;
- 1-2 алма (өчерәк, катырак булсын);
- бер уч каражимеш;
- сарымсак;
- тоз-борыч,
- ярты лимон.

Бизәр өчен:
- төрле төстәге татлы борыч;
- яшел тәмләткечләр;
- ярты авокадо;
- 3-4 каражимеш.

Эш барышы:













■ Үрдәкне юып, суын саркытабыз, эчен-тышын тоз белән ышкыйбыз. Сарымсакны пресс белән изеп яки вак угычтан уып, үрдәк түшкәсенә сылыйбыз.

■ Алма белән айваны эрерәк кисәкләргә турыйбыз, караҗимешне яхшылап юабыз. Барысын бергә аралаштырып, сыйган кадәр үрдәк эченә тутырабыз.

■ Үрдәкнең эчен җеп белән тарттырып тегәбез. Агач таякчыклар белән генә эләктереп куйсагыз да була.

■ Лимонны урталай бүлеп, үрдәк өстенә ярты лимон сутын сыгабыз, һәр ягын шуның белән ышкыйбыз.

■ Үрдәкне полиэтилен җиңгә (рукав) тыгып, баш-башларын яхшылап бәйлибез, өстен бер-ике җирдән энә белән тишкәлибез.

■ Үрдәкне ике сәгатькә 180 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз. Өсте көярлек булса, бераздан мичне азрак кысабыз. Үз шулпасында тәмле булып изрәп пешә ул.

■ Инде үрдәгебезне матурлап табынга бирү хәстәрен күрик. Ник дисәгез, бу – бәйрәм сые, табынның бизәге булсын.

Зур матур тәлинкәгә салат яфраклары тезеп чыгабыз. Аның өстенә боҗралап туралган татлы борыч, телемләп туралган авокадо, укроп белән кыяклы суган тезәбез. Борыч боҗраларын караҗимеш белән бизибез. Тәлинкә уртасына бөтен көйгә үрдәкне куябыз. Аны табынга чыккач кына өлешләргә бүләчәкбез. Соусны исә кечкенә касәгә салып, һәр кешенең янына куялар. Бәйрәмнәрегез ямьле, ашларыгыз тәмле булсын!

■ Илдус Габдрахманов белән мастер-классның видеосын сайтыбыздан (www.syuyumbike.ru) карарга була.



Үрдәк итенең тәмен ачып җибәрү өчен (хәер, теләсә кайсы ит белән дә килешә), нарат җиләгеннән соус ясыйк. Булгач, булгач, ресторандагыча булсын.

Кирәк

- 300 г нарат җиләге (брусника);
- 300 г шикәр комы;
- 1 әфлисун;
- 1 лимон;
- 4 данә канәфер;
- 4 борчак хуш исле борыч;
- 2 чәй кашыгы дарчин.

Эш барышы:

■ нарат җиләген юып, суын саркытабыз. Җиләкнең яртысын алып калып, калганын блендерда издерәбез.
■ калган җиләкне һәм шикәр комын кушып янә яхшылап туглыйбыз.
■ Әфлисунның кабыгын вак угыч белән кырып, җиләк янына кушабыз. Әфлисун сутын да блендерга өстибез.
■ 2 аш кашыгы лимон суты, 2 чәй кашыгы дарчин өстәп, барысын бергә соңгы кат туглыйбыз да, утка чыдам савытка салып, плитә өстенә куябыз. Әледән-әле болгаткалап торабыз. Кайнап чыга дигәндә, уттан алабыз.

Без хатын-кызларны тәмле-татлы ризык өчен үлеп китә дигән фикер яши. Бәлки, шулайдыр да. Әмма бу җәһәттән ир-атларның да кимен куймаганын беләбез. Мөгаен, безгә тартма-тартма конфет, торт бүләк иткәндә, алар үзләре дә ымсынып куя торганнардыр.
Ә без киң күңелле — алар безне сөендерер өчен бүләк иткән тәм-томнарны да, күчтәнәчләрне дә, үзебез пешергән сыйларны да бүлешергә әзербез. Алар, җиң сызганып, безне тәмле ризыклар белән «узындырырга» уйлаганда бигрәк тә рәхәт була инде.



СЫЙЛАНЫЙК ӘЛЕ!

Кара шоколад
Шоколадның әчесе хакында сөйләрбез. Чөнки нәкъ менә шуны-сын яратырга кирәк. Аның калориясе дә күп түгел, башка файдалы үзлекләре дә бар. Әйтик, анда капиллярларны ныгыта, нервларны тынычландыра торган флавонидлар, антиоксидантлар, кальций, тимер, магний, аксым, витаминнар бар.

Пастила
Аны фигурама зыян килә дип курыкмыйча ашарга мөмкин. Ул, мармелад кебек үк, радиациянең тискәре йогынтысын киметә, авыр металл тозларын куалый.

Мармелад
Составындагы пектин аңа койкасыман үзлек бирә. Пектин холестерин дәрәҗәсен киметә, токсиннарны куалый, ашказаны-эчәк юллары эшчәнлеген көйгә сала. Калориясе дә күп түгел.

Бал
Аның калориясе шикәрнеке кебек үк. Әмма ул шикәрдән татлырак. Шуңа күрә аны азрак кабарга киңәш итәбез. Әйтик чәйгә ике шакмак шикәр саласы урынга бер кашык бал кабу җитә. Балда организм өчен гаять кирәкле витаминнар, магний, марганец, тимер, минераллар, аминокислоталар бар. 100 грамм балда – саналган матдәләрнең көнлек нормасы.

Хәлвә
Ул бик тәмле генә түгел, бәлки, яшәртә дә әле. Хәлвә составындагы А, Е, В витаминнары тән тиресен яхшырта, йөрәк-кан тамырларын ныгыта. Хәлвәне борын-борыннан матур булу өчен дә ашаганнар.


Кайнатма
Витаминнар, минераллар оясы. Әмма витаминнар саклансын өчен аны бик аз гына кайнатырга яки джем ясарга кирәк. Бигрәк тә кура җиләге, айва, кизил һәм чикләвек кайнатмасы файдалы.

Зефир
Бик күп татлы ризыклар белән чагыштырганда, зефирда калория азрак. Тимер белән фосфорга бай. Мускуллар ныклыгы өчен кирәкле аксымга бай.

Камыш шикәре
Моннан егерме еллар элек үк диетологлар камыш шикәренең файдасы рафинад шикәрнекеннән күбрәк дип әйтәләр иде. Эшкәртелмәгән шикәр организмга файдалырак, чөнки андагы меласса дигән матдә кальций, магний, тимер, фосфор, калий кебек микроэлементларга бай.

Җиләк-җимеш
Аларда витаминнар, микроэлементлар, минераль тозлар, антиоксидантлар күп. Шуңа күрә җиләк-җимеш һәр кешенең табынында булырга тиеш. Җитмәсә, алар бик туклыклы да, чөнки аларда органик кислоталар, эфир майлары, аксым, углеводлар, пектин матдәләре, клетчатка бар. Ябыгырга теләгән кешеләр өчен җиләк-җимеш клетчаткасы – менә дигән ярдәмче.

Цукат
Бу – натураль продукт. Анда токоферол, аскорбин кислотасы, антиоксидант витаминнар күп. Цукатлар хәтерне яхшырта, дикъкатьне көчәйтә, арыганлыкны бетерә, нервларны саклый. Өстәвенә, аз калорияле бу тәмлекәч файдалы да.


КУЧКАР. Күп кенә хыялларыгыз чынга ашар, куйган максатларыгызга ирешү өчен юллар ачылыр. Сәламәтлеккә бик тә игътибарлы булу кирәк. Акчагызны сак тотыгыз.


ҮГЕЗБОЗАУ. Катлаулы ай көтелә. Теләкләрегез белән мөмкинлекләрегез икесе ике юлдан йөри. Тирә-юньдәге вазгыятькә тыныч караш һәм юмор хисегез барлык мәшәкатьләрне җиңеп чыгарга ярдәм итәчәк.


ИГЕЗӘКЛӘР. Якыннарыгызның сезнең ярдәмгә мохтаҗ булуы ихтимал, аларга игътибарлырак булыгыз. Элеккеге үпкәләрдән котылу өчен менә дигән форсат бу. Эш мәсьәләсендә үз көчегезне дөрес бәяләгез, югыйсә көлкегә калуыгыз бар.


КЫСЛА. Ай башында ерак юлга чыгудан тыелып торыгыз. Айның икенче яртысы сәламәтлекне һәм тышкы кыяфәтне кайгырту өчен яхшы вакыт. Эш урыныгызда хезмәтегезне бәяләрләр, хезмәт хакының да арту ихтималы бар. Зур әйберләр сатып алмагыз, оттыруыгыз мөмкин.


АРЫСЛАН. Яңа эшләрне айның икенче яртысыннан башласагыз әйбәт. Якын кешегезгә җылы сүзегезне, ягымлы карашыгызны кызганмагыз, югыйсә гаиләгездә низаг килеп чыгарга мөмкин. Яман гадәтләрдән арыну өчен иң яхшы ай.


СӨМБЕЛӘ. Бу айда акча белән бәйле мәсьәләләргә катнашмый торыгыз. Эшегездә активрак булырга кирәк, чөнки сезне сынаучылар бар. Айның икенче яртысында финанс ягы әйбәтләнер.


БИЗМӘН. Башкаларның фикеренә колак салыгыз. Компромисска барырга тырышыгыз. Мөмкин кадәр низаглардан качыгыз, югыйсә бик зур бәхәскә кереп китеп, тормышыгызны катлауландырырсыз. Айның икенче яртысында мул гына керем көтелә.


ЧАЯН. Беренче урынга эш һәм тагын бер тапкыр эш калкып чыгар. Элеккеге танышларны очратып, көтелмәгән ярдәмгә юлыгырсыз. Акчагызны кысып тотыгыз, якын арада керем көтелми.


УКЧЫ. Мөмкинлек булса, барлык мөһим эшләрне башка бер вакытка күчерегез. Ай ахырына таба боларны башкару өчен җайлы вакыт чыкмый калмас. Гаиләгезгә көнләшү хисен берүк кертә күрмәгез. Эштә гайбәтләргә катнашмагыз, югыйсә гаепле булып калырсыз.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Айның беренче атнасында бик зур игътибар һәм түземлек таләп ителүе ихтимал. Соңыннан яхшы үзгәрешләр башланачак. Көчегезнең артып китүен үзегез дә тоячаксыз. Эштә үз сүзегездә нык торыгыз. Күптән хыялланып йөргән нәрсәгезне сатып алырсыз. Гаилә тормышы үз җае белән барыр.


СУКОЯР. Күп аралашулар, очрашулар, танышулар ае. Мәгълүматны җиткереп кенә торырлар. Күп вакытны гаиләгез белән үткәрергә тырышыгыз. Бу айда газиз кешегезнең хисләре романтик төсмер алачак, бу бигрәк тә ай ахырына таба күренәчәк. Эштә бар да тәртиптә.


БАЛЫК. Тормышның чын мәгънәсендә төмен тоеп яшәрсез. Тормышыгызга үзгәрешләр кертергә теләсәгез – нәкъ вакыты. Мәхәббәт өлкәсенә килгәндә, йөрәгегезне тыңлагыз, бу айда аеруча сизгер ул.

Мартта кабынган йолдызлар

Татарстан



Венера Ганиева (24.03.1955) – **җырчы.**
Казанда туып-үсә. 1982 елда Казан консерваториясен тәмамлап, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрына эшкә килә. Театрдагы иҗаты хакында сөйләгәндә классик опералардан Виолетта («Травиата»), «Джильда («Риголетто»), Розина («Севильский цирюльник»), Норина («Дон Паскуале»), татар композиторлары әсәрләреннән Алтынчәч («Алтынчәч» Н. Җиһанов), Сәрвәр («Башмагым» Җ. Фәйзи) һәм башка бик күп партияләрне атарга мөмкин. Венера Ганиева эстрада да танылган җырчы. Драматик актриса буларак, Г. Камал театрында К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасында Мәйсәрә ролен дә башкарды. 1999 елдан Казан дәүләт сәнгать университетында вокал кафедрасы мөдире булып эшли, профессор. Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Республиканың Г. Тукай премиясе лауреаты.

Россия



Надежда Бабкина (19.03.1950) – **җырчы.**
Әстерхан өлкәсендә туа. Унынчы сыйныфта укыганда ук яшь башкаручыларның Бөтенроссия конкурсында катнашып, беренче урынны яулый. 1967 елда музыка училищесын тәмамлап, Әстерхан өлкә кинофикация һәм кинопрокат идарәсендә солист-вокалист була. Гнесиннар исемендәге музыка-педагогика институтында укыганда «Русская песня» ансамблен оештыра. 1994 елдан мөстәкыйль оешма булган бу ансамбльдә Надежда Бабкина сәнгать җитәкчесе вазыйфасын башкара. РСФСРның атказанган, Россиянең халык артисты, IV дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены кавалеры.

Чит илләр



Изабель Юппер (16.03.1955) – **француз артисты.**
Парижда бай гаиләдә туа. Беренче тапкыр 1972 елда Н. Компанезның «Фаустина һәм Эссе җәй» фильмында уйный. Ива Буассеның «Дюпон Лажуа» фильмы аның актерлык биографиясендә мөһим урын били. Безгә ул фильм «Бу хәл бәйрәмдә булды» исеме белән таныш. Актрисаның тәүге зур эше – «Хөкемдар һәм җәллад» фильмы. Ә менә режиссер К. Шаброл Г. Флоберның «Госпожа Бовари» романын аның өчен генә сәхнәләштерә. 1994 елда актриса Игорь Минаевның «Наводнение» фильмында уйнарга чакыру ала. Изабельнең олы кызы Лолита Шаммер да – актриса.





АЙЛЫ ТӨНДӘГЕ ТӨШ

Кызыл күлмәкле, кызыл яулыклы кызның сары чәчләре бер якка таралып төшеп, әләм кебек җилферди. Уйчан ай, офыктагы күгелҗем, шәмәхә балкыш, җылылыкны куып, ниндидер җиләслек сирпи. Рәссам Наталья Бабкинаның «Җил» картинасын мин шулай «укыдым». «Күк гөмбәзе», «Эңгер-меңгер», «Сирень төсендәге урман», «Май төне», «29 апрель. Алабуга», «Диңгез турында» картиналарында да – шул ук төсләр... Кояшлы аяз күк йөзе яки кичке шәфәкъ, томан артыннан тонык кына күренүче ай, дулкыннар... Айлы төндәге төш сыман ниндидер сер тулы үзгә бер дөнья... Хәер, бер картинасы нәкъ шулай атала да – «Айлы төндәге төш». Әнә шундый шигъри исемле күргәзмәсе белән Наталья моннан берничә ел элек туган шәһәре Чаллыда бик күп тамашачыны җыйган иде инде. Талантлы рәссамны Татарстанда, Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы беләләр. Ул Россия Рәссамнар берлеге һәм Юнеско сынлы сәнгать халыкара ассоциациясе әгъзасы.

Гадәти әйберләрдән дә матурлык күрә, көндәлек тормышны кабатламаган сурәтләрдә ача торган рәссам ул. Образлы фантазиясе һәрчак очышта. Җете ачык төсләре, дөньяны самими кабул итә белүе, күңел халәте картиналарына да җай гына кереп урнаша да тамашачыларын сихерләп, үзенә тартып тора. Кагыйдәләргә буйсынмыйча, ничек күрә, ничек кабул итә – шулай ясый ул. Бөтенесе – темасы да, сюжеты да, колориты да – үз тормышыннан. Фольклорга, дини мифологиягә нигезләнеп яисә үз тоемлавына, хыял сурәтләренә таянып иҗат ителгән картиналары, табигать белән кеше арасында ихлас гармония тудырып, шигъри саф дөнья ача.


Укытучылары, остазлары кемнәр соң! Рәсем укытучысы Елена Севастьянова аңа мәктәп елларында беренче күнекмәләрне төшендерә. Мадияр Хаҗиев исә төсләр, буяулар, фантазия ярдәмендә әкияти матур дөнья тудырырга сәләтле укучысын олы иҗатка алып кереп китә.

Наталья Бабкина төрле стильләрдә, төрле жанрларда иҗат итә. Аңа этно-авангардлык та, абстракция дә, импрессионизм да хас. «Җил»енә сокланып, мин аны портрет остасы дип ачтым. Пейзажлары («Май төне», «Гыйнвар көне») туган як матурлыгын Наталья күңеле аша күрсәтә. Натюрмортлары гадилеге һәм нәфислеге белән җәлеп итә («Эңгер-меңгер», «Чәй», «Узган елгы букет»). Эксперименталь сәнгать жанрына караган эшләре тирән фәлсәфәсе белән уйга калдыра. «32 нче август» картинасына гына күз салыгыз! Аны һәркем үзенчә кабул итә. «Узып баручы гасырдан уйланырга дип калдырылган бер көн», – ди рәссам үзе.

Ландшафт дизайны белән профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнә. «Илһам» иҗат берләшмәсендә төрле арт-проектлар уйлап таба, Чаллы укучылары һәм студентлары өчен мастер-класслар үткәрә. Тату гаиләсе, яраткан дуслары белән сәяхәтләрдә йөреп кайту исә яңа картиналарында балкып кабына. «Урал» сериясеннән никадәр картинасы бар! «Агачлар» сериясе исә Абхазиянең бай үсемлекләр, чәчәкләр, агачлар дөньясын сыйдырган. Кояш, диңгез, таулар, яшеллек... Һәм, әлбәттә, төсләр, хисләр.

Наталья Бабкинача: күк, сары, зәңгәр, шәмәхә...

Эльмира ЗАКИРОВА






НАТАЛЬЯ БАБКИНА

БУТИК «ЛЮКС», КАК ДИЗАЙНЕР ОБРАЗА И ИНДИВИДУАЛЬНОСТИ, НЕГРОМКО, НО ВЕСОМО ЗАЯВЛЯЕТ О СЕБЕ. ЗДЕСЬ МИР МОДЫ ПЕРЕСЕКАЕТСЯ С СОСТОЯНИЕМ ДУШИ, ВЕЩЬ СТАНОВИТСЯ ВЫРАЖЕНИЕМ ЛИЧНОСТИ. ПРОЦЕСС ПОКУПКИ ПРЕВРАЩАЕТСЯ В ШОУ ОДНОЙ ЖЕНЩИНЫ – ВАС. И ЭТО БЕЗУМНО ИНТЕРЕСНО И ДАЖЕ ВЕСЕЛО. ВЫ СОЗДАЕТЕ СТИЛЬ – СТИЛЬ СОЗДАЕТ ВАС! ЖДЕМ.



РЕКЛАМА

ЛЮКС
BOUTIQUE

Казан, Калинин ур., 37
+7 (843) 264-51-61
luxkazan.ru

16+